Хәзерге вакытта бик күп авыллар турында беренче белешмәне «Татар энциклопедиясендә», район тарихына багышланган китапларда, Фирдәүс Гарипованың «Авыллар һәм калалар тарихыннан» һәм башка китапларда, Интернет челтәрендә урнаштырылган материалларда табарга мөмкин. Авыл тарихы турында алыштыргысыз чыганак – район газеталары. Алар 1930 елларда районнар оештырылгач та нәшер ителә башлаганнар һәм хәзерге көнгә кадәр басылып киләләр. Биредә кайбер авылларның тарихы турында кызыклы мәкаләләр, белешмәләр табарга мөмкин. Авыл тарихы белән шөгыльләнүчеләр арасында: «Мин авылның беренче тарихчысы түгел, ә профессионал тарихчылар, этнографлар, тел белгечләре хезмәтләре белән танышкач кына авыл тарихын язарга керешү теләге булырга тиеш» – дигән фикердән чыгып изге эшкә керешергә кирәк дип уйлыйм. Күп китап укыган кеше берничек тә үзен алыштыргысыз илаһи зат итеп күрсәтми, бигрәк тә тарих өлкәсендә.

Бу өлешкә йомгак ясап шуны әйтәсе килә: әлегә бу өлкәдә бер калып эшләнмәгән, чөнки һәрбер автор китапның кереш өлешен язганда үз калыбын булдырырга тели һәм аны үзе ничек аңлый, шулай итеп тормышка ашыра да. Авыл тарихына багышланган китапның кереш өлеше булырга тиеш, биредә бу авыл тарихын язуның актуальлеген, нинди максатлар һәм бурычлар куелганын, хронологиясен, авыл тарихын язганда нинди чыганаклар һәм әдәбият файдалануны күрсәтеп, анализлап язарга кирәк. Авыл тарихына багышланган китапның кереш сүзе күләме буенча ким дигәндә 10 биттән дә аз булмаска тиеш дип уйлыйм.

Хәзер инде авыл тарихының төп өлеше турында берничә фикер. Китапның төп өлеше үзе берничә бүлектән тора – авыл тарихы текстын берничә бүлеккә бүлеп эшләү гадәти хәл. Биредә дә авторлар арасында бердәмлек сизелми, ул юк дәрәҗәсендә. Шул ук китапларны тикшереп карыйк.

10 китапның 4 се аерым әсәрләрдән, очерклардан тора һәм ике китап 17 бүлектән, калганнары 32 һәм 37 бүлекләрдән тора [Закирова: 2013. 511 б.; Закиров: 2015. 284 б.; Зыятдинов: 2004. 223 б.; Сафин 2014. 318–319 б.]. Китапны 17 бүлеккә бүлеп эшләү белән килешеп булса, 32–34 бүлекләр укучыда шик тудырырга мөмкин. Чынбарлыкта, авторлар китапның структурасы турында ныклап уйлап эшләмәгәнлеге сизелә. Шуннан чыгып кына бу китапларны чын авыл тарихы түгел дип әйтә

алабызмы? Юк, андый сүз биредә урынсыз булыр иде, чөнки автор үз күзлегеннән чыгып максатын тормышка ашырган.

Калган алты китапны структура ягыннан анализласак, биредә китапның эчтәлеге структура ягыннан караганда яхшырак эшләнгәнлегенә игътибар итәсең. Бу китапларда төп эчтәлек биш бүлектән алып 12 кадәр җитә. Бу бүлекләр дә тагын аерым параграфларга, бүлекчекләргә бүленгән. Аларның саны 18 алып 106 кадәр җитә. Авторларларны авыл тарихына караган иң беренче нинди проблемалар җәлеп итә соң? Алар берничә. Шуларның кайберләрен атап китик.

Авыл тарихына багышланган китаплар өчен иң популяр, барлык китапларда төрле яктан чагылыш тапкан тема – Бөек Ватан сугышы еллары. Әлбәттә, ул тема эчтәлеге ягыннан төрлечә яктыртыла, кайберләрендә сугыш елларындыгы авылның авыр тормышы чагылыш таба, кайберләрендә – авылдашларның фронттагы батырлыклары искә алына, шуңарга акцент ясала, аерым геройлар портретлары сүрәтләнә: [Галимов: 2015. 157-189; Данилов: 2014. 103-113; Закиров: 2015. 284114-164 б.; Закирова: 2013. 188-211 б.; Зыятдинов: 2004. 32-63 б.; Кыямов: 2017. 279-376 б.; Салах: 2003. 28-32 б.; Сафин 2014. 87-135 б.; Файзрахманов: 2017. 73-100 б.; Шәйхетдинов: 2006. 85-135 б.]. Шулай да китапның бу өлешенә карата бер тәкъдим кертер идем. Ул тәкъдим шуннан гыйбарәт: бу өлешкә кушымта итеп фронтта катнашучыларның исемлеген бирергә кирәк дип уйлыйм. Кызганыч, әлегә кадәр күп авылларда сугышта катнашучыларның тулы исемлеге юк, авылда туып үскән, Ватан сугышында катнашкан кайбер кешеләр турында авылда бернинди дә мәгълүмат сакланмаган очраклар да бар. Тиз арада бу кимчелекне бетермәсәк, күп кеше авыл тарихына кермичә калырга мөмкин. Фронтта катнашучыларны табу өчен хәзер мөмкинлекләр шактый. Мин үзем Урманасты Үтәмеш авылы тарихын эшләгән вакытта авылдан фронтка 119 кеше киткән дигән санны 240 ка җиткердем. Фронтовиклар исемлегендә әсир төшкән кешеләр бөтенләй юк дәрәҗәсендә иде. Мин аларны Чирмешән Мемориал музеенда сакланган архив материаллары исәбенә тулыландырдым. Әлбәттә, «Хәтер китабы» да ярдәм итте.

Сан ягыннан икенче урында авыл исемен һәм авылның нигезләнгән вакытын ачыклау темасы. Бу мәсәләләрне 10 авторның 9 сы төрле яктан тикшерә. [Галимов: 2015. 24-29 б.; Данилов: 2014. 16-23 б.; Закирова: 2013. 34-39 б.; Зыятдинов: 2004. 7-25 б.; Кыямов: 2017. 34-43 б.; Салах: 2003. 6-11 б.; Сафин 2014. 12-24 б.; Файзрахманов: 2017. 23-27 б.; Шәйхетдинов: 2006. 7-19 б.]. Бу бик катлаулы мәсьәләнең эчтәлегенә тукталып тормыйча, шуны азсызыклап әйтергә мөмкин: бу тема авыл

тарихында төрле архив чыганакларын файдаланып, халык арасында сакланган риваятьләрне дә инкар итмичә, җентекләп тикшерeләргә тиеш.

Колхозлаштыру – күмәкләштерү темасы да иң популяр темаларның берсе, бу темага ун автор да туктала. [Галимов: 2015. 129-153 б.; Данилов: 2014. 88-102 б.; Закиров: 2015. 105-113 б.; Закирова: 2013. 118-187 б.; Зыятдинов: 2004. 26-32 б.; Кыямов: 2017. 204-278 б.; Салах: 2003. 25-28 б.; Сафин 2014. 36-41 б.; Файзрахманов: 2017. 51-59 б.; Шәйхетдинов: 2006. 70-84 б.]. Әлбәттә, бу бүлек тә күләме буенча да, эчтәлеге белән дә нык аерылып тора. Шулай да совет чорында авылда тормыш колхоз белән тыгыз бәйләнгән булганга күрә, бу тема да авыл тарихында тиешле чагылыш табарга тиеш дип уйлыйм. Колхозны оештыру датасын ачыклау өчен Татарстан Республикасы милли архивында эшләнгән каталог ярдәм итә, аннан файдалана белергә кирәк. Колхозлаштыру, кулакларны сөрү, авылдагы репрессияләр бер-берсе белән нык бәйләнгән. Кызганыч, репрессия темасы авыл тарихында әлегә игътибарсыз темаларның берсе булып тора. Биредә дә шактый яңалаклар ачарга мөмкин. Җентекләп тикшерү нәтиҗәсендә генә ул елларда авылның фаҗига масштабына төшенә башлыйсың. Китапның бу өлешен эшләгән вакытта репрессиягә эләккән кешеләрне барлап чыгарга, күп кенә кешеләр турында яңа мәгълүматлар табарга тырышырга кирәк дип уйлыйм. Урманасты Үтәмеш авылында 3 кеше генә репрессияләнгән дип исәпләгән булса, хәзерге вакытта алар 38 кеше, шуларның өчесе атып үтерелгән, берсе Бөгелмәдә, ә икесе Красноярский крайда. Биредә архив материаллары, репрессия корбаннарына багышланган китаплар, Чирмешән меморил музее архивы, газета язмалары ярдәм итә. Бу юнәлештә эшне авыл тарихын язучылар дәвам итәргә тиешләр.

Авыл тарихын язучылар мәгариф, уку-укыту эшен тиешле дәрәҗәдә яктыртырга тырышалар. Без анализлаган китапларның берсендә генә мәгариф тарихына багышланган бүлек яисә параграф бирелмәгән. Күпчелек авторлар мәгариф тарихын борынгы заманда ук оешкан мәктәп-мәдрәсәләрдән башлап бүгенге көнгә кадәр җиткерәләр. Әлбәттә, мәгариф тарихын совет чорыннан гына күрсәтүче авторлар да бар. Татар-мөселман дөньясында дини мәгариф системасы X гасырда формалашып XX гасыр башына, 1917–1918 елларга кадәр бик яхшы эшләп килгән. Без моны онытырга тиеш түгел. Нинди генә авыл булмасын, авылда мәктәп эшләгән, малайларны мулла укытса, кызларга белемне абыстай биргән. Менә бу казанышыбызны безгә онытмыйча, киләсе буынга тапшырырга кирәк.

Авыл тарихына багышланган китапларда төрле гасырларда авыл халкының көн-күреше, Пугачев явы, гражданнар сугышы, ачлык еллары, дин

тарихы, шәҗәрәләр, күренекле шәхесләр турында да тәфсилләп язылган. Болар барысы да халкыбыз тарихын тулыландыра, авыл кешеләренең төрле өлкәләрдә казанышларын күрсәтергә мөмкинлек бирә.

Кызганыч, анализлаган китапларда татар тамгалары турында тик Илдар Кыямов кына «Нәсел тамгалары» дип аталган параграфта мәглүматлар биреп китә, 51 кешенең тамгасын сүрәтли [Кыямов: 2017. 594-596 б.]. Халкыбызның кабатланмас тарихи мирасы турында мәгълүматлар әлегә китапларда чагылыш тапмый, үзешчән тарихчылар авыл тарихын эшләгәндә архив материалларында сакланган тамгалар сүрәтен төшереп, таблицалар ясап, укучыларга тәкдим итсәләр, тарихи-мәдәни мирасны барлау, киләсе буыннарга тапшыру өлкәсендә зур эш башкарылган булыр иде.

Китап, гадәттә, йомгаклау сүзе белән тәмамлана. Тик безнең авторларның дүртесе генә бу таләпне үтәгән. [Галимов: 2015. 365-369 б.; Данилов: 2014. 278-300 б.; Салах: 2003. 253 б.; Шәйхетдинов: 2006. 7-19 б.]. Үтәлгән очракта да, йомгаклау сүзендә башкарылган эшкә тиешле нәтиҗә ясала дип әйтә алмыйбыз. Ул урыны белән кереш сүзнең дәвамына охшаган була, кайбер очракларда китапның эчтәлеген бөтенләй чагылдырмый.

Хәзерге вакытта язылган авыл тарихларында, гадәттә, кушымта рәвешендә оригинал документларның күчермәсе дә бирелә. Анализлаган китаплар арасында җиде автор кушымта биргән. Алар арасында иң эчтәлекле, оригиналь документлар һәм архив чыганаклары Вячеслав Данилов һәм Җәүдәт Файзрахманов хезмәтендә 17 шәр кушымта [Данилов: 2014. 317-450 б.; Файзрахманов: 2017. 274-313 б.], ә калганнары бердән биш кушымта белән чикләнгәннәр. Шактый күләмдә – 133 һәм 39 биткә сыйган архив документлары аерым игътибарга лаек, чөнки алар китапның эчтәлеген баетып кына калмыйлар, алар авыл тарихын тулыландыра торган яңа информация бирәләр. Кызганыч, кайбер очракларда, бу чыганаклар китапның текстында кулланылмый, ул аерым документ булып кына кала.

Тарихи китапларның ахырында, кагыйдә буларак, кулланылган чыганаклар һәм әдәбият исемлеге бирелә. Безнең авторларның дүртесе файдаланган әдәбият исемлеген бирмичә калдырган, китап битләрендә дә авторларга, документларга сылтамалар юк дәрәҗәсендә. Шуңа күрә авыл тарихларының фәнни нигезен киңәйтүне алга сөргән очракта, архив чыганакларына, китаплардагы документларга, истәлекләргә, хәтирәләргә сылтама ясарга кирәктер дип уйлыйм.

Югарыда күрсәтелгән ун авторның китапларын кыска анализлаганнан соң, йомгак ясаган вакытта, түбәндәге нәтиҗәләргә килергә мөмкин:

1. Авыл тарихлары хәзергә кадәр төрле эчтәлектә, структурада эшләнә.

2. Ул хезмәтләр өч өлештән – кереш, төп өлеш, йомгак – өлешләреннән тора.

3. Китапларга кереш сүзләрне автор гына түгел, авторның китабын тәкдим итүче галим-голәмә дә эшли.

4. Төп өлешнең дә кабул ителгән структурасы әлегә юк; биредә биштән алып унсигезгә кадәр бүлекләр бар. Алар авыл тарихында булган иң мөһим вакыйгаларны яктырталар.

5. Йомгаклау сүзе дә күп очракта язылган хезмәткә нәтиҗә ясаучы аерым бүлек булып тора алмый.

6. Кушымталарда төрле оригинал документлар тәкъдим ителә, тик аларны фәнни эшкәртү, тарихи чыганак итеп куллану өчен сылтама ясалып бетерелмәгән.

Язмамның ахырында, төрле авторларның авыл тарихы хезмәтләрен тикшергәннән соң, түбәндәге, катлаулырак структураны тәкъдим итәргә мөмкин дип уйлыйм:

Кереш сүз

Төп өлеш

I. БОРЫНГЫ ТАРИХ

II. АВЫЛЫМ ТАРИХЫ: ПАТША ЗАМАНАСЫ

1. АВЫЛНЫ КЕМ ҺӘМ КАЙЧАН НИГЕЗЛӘГӘН?
2. ПАТША ЗАМАНЫНДА АВЫЛ ТОРМЫШЫ
3. АВЫЛЫМ ТАМГАЛАРЫ

III. АВЫЛЫМ ТАРИХЫ: СОВЕТ ЧОРЫ

1. 1917 ЕЛГЫ РЕВОЛЮЦИЯЛӘР, ГРАЖДАННАР СУГЫШЫ, АЧЛЫК
2. КҮМӘКЛӘШТЕРҮ-КОЛХОЗЛАШТЫРУ ЕЛЛАРЫ
3. БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫ
4. КОЛХОЗ ЧОРЫ (1946-1991)

IV. АВЫЛЫМ ТАРИХЫ: ЯҢАРЫШ

ЙОМГАКЛАУ СҮЗЕ

КУШЫМТАЛАР

ЧЫГАНАКЛАР ҺӘМ ӘДӘБИЯТ

**Әдәбият:**

1. Галимов Кадыйрҗан. Ябалагым – якты ягым. Тарихи очерклар. Казан: Яз, 2015. – 384б.

2. Данилов В.В. Хуҗа Хәсән – әби-бабайлар нигезе. Казан: Идел-Пресс, 2014. – 452 б.

3. Закиров Әсгат, Закирова Миләүшә. Вакыт дәрясында Иске Үтәмеш. Бөгелмә: Нәфес нәшрияты, 2015. – 285 б.

4. Закирова Гөлүсә. Каргаул. Казан: Полигран – Т., 2013. – 512.

5. Зыятдинов Бакый. Мәгърифәтле Таузар иле. Казан: Идел – Пресс, 2004. – 224 б.

6. Кыямов Илдар. Кара Чишмә карясе. Казан: Идел-Пресс, 2017. – 720 б.

7. Салах Әсгат. Бараң токымы. Казан: Матбугат йорты, 2003. – 256 б.

8. Сафин Илдар. Юлбатым – Ямбулатым. Саба муниципаль районы Юлбат, Тенеки, Йосыф – Алан, Калатау авыллары тарихыннан сәхифәләр. Казан: «Сүз» нәшрияты, 2014. – 320 б.

9. Файзрахманов Җәүдәт. Кышлау авылы тарихы. Казан: Яз, 2017. – 320 б.

10. Шәйхетдинов Б.Г. Олы юлда – Олы Тигәнәле. – Казан: Сүз, 2006. – 288 б.

# ПРОСТРАНСТВЕННОЕ ВИДЕНИЕ БУДУЩЕГО РОДНОГО КРАЯ[1]

*Р.Ф.Гатауллин*

По происхождению и форме развития все поселения нашей страны делятся на следующие группы:

– поселения, которые появились в досоветский период;

– созданные в советский период;

– образованные в постсоветское время.

В досоветский период в образовании поселений ведущую роль играли факторы землепользования. Новые поселения возникали с целью сокращения расходов на транспортировку сельскохозяйственной продукции и инвентаря.

В советский период новые поселения создавались планово. В свою очередь, планово были осуществлены укрупнения сел. При этом на передний план ставилось стремление сэкономить в расходах на создание объектов социальной инфраструктуры. Строительство одной крупной школы или больницы всегда было дешевле, чем строительство нескольких мелких.

В постсоветское время образование и развитие поселений происходит на совсем иной основе. В этом ведущую роль играет стратегическое планирование территории, которая, прежде всего, рассматривается как совокупность поселений.

В соответствии с ФЗ от 28.06.2014 г. №172 «О стратегическом планировании в Российской Федерации» муниципальные образования страны начали разрабатывать стратегии их социально-экономического развития. Изучение существующего в этой области опыта показывает, что наибольший разнобой существует в подготовке разделов стратегий по пространственному развитию. В ст. 3 цитируемого Закона Стратегия пространственного развития Российской Федерации рассматривается как самостоятельный документ, нацеленный на поддержание устойчивости системы расселения на территории РФ. Согласно ст. 4 Закона методическое обеспечение стратегического планирования отнесено к полномочиям органов государственной власти Российской Федерации в сфере стратегического планирования. Институт экономики города в 2015 г. разработал «Методические рекомендации по оптимизации стратегического

1. Данное исследование выполнено в рамках госзадания ИСЭИ УНЦ РАН по теме «Нивелирование пространственной поляризации разноуровневых территориальных систем в условиях формирования технологического прорыва» (№ госрегистрации АААА-А17-117021310209-5).

планирования на муниципальном уровне», которые были рекомендованы профильным комитетом Госдумы РФ к использованию.

В федеральном законодательстве в настоящее время в области стратегического планирования в МО существуют противоречия. Так ФЗ от 06.10.2003 г. 131-ФЗ «Об общих принципах организации местного самоуправления в Российской Федерации» принятие и организацию выполнения программ комплексного развития муниципального образования (ст. 17) отнес в область полномочий органов МСУ. В то же время комплексное социально-экономическое развитие МО в число вопросов местного значения не вошло.

ФЗ № 172 установление требований к содержанию документов стратегического планирования относит к полномочиям органов государственной власти субъектов РФ. В данном случае становится не ясным, как все это осуществить в условиях, когда методическое обеспечение стратегического планирования закреплено все же за федеральной властью.

Следует отметить, в указанных документах речь идет в лучшем случае о механизме подготовки муниципальных стратегий, а не об их содержании.

При подготовке проекта раздела по пространственному развитию муниципальных образований не существует также ясности в его структуре. До сих пор отсутствует также единая трактовка содержания категории «экономическое пространство». Как нам кажется, пространственное развитие любого муниципального образования может рассматриваться в следующих ракурсах:

– внутреннем, как упорядоченная структура форм организации собственно пространства;

– внешнем, как отношение к элементам, находящимся вне объекта пространства.

Внутренний профиль пространственного развития муниципального образования прежде всего включает функциональное зонирование его земельного фонда. Обычно выделяют несельскохозяйственные земли и земли сельхозназначения, земли поселений, пашни, пастбища, многолетние насаждения, внутренние водоемы, водоохранную зону, зеленый пояс, промышленную и лесную зоны. Внутри жилой зоны можно выделить земли занятые индивидуальным жильем и многоквартирными домами различной этажности. Можно также выделить центр поселения (если он выражен) и другие функциональные его зоны. Выбор характеристик внутреннего профиля зависит от специфики муниципального образования. Для городского округа важны площади зеленой зоны, застроенной площади, земель для транспорта, развития промышленности и других видов экономической деятельности.

Для сельских районов на первый план выходит взаиморасположение и людность поселений, состояние дорожной сети между ними. На уровне сельских советов актуальными остаются эти же вопросы, кроме того – доступность объектов социальной инфраструктуры – школ, муниципальных учреждений (больниц, ФАПов, аптек, клубов) и т.д.

Внутренний профиль образуют также исследования таких проблем, как развитие транспорта, ЖКХ и экологии. В данном случае среди перспективных проектов рассматриваются те из них, которые реализуются на территории МО в интересах его населения. Это их сближает с социальными проектами, реализуемыми в границах МО.

Внешний профиль пространственной характеристики МО включает анализ их расположения относительно центров роста, экономической оси и каркаса территории, значимых природных объектов, включая наличие природных ресурсов, а также коммуникационных сетей (автомобильных и железных дорог, речных, морских путей, крупных трубопроводов).

Относительно городов в последние годы выделяют административный, бизнес-ориентированный и социально-ориентированный типы. Административный тип развития городов распространялся в годы социалистического строительства. На основе концепции «Соцгорода», разработанного в довоенный период, в Башкирии были построены следующие города: Салават, Ишимбай, Мелеуз, Кумертау, Октябрьский, Нефтекамск и Дюртюли. Из них Ишимбай, Октябрьский, Нефтекамск и Дюртюли были построены, чтобы обслуживать нефтедобычу. В данном случае города создавались согласно единому народнохозяйственному плану, для предприятий и при предприятиях. При такой концептуальной основе градостроительства ведущую роль в определении судьбы города играли институты планирования. Развитие шло согласно генеральным планам развития, использовались методы функционального зонирования территорий, нормирования городского пространства.

Бизнес-ориентированный тип развития городов предполагает развитие города на основе градорегулирования, когда все решения по пространственному развитию принимаются альтернативно. Развитие происходит на основе утвержденных правил землепользования и застройки.

Социально-ориентированный тип развития городов предполагает градостроительство на основе конценсуса интересов власти, бизнеса и населения.

Мы считаем – будущее за бизнес и социально-ориентированной моделью развития городов, что больше соответствует конституциональным нормам экономики (социально-рыночной модели). В данном случае важны разработки механизмов согласования интересов основных заинтересованных лиц.

Одним из основных направлений в изменении системы расселения населения является формирование городских агломераций. В обществе не осталось без внимания предложение бывшего вице-премьера Российской Федерации А.Кудрина об объединении городов Казани, Ульяновска, Самары и Саратова в одну агломерацию.

Городская агломерация – это скопление населенных пунктов, преимущественно городов, которые объединяются в многокомпонентную систему с интенсивными транспортными, культурными и экономическими связями.

В различных странах приняты различные критерии разграничения агломераций. Чаще всего это:

– наличие общих границ поселений;

– превышение застроенных территорий площадей сельхозугодий и лесов;

– маятниковые миграции в размере 10–15% трудоспособного населения.

Не учитываются:

– самодостаточные города;

– поселения, не имеющие транспортную связь;

– расстояния между поселениями;

– административно-территориальное деление.

В Стратегии социально-экономического развития Республики Татарстан до 2030 года, утвержденной законом РТ от 17.06.2015 г., в республике выделены три агломерации: Казанская, Камская и Альметьевская. В Стратегии отмечено, что Альметьевская агломерация формируется за счет муниципальных районов: Альметьевский, Лениногорский, Бугульминский и отчасти Азнакаевский.

Ютазинский и Бавлинский, благодаря железной дороге Ульяновск–Уфа и автодороге М-5, признаны как зона активного взаимодействия между Республикой Татарстан и Республикой Башкортостан.

В зону формирования Альметьевской агломерации включается также город Нурлат, как территория трансграничного сотрудничества между Республикой Татарстан, Самарской и Ульяновской областями.

Кроме вышеназванных МО, в зоне влияния г. Альметьевска – центра агломерации – находятся Сармановский, Черемшанский, Аксубаевский и Новошешминский, Заинский районы. Ядрами Альметьевской агломерации признаны города Альметьевск, Бугульма и Лениногорск, находящиеся в часовой транспортной доступности друг от друга.

В Стратегии признается особая перспектива в развитии Ютазинского и Уруссинского районов в связи с возможным строительством международного транспортного коридора «Европа – Западный Китай».

Стратегия развития Республики Башкортостан до 2030 года, одобренная Правительством РБ 13.12.2017 г., к сожалению, не содержит таких разработок по пространственному развитию, как Стратегия Республики Татарстан. Некоторую ясность в решение пространственных проблем Западного Башкортостана вносит Стратегия развития г. Октябрьского на период до 2030 г., в которой говорится о формировании Октябрьско-Туймазинской агломерации.

В ходе работы над стратегией развития г. Октябрьского выявилась тесная взаимосвязь экономики города с Уруссинским и Ютазинским районами, в перспективе – с Альметьевским.

До сих пор развитие агломераций рассматривается в рамках административных границ регионов, тогда как их формирование происходит под воздействием рыночных факторов, которые не знают границ, ни государственных, ни административных. Так, крупнейший мегаполис Европы Стамбул, в свою периферию включил большие территории Болгарии и Греции. На наш взгляд, выделяемая Альметьевская агломерация своим продолжением на территории Республики Башкортостан имеет город Октябрьский, Туймазинский и Белебеевский районы. Сюда можно включить и Бижбулякский, Ермекеевский, Буздякский, Бакалинский районы. Тогда предлагаемая к признанию агломерация будет иметь следующие очертания (рис.1).




Рисунок 1. Состав Альметьевско-Октябрьской агломерации.

В этом случае можно выделить два центра агломерации: г. Альметьевск – в западной части региона и г. Октябрьский – в восточной.

Численность населения агломерации в предлагаемых границах составит около 1,0 млн. чел., что позволяет в ней создать весь комплекс учреждений сферы услуг. Так, в настоящее время важную роль в транспортном обслуживании населения играет наличие международного аэропорта. Первым шагом в укреплении агломерационных связей могло бы стать превращение аэропорта г. Бугульма в международный. Вторым – создание сети автобанов, соединяющей города агломерации.

Требуется координация между муниципальными образованиями, образующими агломерацию, в развитии профессионального образования и здравоохранения, прежде всего – в развитии технически сложных медицинских услуг.

Важнейшими направлениями координации МО внутри агломерации могут стать развитие туризма, утилизация ТБО, специализация в производстве продуктов питания, разработка новых технологий нефтедобычи.

Делом первостепенной важности скоро встанет и создание мощнейшего логистического центра в уже упомянутом транспортном коридоре «Европа – Западный Китай». Если Башкортостан и Татарстан начнут конкурировать между собой в его создании, то проигрыш может быть общим.

Башкортостан и Татарстан могли бы сотрудничать в области пространственного развития не только в рамках предлагаемой к формированию агломерации. Другим направлением сотрудничества в пространственном развитии могло бы стать расширение Камской агломерации на север-восток, включив в ее состав города Нефтекамск, Агидель, Янаул и прилагающие районы. Важной частью Камской агломерации могли бы стать также города Ижевск, Сарапул и прилегающие к ним муниципальные районы Удмуртии.

На пути формирования межрегиональных агломераций существуют следующие преграды:

– несовершенство федерального законодательства, не предусматривающего развитие таких образований;

– отсутствие опыта положительного решения межмуниципального сотрудничества на межрегиональном уровне;

– низкий уровень научной проработанности проблемы.

Формирование Альметьевско-Октябрьской агломерации будет происходить в следующих условиях:

– расстояние между центрами агломерации: Октябрьским и Альметьевским составит 107 км, между Октябрьским и Бугульмой – 71 км, между Альметьевским и Бугульмой – 56 км.

К Октябрьскому прилегают Туймазы (23 км), Ютазы (24 км), Бавлы (26 км), Уруссу (16 км). Агломерационные связи теснее всего существуют именно между данными муниципальными образованиями.

От Альметьевска эти муниципальные образования отстоят гораздо дольше (Бавлы – 93 км, Ютазы – 95 км, Уруссу – 111 км).

Расстояние между Альметьевским и Нурлатом – 145 км, Туймазами и Альметьевским – 142 км, столько же расстояние между Белебеем и Альметьевском. Как видно, расстояния вполне соразмерны.

От Октябрьского расстояние самого дальнего муниципального района внутри предлагаемой агломерации – Нурлата, составляет – 233 км, от Альметьевска до Буздяка – 194 км.

Через агломерацию проходит железная дорога Уфа–Буздяк–Туймазы–Бугульма–Нурлат–Ульяновск, существуют междугородные автобусные сообщения.

Наш анализ показывает, на сегодняшний день агломерационные связи существуют именно в башкирской ее части. В частности, число автобусных рейсов в день составляет по маршрутам:

– Октябрьский – Туймазы – 91;
– Октябрьский – Бавлы – 15;
– Октябрьский – Уруссу – 30;
– Октябрьский – Бугульма – 10;
– Октябрьский – Альметьевск – 6;
– Октябрьский – Белебей – 8;
– Октябрьский – Азнакаево – 3.

Рейсы из Альметьевска составляют: в Заинск – 6, в Белебей, Буздяк, Сарманово, Бавлы, Туймазы – по 2, в Азнакаево – 3.

Число рейсов в определенной степени характеризует величину миграции людей и тесноты агломерационных связей. Бугульма как центр агломерации заметно уступает по значимости г. Октябрьскому и не может рассматриваться в качестве одного из ее центров, но этот город – важный транспортный узел.

Итак, чтобы использовать агломерационный эффект в интересах населения Республики Башкортостан и Республики Татарстан, необходимо всемерно расширить межмуниципальное сотрудничество в приграничных их территориях. Для этого очень важна позиция органов власти обеих республик.

## Литература:

1. Р. Ф. Гатауллин. Методологические основы разработки проблемы пространственного развития в стратегии муниципального образования

// Инновационные технологии управления социально-экономическим развитием регионов России: Материалы IX Всероссийской научно-практической конференции с международным участием. – Уфа: ИСЭИ УНЦ РАН, 2017. – С. 34-37.

2. Стратегия социально-экономического развития Республики Татарстан до 2030 года [Электронный ресурс] // URL: http://www.invest.tatar.ru/upload/iblock/4f8/zakon-rt-ot-17.06.2015-n40_zrt-ob-utverzhdenii-strategii-rt-2030.pdf.

3. Стратегия социально-экономического развития Республики Башкортостан до 2030 года [Электронный ресурс] // URL: https://economy.bashkortostan.ru/upload/iblock/b5c/proekt-strategii sotsialno_ekonomicheskogo-razvitiya-respubliki-bashkortostan-na-period-do-2030-goda.pdf.

4. Структуризация экономического пространства региона: сущность, факторы, проектирование: монография / под общ.ред. д.э.н., проф. Р. Ф. Гатауллина – Уфа: ИСЭИ УНЦ РАН, 2016. – 216 с.

5. Электронный ресурс. Globuss24.ru. Режим доступа: http: doc|prostranstvennye-zakonomernosti-ekonomiceskogo-razvitia

6. Электронный ресурс. Dislibi.ru. Режим доступа: http: ekonomika/1227-1metodi-analisa-regulirovaniya-prostranstvennogo-razvitiya-goroda.php.

**Төбәк тарихы буенча фәнни мәкаләләр/ Научные публикации по краеведению.**

## БЕР ШӘҖӘРӘ АРТЫННАН

*Д.М.Исхаков*

Пермь якларында яшәгән һәм әдәбиятка «пермь татарлары» дип йөртелүче милләтебез эчендәге бу этнографик төркемнең тарихы бик кызыклы һәм әле күп яклардан өйрәнелеп бетмәгән. Хәлбүки, бу як татарларына багышланган хезмәтләр шактый гына булса да. Нәкъ менә пермь татарларының урта гасыр тарихын яңадан барлап чыгу өчен без язмада шушы төркемгә кагылышлы инде фәнни әйләнешкә кертелгән, ләкин чынлап торып анализланмаган бер шәҗәрәгә тукталып китәргә булдык. Сүз танылган татар драматургы Риза Ишморатның әнисе ягыннан (әнисенең исеме Фәрхесрур, 1870-нче елгы) килгән нәсел җебе турында бара. Үз чиратында бу шәҗәрә 1955-нче елны ук Муллахмәт Ильяс улы Атнабаевтан, ягъни, әнисенең атасы Шәһимәрдән бабасының бертуган энесеннән, күчереп алынып, хәзерге Башкортостанда урнашкан Урады һәм Күрдем авыллары халкына карый. Элекке административ бүленеш буенча бу авыл Уфа губернасы Бөре өязенә кереп, пермь татарларыннан көнъяктарак урнашкан булган [Ишморат, 1987: 45 б.].

***Башта шәҗәрәне китерик:***

Фәрхесрур – Шаһимәрдән – Калимөхәммәт (Күрдем авылыннан) – Атнабай – Күчем – Акегет – Җермәк – Истәк – Кармыш – Турбай – Кара Җау – Сөндык би – Сүнчәле би – Үрдәк би – Алманчык би - Бүркыт би (шәҗәрә башы).

Р. Ишморат күрсәтеп үткәнчә, ул күчереп алган шәҗәрәдә, дөресрәге шул язылган дәфтәрдә, тагы бер өстәмә булган. Хәзер ул өстәмәне дә бирәбез.

«Бүркыт биләр [,] Чыңгыз хан иде. Синең агачың чаган, кошың-һөдһөд, тамгаң әмзәдер. Төбәгебез Аудуак төбәге. Түбәнге кисәк Туктамыш аймагы, дип язылгандыр. Ике аймагыбыз Аккүз дип язылгандыр. Бер Уртавыл аймак Янбарысның би нәзер бер аймаклар бәяны».

Шушы китерелгән өстәмәне тикшерә башлаганчы, аңа кайбер аңлатмалар кирәк булыр.

Беренчедән, шәҗәрәгә өстәмә рәвештә бирелгән сүзләр татарларда киң таралган «Дәфтәре Чыңгыз-намә» (XVII йөз ахры) әсәреннән алынганга охшый. Нәкъ шул әсәрдә Чыңгыз хан турында сөйләнеп, мондый

сүзләр әйтелә: «Ул биләрнең һәркайсына хөрмәт күрсәтеп урын-җир, илкөн бирде.., тамга, кош, агачын, урыннар бирде, халыклар итеп аерды» [Дәфтәре Чыңгыз намә, 2011: 51 б.]. Шунда ук мондый юллар да бар: «Аннан соң хан янә әйтте: – Әй Буркит би, синең агачың чаган булсын, кошың һөд-һөд булсын,ораның буруҗ булсын, тамгаң һәз булсын, сыйфаты шушы» [Дәфтәре Чыңгыз намә, 2011: 53 б.]. Шулай ук, икенчедән, монда төбәк (чынлыкта – «түбә») дип язу да игътибарга лаек, чөнки ул кабилә-ыру җирләрен һәм халкын бүлү белән бәйле. Димәк, «Аудузак төбәге» берничә кисәктән (аймактан) торган: Туктамыш төбәге, ике аймак – Аккүз исемле. Ләкин соңгы җөмләдәге «Уртавыл аймагы» шушы аймага кергәнме, бик үк аңлашылып бетми, чөнки күрсәтелгән шәҗәрә язылган(төп авыл – Күрдем булса кирәк) җирләрдән ерак түгел Янбарыс авылы булганлыгы билгеле [Ишморат, 1987: 355]. Бу дүртенче аймак шул авыл исеме беләнме, әллә шушы авылга исем биргән «Янбарыс би» исеме беләнме аталганмыдыр, бусы билгеле түгел. Һәрхәлдә, соңгы җөмләнең мәгънәсе бозылган.

Иң әһәмиятлесе без карап үткән шәҗәрәнең Буркыт бидән башлануы. Аның кем булганлыгы мәсьәләсен карый башлаганчы безгә тагы кайбер башка мәгълүматларга да тукталып китү кирәк. Беренче чиратта сүз татар язучысы Н.Фәттахта сакланган, аннан соң мәрхүм тарихчы Ә.Булатовта булган 1950-нче елларда күчерелгән тагы бер шәҗәрә турында бара [Әхмәтҗанов, 2011: 205 б.]. Ахрысы, ул югарыда китерелгән шәҗәрәнең бер варианты булса кирәк:

Чыңгыз хан – Бортек би – Алманчык би – Исәнбай би – Урдәк би – Сәйед би – Сүнҗәле би – Шондык би – Уразбахты – Калай

– Карҗау – Тулбай

– Туктамыш

– Җанҗегет

– Карамыш

– Мачтык һ.б. Алдагы буыннарда Истәк, Җәрмәк, Акъегет, Күчем исемнәре күренү шул турыда сөйли.

Шулай ук, соңгы шәҗәрәне тикшергәндә, анда күренгән «Туктамыш» (XII буын), «Аккүз» (XIII буын) буыннарының түбә (төбәк) бүленеше белән бәйле булуга мөмкинлеген дә әйтеп үтә кирәк. Бу мәсьәләгә без әле алга таба әйләнеп кайтырбыз.

Хәзер инде безгә шушы шәҗәрә материалларына таянып ул барлыкка килгән төбәккә бәйле тарихи җирлек мәсьәләсен тикшерү кирәк булачак.

Билгеле, иң беренче безнең игътибар Бөркет/Буркат/Бортек (кайбер очракта бу исем бераз бозылган) би исеменә юнәлтерелергә тиеш, чөнки бу очракта ул эпоним, ягъни, этнонимны чагылдырган атама буларак

бирелә. Әйтергә кирәк, Уфа губернасының элекке Бөре өязе җирлегендә язып алынган бу атама ул якларда тагы да кабатлана. Мәсьәлән, Башкортстанда яшәгән күренекле татар этнографы Р.Г.Кузеев үз вакытында башкортлар эчендәге канглы ыруы шәҗәрәсендә булган Тарагай би исемле шәхеснең «Кара диңгез, Кырым» якларыннан килүен күрсәткән иде[Кузеев, 1974: 359]. Шушы ук бинең исеме тагы бер шәҗәрәдә күренә – бу юлы сүз башкортларның шәмшәдин ыруы шәҗәрәсе турында бара. Анда Буркат бинең улы Таргай бинең «Кырымнан килеп Ак Идел буйлап баруы», турында әйтелә [Фаттахутдинова, 1985:108-109]. Күренә ки, бу ике шәҗәрә бер-берсе белән бәйле һәм сүз канглы төркеме турында, яисә ул төркем белән бәйле башка бер ыру-кабилә турында бара (атамасы – шәмшәдин, ахрысы, соң дәвердә генә барлыкка килгән һәм Шад /Шәд авылы исеме белән бәйле).

Тарихи чыганаклардан чыгып эш итсәк, төп атама булган Боркыт/Бөркет эпонимы артыннан бару кирәк, чөнки аның артында боркыт/бәргут кабиләсе яшеренгән. Канглы кабиләсе дә борынгы дәвердә ул төркемгә бәйле булган ахрысы. Ләкин, иң кызыгы шунда, бу ике төркем дә монголлар көчәю дәверенә кадәр Урал буйларыннан, шулай ук легендаларда искә алынган Кара диңгез, Кырым тирәләреннән бик еракта, Үзәк Азия якларында яшәгәннәр. Бу мәсьәләне тикшерер өчен безгә тагы бер тарихи чыганакка мөрәҗәгать итү кирәк. Сүз 1504-1510нчы елларда Урта Азияда язылган «Тәварих-и-гузида-йи нусрат-намә» әсәре турында бара. Анда әйтелгәнчә, «Шибан хан (ягъни Җучиның улы, Чыңгызның оныгы) Болгарны, Руссларны, Асларны явлап алганда һәм башкортлар белән сугышта зур батырлык күрсәтә». Бу вакытта аның кулы астында 40 меңлек гаскәр булып, аларның «башлыкларының атлары [мондый булган]: кыйат Бурулдай бик, бәсә конгратдин [Гали] бик [әбүгәсе], боркыттан Тайбуганы, төмәннән Тукбуганы», әйтеп китә бу чыганак [Таварих-и, 1967:115].

Шибанның һәм алда искә алынган Бурулдайның (ул төмән, ягъни 10 мең сугышчы булган хәрби берәмлек башында торган) Бату белән бергә Болгар дәүләтен яулап алуда, «буларлар(болгарлар-Д.И.) һәм башкортлар» белән сугышта катнашуын фарсы тарихчысы Рәшид-әд-Диндә дә искә алына. Соңыннан алар урыс кенәзлекләрен яулап алалар һәм аннан Кырым төбәгендә дә булалар. Берникадәр вакыт бу Шиабан җитәкчелегендәге гаскәр Кырымга якын җирләрдә 1236–1237 елгы походтан соң да кала. Әйтик, Тукбуга (Төмән кабиләсе гаскәре башлыгы, ул атамадан «Тамань» һәм хәзерге Мордовия Республикасындагы «Төмән» шәһәре исеме килеп чыккан дип уйларга урын бар) Кырым тирәләрендә әле 1264–1265нче еллар тирәсендә дә күренә. Ләкин, кайсыдыр бер дәвердә Шибанның элеккеге гаскәре Кырым якларыннан Урал буйларына, тө-

гәлрәге, Шибанга бирелгән элекке Болгар дәүләтенең көнчыгышына һәм тарихи «Башкардия» яисә «Magna Hungaria» (монда «magna» латинча «зур» дигәнне түгел, ә «ерак» дигәнне аңлата) җирләренә, шулай ук Көнбатыш Себер җирләренә кире кайтып китә [Исхаков, 2016].

Нәкъ менә шушы гаскәрнең бер өлеше булган боркыт кабиләсенең кисәкләрен без Боркыт би исеме астындагы инде соңгы заманнарда татар телле башкортларга әйләнгән халыкны төнъяк-көнбатыш Урал регионында күзәтәбез дә. Әйтелгәнчә, ул төркем вәкилләрендә бабаларының «Кырымнан» күчүләре турындагы риваятьләр сакланган. Билгеле, төпкә төшеп карасаң, бу Боркыт бигә бәйле кабилә-ыру вәкилләре (кәнглы, шәмшәдин илләре кешеләре) тарихи яктан башкорт булмаганнар. Кайсы җирләрдән чыкканнар соң алар? Бу сорауга җавап эзләгәндә безгә беренче чиратта боркыт/баргут дип аталган кабилә турында сүз алып барырга кирәк.

Үз вакытында Хива ханы Абел – Газый Баһадир (XVII йөз) Боркыт, Барын һәм Курлавытны бер-берсенә бертуган булган һәм Дурбан исемле кешедән туган шәхесләр ди(бу исә, алдагы өч атама төсле ук эпоним) һәм алар монголдан булган дип язган иде (Әбелгазый Баһадир хан, 2007; 47). Ләкин бу караш чынлыкта ялгыш. Фарсы тарихчысы Рашид-әд-Дин Байкал күленнән көнъякта, Селенга елгасы тирәсендә яшәгән баргуд кабиләсен белә(Баргузен дигән атама да шуңардан килә), аларның «монгол» дип атала башлавын да әйтә, ләкин иң баштагы монголлар рәтенә аларны кертми [Рәшид-әд-дин, 1952, т.1. кн.1: 156] һәм бу бер дә юкка түгел, чөнки борынгы дәвердә бу кабилә төрки булган (исеме «байркы» атамасыннан алынган [Парунин, 2012:132-133]. Дөрес, монгол яулап алуларыннан соң (1207 ел) бу «урман халыклары» рәтендә саналган кабилә Җучи олысына кертелә һәм монголларга буйсына (бигрәк тә ул төркем монголларның конграт кабиләсе белән якыная, алар белән кыз биреп кыз алышу аркылы).

Менә шул заманнардан башлап баргут/боркыт кабиләсе Җучи олысында яши башлый һәм аның улы Шибан (Җучи үзе 1227-нче елда үлә) кул астына эләгеп, 1230-нчы еллардагы Монгол дәүләтенең көнбатышта булган «бөек походларында» катнаша [Карагыз: История и культура татар, 2015: 122-157]. Шулай итеп, Үзәк Азияда (Байкал – Селенга тирәләрендә) яшәгән кабилә көнбатышка китә. Соңыннан, XV гасырда, боркытлар башында Абул-Хайр хан торган Шибанилар дәүләтендә гел искә алыналар. Ә бу дәүләткә Урал буйлары һәм Көнбатыш Себер генә түгел, ә Болгар вилайяте дә буйсынган (1429–1430-нчы еллар тирәсендә) [Парунин, 2012: 135-136; Исхаков, 2013: 29-30]. Себер йортында бер заман хөкем иткән (XV йөзнең ахыры – 1563-нче еллар) «Себер кенәзләре»

исеме астында билгеле булган Тайбугидлар нәселе дә (нәсел башы Шибан гаскәрендә булган Тайбуга бигә барып тоташкан) боркыт кабиләсеннән булган [Исхаков, 2009:]. Шушы фактларны исәпкә алганда без башка тарихи мәгълүматларны да аңлата алабыз.

Әйтик, югарыда китерелгән Буркыт бидән башланган Р.Ишморатның анасы ягыннан булган шәҗәрәдә мондый исемнәр бар: Кара җау, Сондык би, Сүнчәли би. Бу шәҗәрәдәге исемнәр Пермь өлкәсе татарлары белән дә бәйле. Кара җау атамасы топоним буларак Карьево (татарча-Караҗау) авылы исемендә сакланган. Ә бу авыл XVII йөз башында Сылва (Сөлил) һәм Ирән елгалары бассейнында яшәгән иштәк («остяк») төркемнәренең Көнгер өязенә кергән улусы үзәге («Карьев улус») булган. Сондык исә «Зевендук» исеме астында Тулва елгасы янында яшәгән (хәзерге Барда районы) гайнә «башкортлары» «остяклар» башында торган «начальник» буларак билгеле (Изге Трифон язмаларында исеме күренә, 1570-нче елларда). Үз чиратында бу шәхес XVI йөздә яшәгән «муллин» остяклары башында торган(хәзерге Барда районы Куян һәм Башкултай авыллары халкы бабалары) Урак би Мәмәткколовның энесе булып чыга һәм иң кызыгы, бу төркемнең кабилә билгеләре инде безгә билгеле булган боркыт кабиләсенәнә туры килә. Ләкин ул туры килү фәкать тик шушы бәкләр нәселе белән генә бәйле [Исхаков, 2014].

Шулай итеп, Уралга Урал буенда яшәгән татар-башкортларының шәҗәрәләре аркылы без аларның борынгы бабаларының бер өлешенең Үзәк Азия ягыннан килгән монголлар рәтендә булган төркиләр белән бәйләнгәнен күрәбез. Шулай ук Урал тауларыннан көнбатышка таба яшәгән төрки төркемнәренең (татарлар һәм башкортларның) себер татарлары белән этник туганлыгы да күренә бу очракта. Ул туганлыкның бер катламы Җучиның улы Шибан белән бәйле кабиләләргә барып тоташа. Шуңа күрә Көнбатыш Себер һәм Урал буйларындагы төрки-татарларының урта гасыр тарихларын шушы кысаларда карарга кирәк.

## Әдәбият:

1. Дәфтәре Чыңгыз намә//Мирастан биш сәхифә: XVII–XIX гасырлар әдәби-тарихи ядкарләре/ [транскр.эшләүче, хәзерге татар әд.теленә күчерүче, иск. һәм сүзл. төз., кереш мәкаләләр авторы С. Гыйләҗетдинов]. Казан: Татар.кит.нәшр., 2011.

2. Д. М. Исхаков. К вопросу о западных пределах Улуса Шибана и его потомков//История, экономика и культура средневековых тюрко-татарских государств Западной Сибири. Материалы II Всероссийской научной конференции.Курган, 17–18 апреля 2014 г.Курган: Из-во Курганского гос. ун-та, 2014. – С. 28-31.

3. Д. М. Исхаков. Между Булгаром и Казанью: Этнополитические процессы в Булгарском/Казанском вилайяте в 60–70-х годах XIV – 40-х годов XV веков. Казань: Изд-во «Фэн» АН РТ, 2013.

4. Д. М. Исхаков. Новые данные о клановой принадлежности «Сибирских князей» Тайбугидов//Сибирский сборник.Вып.1.Казань: Из-во «Яз», 2014.-С.236-243.

5. Д. М. Исхаков. Труды по исторической этнологии татарского народа.Т.1 Среднетюркская эпоха (X–XV вв). Казань: Ин-т истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2016.

6. История и культура татар Западной Сибири. Монография. Казань: Ин-т истории им. Ш. Марджани Ан РТ, 2015.

7. Р. Ишморат. Тарих сукмаклары. Истәлекләр. Казан: Татар.кит. нәшр., 1987.

8. Р. Г. Кузеев Происхождение башкирского народа. Этнический состав, расселение. М.: Наука, 1974.

9. А. В. Парунин. Клан баргут/буркут в политической истории чингизидских государств XIII–XVI вв. // Средневековые тюрко-татарские государства. Вып.4. Казань. Ин-т истории им.Ш. Марджани АН РТ, 2012. – С.131–143.

10. Рашид-ад-Дин. Сборник летописей. Т.1.кн.1.М.:НИЦ «Ладомир», 2002.

11. Таварих-и-гузида-йи нусрат-наме/ Исслед.крит.текст, аннот., оглав. и табл.свод. оглав. канд.филол.наук А. А. Акрамова. Ташкент: Фан, 1967.

12. А. Фаттахутдинова. Башкирские шежере (Краткое археографическое описание)//Башкирское шешере (Филологические исследования и публикации). Уфа: БФ АН СССР, 1985.- С .88-125.

13. Әбелгазый баһадир хан. Шәҗәрәи төрек. Казан: Татар.кит.нәшр., 2007.

14. М. И. Әхмәтҗанов. Татар шәҗәрәләре. Беренче том. Казан: Г. Ибраһимов исемендәге ТӘСИ, 2011.

## УБИЙСТВО ГАЙНЕТДИНА АЛЬ БУЛГАРИ
## (Протоколы Зайнуллы Ибрагимова)

***Р.К.Валеев***

28 февраля 1918 года при активной помощи казанских большевиков произошло одно из самых грязных и трагических провокаций убийство лидера Ваисовского движения, боровшихся под знаменем ИСЛАМА за «Справедливость и Правду». История этого движения ныне активно изучается появляются все новые документы и материалы, которые проливают свет на события, имевшие место в Казани в конце февраля и в начале марта 1918 года.

Известно, что Вошуро/Харби Совет-Р.В./, выполняя решения Уфимского Национального собрания и Второго съезда воинов мусульман России на 1 марта 1918 года назначило провозглашение «Урало-Волжских штатов». Однако, казанские большевики, ведущие тайную войну против провозлашения» Урало-Волжского штата», в ночь на 28 февраля арестовали руководителей Второго съезда воинов мусульман. Это привело к чрезвыйчайному осложнению и без того непростой ситуации в Казани. Обострились отношения между Казанским Советом и делегатами Второго съезда и их руководителями. По предложению Мирсаида Султангалеева было принято решение арестовать 10 человек руководителей съезда с целью срыва провозглашения 1 марта 1918 года «Идел-Урал штата».

В 1923 году М. Х. Султангалеев подчеркивая написал большое письмо членам Центральной контрольной комиссии из тюрьмы, свои заслуги перед Советской власти. Касаясь казанских событий он писал: ***«Было созвано экстренное совещание Губкомитета большевиков с участием меня и Саид-Галиева. Был поставлен вопрос как быть?... Я предложил не допускать объявления националистами штата и как предупредительную меру предложил… арестовать руководителей движения. Совещание со мной согласилось.***

***И так как в нашем распоряжений имелась лишь одна ночь, было решено аресты возложить на меня и т. Саид-Галиева»*** (См. Мирсаид Султан Галлиев. Статьи, выступления, документы. Казань, 1992. -С.421–422).

В этот период ваисовцы поддерживали сторонников Советской власти, считая, что они тоже ведут борьбу за справедливость, за освобождение народов. Антивсоветски настроенная часть населения выступала как против большевиков, так и против ваисовцев. Однако в силу каких-то

причин удар был нанесен именно по ваисовцам – был убит их руководитель, который боролся за возвращение Булгарского государства. Он не был согласен с проектом провозглашения «Идел-Урал штата» и вел борьбу за провозглашение республики под названиемя «Булгарская республика»

До сих пор историки не могут ответить на вопрос: Кто же виновен в смерти Гайнанутдина Ваисова Аль-булгари. Появление новых документов, материалов и их анализ помогут в выяснении истинных причин гибели Гайнанутдина Ваисова. Предлагаем протоколы допроса одного из соратников Гайнанутдина Ваисова – Ибрагима Зайнуллина от 5 марта 1918 года и 31 октября 1919 года.

Ибрагим Зайнуллин Аль булгари был жителем г. Казани. Жил в Ново-Татарской слободе, Мало Симбирской улицы дом № 10. В эти дни он исполнял роль начальника караула. Они охраняли руководителя движения ваисовцев Гайнанутдинса Ваисова Аль-булгари. В день убийства он пришел к нему часов в 9 утра и позже стал очевидцем произшедших здесь событий.

Он являлся также членом президиума Совета в числе 12 человек, избранных съездом «волжских булгарских мусульман рабочих и хлебопашцев», являлся бессменным зместителем Гайнанетдина и некоторое время и Газизяна Ваисова. И лишь после смерти Сардара и, особенно в 20-е годы XX века, он постепенно отходит от этого движения и работает на различных должностях при советской власти в Республике Татарстан.

Протоколы допросов Ибрагима Зайнуллина – одного из близких соратников Гайнанетдина Ваисова, имеют большое значение для изучающих историю ваисовского движения и истории РТ.

***Протокол допроса Зайнуллы Ибрагимова аль Булгари.***

1918 года марта 5/февравля 20/ дня члены комиссии Родионов, Богданов, Арзамасцев, снимали показания с очевица убийства Сардара Ваисова свидетелей Ибрагимова Зайнуллы Булгари и Мубаракша Гадельша Булгари. Спрошенный по сему делу Ибрагим Зайнулла Булгари, уроженец города Казани, живущий в Ново-Татарской слободе, Мало Симбирской 2-й переул., дом № 10 показал:

28 февраля в 9 часов утра я пришел к Сардару Ваисову. Он был занят у себя в спальне, составлял доклад. Я с ним поздаровался, он спрашивал меня, нет ли каких-либо новостей, но я отвечал, что пока новостей никаких не имею вышел только из дома. В это время раздался звонок, я отпер дверь – это пришел другой член нашего общества

Хайрутдин Валиулла, он рассказывал, что на базаре возмущается народ, закрывают все лавки, говорят про арест членов Шуро. Я пошел и сообщил об этом Сардару. Сардар говорит, что это (слово не ясное – Р.В.) пусть они волнуются в это дело вмешиваться не будем. В это же время меня Сардар попросил справиться по нашему телефону в мусульманский комиссариат об аресте членов Шуро. Я позвонил туда по телефону мне ответили, что действительно некоторые члены Шуро арестованы.

Я сообщил об этом Сардару, то действительно члены Шуро арестованы. Сардар говорит по этому поводу, что если они продолжали штат не таким путем каким следовало, они нам не в пример, с нами идти вместе не хотели и нет ничего удивительного, что их арестовали.

Затем Сардар опять продолжал заниматься. Минут через пять после этого вошел в дом новый член нашего общества – старик лет 60 Гиззатулла Гатаулла-оглы. Он рассказывал, что около Юнусовской площади собирается народ и волнуется по поводу ареста, а некоторые угрожают нам – лица которые угрожали нам вели разговор этот около окружного комитета. Гиззатулла также зашел к Сардару, рассказал ему о волнениях на улице. Во время нашего разговора снова раздался звонок. Я пошел и отпер дверь – вошел член окружного комитета, как он об этом заявил, пришел по поводу сегоднящних событий и велел о себе должить Сардару. Я сообщил об этом Сардару, который просил проводить пришедшего в кабинет и сам вышел туда же. Член окружного комитета Юсупов стал разговаривать с Сардаром о событиях в городе и спрашивал его какой его Ваисова взгляд на арест членов Шуро. Сардар отвечал ему, это конечно и для него неприятно. Мы хотели найти соглашение, объединить всех мусульман, мы делали свой доклад в Московский российский мусульманский съезд. В Казани в последнее время военному съезду также делали доклады, но с нами не соглашались, а теперь в такое тревожное время вы приходите ко мне и просите помощи и оружия, но оружие у нас не для братоубийства, не для кровопролития, а воспользуемся им мы только в том случае, если будет контрреволюция.

После всего этого член окружного комитета спросил Сардара – значит вы не идете против Советов? Сардар отвечал, что да мы не пойдем против Совета. Юсупов после

этого ушел. Во время разговора Юсупова с Сардаром входил в квартиру к Ваисову Ибрагимов, нач. милиции 5 гор. и сказал мне, сегодня за амуницией зашли к нему в интендантство, после чего он вышел, Юсупов немного после этого закончил свой разговор с Сардаром Ваисовым, я проводил Юсупова на парадное крыльцо вновь обратно…зашел к Сардару, говорили с ним опять о случившимся, Сардар говорил, что вот не слушались меня и «получились» такие события. В это время вновь раздался звонок-пришел опять Ибрагимов и говорил, что сегодня не ходите в интедантство, меня там не будет, сегодня важное дело есть.

Н. А. Томилов, опираясь на данные лингвистов, подчеркивает, что для языка заболотных татар характерно наличие в говоре древнетюркского субстратного слоя кыпчакского типа, восходящего к языку тюрков орхонских и таласских надписей. И это, как считает ученый, говорит о значительной древности данной группы [Томилов: 1981: С.97]. У заболотных татар мы обнаруживаем сходные черты, не сохранившиеся у многих групп сибирских татар, но присущие другой группе сибирских татар – барабинским татарам, обитающим на значительном расстоянии от заболотных – на территории Новосибирского Приобья. Данное обстоятельство, на наш взгляд, может говорить о некоем общем древнетюркском субстрате, легшим в основу формирования этих групп [Тычинских: 2016 а].

Многочисленные легенды, сохранившиеся в исторической памяти заболотных татар, рассказывают о древней истории насельников края. Жители Заболотья до сих пор могут показать кладбище маленьких людей – сыпыров – размером с рукавичку, которые могли поместиться в глиняном горшке, места, где проходили войны татар с сыпырами, где находились землянки Сангыра и Мангыра, могила Илак(Илек) алыпа, место амбара, где держал своего крылатого коня Яик бай [Тычинских: 2016 а].

В преданиях мы находим и информацию о древних занятиях жителей Заболотья. Так, одно из них рассказывает о первых насельниках края: «Два старика, у одного из них был сын, а у другого дочь, приплыли к этим местам. Один из стариков поставил шалаш. Есть было нечего. И тогда один старик вместе с сыном доехал до озера, где убил чирка, нашли они там утиные яйца и с добычей поехали обратно. Когда подъезжали, почувствовали запах. Подумали, что пока их не было, умерла от голода старуха-мать. Но на деле было так: старуха пошла в сторону Ишменево, где обнаружила копанку, в которой плавало много язей. Она руками повыкидывала их на берег и натопила крынку масла, запах которого и послышался старику с сыном. Затем они загородили это место. Так появились запоры.

А вторая семья поехала в сторону дер. Ишменево. Они там стали сеять, а хлеб убирали железякой, от которой потом пошли серпы. Из зерна изготавливали болтушку, которую и ели. Эти две семьи обменивались продуктами, построили жилища, а затем и породнились. Так и пошли здесь первые жители» [Тычинских: 2016 б]. Как видим, в легенде отразилось давнее присутствие в традиционной хозяйственной культуре заболотных татар не только присваивающих отраслей, но и производящих, в т.ч., земледелия.

В целом традиционное хозяйство сибирских татар было комплексным и базировалось на таких отраслях, как скотоводство, земледелие, охота, рыболовство и собирательство. Вариации хозяйственного комплекса зависели, прежде всего, от среды обитания, ландшафта, климатических факторов и были традиционными в той или иной местности.

Территория расселения сибирских татар находится в зоне умеренно-континентального климата. Жизненной средой части сибирских татар Тюменской области является природный комплекс, для которого характерна заболоченность и заозеренность. Ландшафт территории во многом предопределил хозяйственную деятельность народа, поселившегося в этих местах, которая традиционно базировалась на рыболовстве, охоте, собирательстве.

Рассмотрим традиционный рыболовный промысел заболотных татар, используя материалы полевых исследований, собранных в ходе экспедиций к заболотным татарам в течение ряда полевых сезонов (1986–1990 гг., 2013–2015 гг.).

Экологические условия Заболотья открывают широкие возможности для занятий рыболовством. Рыболовный промысел на исследуемых территориях ведется во всех водоемах: озерах, реках и старицах. По территории края протекают реки Носка, Алымка, Лайма и др. На территории Тобольского района находится 88 озер, из них свыше 50 – в Тобольском Заболотье в Ачирском и Лайтамакском сельских поселениях. Многочисленные озера Заболотья носят татарские топонимы: Ецка-куль, Тарьяга куль, Артке куль, Сагыслы куль, Каинтар куль, Цой куль, Кашкаин куль, Митерле куль, Имтря куль (Андреевское) и многие другие.

Промысловая ихтиофауна Заболотья представлена такими видами рыбы, как карась – *«табан»*, язь – *«опты»*, щука – *«цорагай»*, окунь – *«алвыга»*, чебак – *«цабак»*, налим – *«курты»*, сырок – *«сирюк»* и др.

Для заболотных татар был характерен тип хозяйственного комплекса с доминирующей ролью присваивающих отраслей. Круглогодичное занятие рыбным промыслом определяло хозяйственный цикл заболотных татар.

Для зимнего периода – с середины ноября до середины марта – был характерен подледный лов. Лед долбили пешней, затем, по заготовленным лункам длинным шестом протягивали невод. Основными объектами лова в этот период были карась и сырок.

Уже с апреля начинается подготовка к новому этапу промысла. В начале мая рыбаки вместе с семьями выезжали на летние озерные поселения. В этот период основными средствами лова служили сети и фитили; объектами промысла – карась, язь.

В конце июня рыба уходила, и в это время ставились запоры. Ловили щуку, карася, язя, линя, окуня, чебака. Основные средства лова в этот период – фитили (на озерах), запоры, сети, котцы, невод. В июле начинался сенокос, «цвела» вода, и к середине июля заканчивался летний этап рыболовства. Следующий начинался в середине августа и длился до октября. Рыбачили в этот период на больших озерах фитилем, неводом, сетками, широко практиковалось запорное рыболовство.

Для зимнего периода, длившегося с середины ноября до середины марта, наиболее характерным являлся подледный неводной лов карася, сырка. На берегах многих озер ставились сезонные рыбацкие поселки или одиночные избушки, где рыбаки вели промысел с весны до середины зимы. Осенью рыбачили на больших озерах на карася, где жили по 3–4 месяца. Карась «стоял» до зимы в садке, который «делают как сруб и ставят на озере».

Садок – *«урек»*, изготавливали часто из тальника делали на озерах. Садки охраняли до тех пор, пока озеро не замерзало. Уже в конце осени, когда начинает замерзать лед, рыбу вычерпывали из садка, складывали в кули и хранили в итлек (амбар).

С апреля начиналась подготовка к новому этапу рыбного промысла. В начале мая рыбаки снова выезжали на летние озерные угодья [Гафурова: 1991].

Традиционными средствами рыбной ловли были невод – *«йылым»*, запор – *«туан»*, сеть – *«ау»*, фитиль – *«пител»*, морды – *«мурта»*, котцы – *«коцэ»*, берекет (разновидность фитиля, отличающаяся от фитиля большими размерами и тем, что его ставят только на реке). Фитили круглогодично использовались при озерном рыболовстве, лишь весной, в период половодья, ставили на реке. Запорное рыболовство было наиболее характерно для весенне-летнего периода. «Рыба приходит в мае, а уходит в июне. Тогда и ставятся запоры» [ПМА]. Запоры ставили на реках, озерах, мелких речках. За ними обычно присматривали. Орудия запорного рыболовства широко применялись в таежной полосе Западной Сибири. Общим технологическим принципом применения запоров было создание естественных резервуаров рыбы в огороженных участках водоемов. Весной и осенью, когда рыба в реках начинала движение либо на нерест, либо на зимовку, в узких местах речных русел устанавливались сплошные запоры. Известно несколько видов запоров. Один из них представлял собой загородки, установленные по дну с обеих сторон реки и длинную морду по центру. Весной морды ставили устьем по течению, а осенью – устьем против течения. Загородки изготавливали обычно из тала. Другой

тип запора представлял собой сплошную загородку и ловушку, установленную у берега. Широко использовались запоры и на озерах.

Однако основными средствами рыболовного промысла оставались сети и невод. Сети и фитили в Заболотье изготавливали из конопли – *«кинтер»*. Информаторы указывают, что за зиму женщины плели по 3–4 сети.

Основной формой хозяйственных объединений в конце XIX – начале XX вв. являлась семья. Хозяйственные объединения, занятые рыбной ловлей, были неустойчивы и варьировались в зависимости от сезона и способа промысла. Так, в весенне-летний период промысел осуществлялся семьей, выезжавшей на летние озерные поселения. «В деревне оставались лишь старые да малые» [ПМА].

Для следующего этапа – с конца августа по ноябрь, был характерен преимущественно индивидуальный промысел. Рыбачили в этот период сетями, фитилями, применялось запорное рыболовство. На озера выезжали одни мужчины.

Зимним подледным неводным ловом занималась артель, обычно состоящая из родственников, либо вновь на озерные поселения выезжала вся семья. Все основное трудоспособное население было занято в рыболовстве.

Таким образом, промысловые коллективы, будь то охотничья группа или рыболовецкая артель, состоящая из 2–3 человек, объединялись по родственному принципу. Но, хотя основной производственной единицей была семья, а иногда артель, распределение продукции хозяйственной деятельности выходило за рамки этих групп. Добытая рыба распределялась среди всех членов тугума, т.е. родственников.

Род – тугум, выступал и главным «собственником» рыболовных угодий: «Каждый тугум на озере имел свой участок» [ПМА].

Пищевой рацион населения Заболотья состоял из промысловых продуктов, и прежде всего, рыбы, с добавлением дичи и приобретенных в результате товарообмена муки и других продуктов. Рыбные продукты составляли основу пищевого рациона заболотных татар. В пищу употреблялась свежая, соленая и сушеная рыба.

Основными товарными продуктами заболотных татар были рыба (карась), а также пушнина и мясо. Товарно-обменные отношения в прошлом происходили на ярмарках, куда отвозили рыбу и другие продукты. Через территорию Заболотья проходила большая зимняя дорога из Кондинского района до Тюмени, которая была важнейшей транспортной артерией региона.

В весенне-летне-осенний период в Заболотье главным видом транспорта является лодка – кима. В прошлом известно о существовании

у заболотных татар берестяных лодок – тус кима. Но наиболее широко использовались лодки-долбленки.

Этнограф Р. Х. Рахимов сообщает о том, что для облегчения передвижения и увеличения возможности путешествовать на дальние расстояния между озерами, между озером и рекой, между реками и ручьями, вручную выкапывались узкие каналы, по которым могла пройти долбленка. При необходимости каналы расширяли до таких размеров, чтобы по ним могла пройти двухвесельная дощатая лодка грузоподъемностью до 3 тонн. В настоящее время по таким каналам передвигаются на современных моторных лодках.

Р. Х. Рахимов считает, что многие искусственные системы водоемов и транспортные артерии в Тобольском Заболотье были созданы очень давно, и уже воспринимаются как естественные. В исторической памяти заболотных татар сохранились воспоминания о сравнительно недавнем сооружение таких артерий. Так, в 1960-х годах озеро Томкуль, расположенное в 8 км к северу от дер. Ачиры, было соединено каналом с рекой Алымка. Длина канала более 5 км. А в 1990-х годах озера Саенкуль и Сабынкуль были соединены сразу с несколькими соседними озерами [ПМ Р. Х. Рахимов].

Искусственные водные системы создавались не только как транспортные артерии, но и как рыболовные угодья. Искусственные протоки между озерами становились путями миграции рыбы от озера к озеру или от реки к озеру. На этих протоках ловили рыбу традиционными способами и орудиями: устраивали запоры, ставили фитили и морды, устанавливали котцы [Рахимов: 2004].

Рыболовный промысел в Заболотье определялся следующими основными признаками:

1. Рыбный помысел занимает главенствующее положение в годовом хозяйственном цикле, характерна круглогодичность рыболовного цикла, наличие зимних и летних поселений на озерах, способы и средства лова значительно развиты, причем, преобладающее значение имеет сете-неводное рыболовство с широким использованием других средств – фитиля, запора.

2. Важное место занимает подледный зимний лов, в рыболовстве была занята большая часть населения, основной группой, осуществляющей промысел, являлась семья.

## Литература:

1. З. А. Гафурова. Типы хозяйств сибирских татар Нижнего Прииртышья//Экспериментальная археология. Вып. 1.Тобольск, 1991. С. 108-117].

2. Р. Х. Рахимов. Современное состояние охотничьего и рыболовного промысла Заболотных татар (по материалам экспедиции в Тобольский район в феврале 2003 г.).//Ежегодник Тюменского областного краеведческого музея «Земля Тюменская. Выпуск 17. Тюмень, 2004. – С.236-248

3. Н. А. Томилов. Тюркоязычное население Западно-Сибирской равнины в конце XVI – первой четверти XIX вв. Томск, 1981.

4. З. А. Тычинских. Легенды заболотных татар о первых нселениях края// Тобольск научный 2016. Тобольск. 2016. С.159 – 162.

5. З. А. Тычинских. Параллели в традиционной культуре заболотных и барабинских татар// Сулеймановские чтения Всероссийская научно-практическая конференция с международным участием. Тюмень, 2016. С.223-227.

6. ПМА – Полевые материалы автора.

**Фәнни популяр язмаларда төбәк тарихы/ Краеведение в научно-популярных публикациях.**

# ТАТАР КАТЛАМНАРЫ

***Д.И.Шәйхетдин***

***Аннотация:*** *Мәкаләдә төрки-татар җәмгыятенең катламнарга бүленеп яшәвенә анализ ясала. Мондый бүленешләрнең тарихның төрле чорларындагы үзенчәлекләре һәм принциплары күрсәтелә. Шулай ук, фәнни әйләнештә йөргән кайбер терминнарга карата автор үзенең аныклауларын бирә.*

***Төп сүзләр:*** *катлам; тайфә; ыру; кабилә; милләт; дәүләтчелек; ил һәм җир.*

Милләт булып өлгергәнче һәм үз мөстәкыйль дәүләтен төзегәнгә кадәр борынгы төрки-татар җәмгыяте дә, башка җәмгыятьләр кебек үк, катлаулы үсеш чоры узган. Ыру һәм кабилә булып яшәү барышында катламнар иерархиясе барлыкка килгән. Ыру дип, әйтик, шул заманда аерым бер торак урын (авыл) булып яшәгән, кан буенча бер-берсенә туганлыгы булган халыкны әйтәбез. Һәр ыруның башлыгы, гадәттә, өлкәнрәк яшьтәге, акылы, күңел сизгерлеге, рухи көче һәм башка югары сыйфатлары белән аерылып торучы хөрмәт казанган кеше булган.

Ыруның буыннан-буынга килә торган тамгасы, шулай ук үз җир биләмәсе, биләмә эчендә гыйбадәт кылу урыны да булган. Чишмәләр, ыру тавы, ак тирмә торган урын, кирәмәт һ.б. изгелек урыннар яшәгән. Гыйбадәт урыны башка ыру яки чит кабилә кешесе өчен дә изге һәм кагылгысыз булган, аңа зыян салу зур гөнаһ дип исәпләнгән. Борынгылар карашы буенча, андый урында рухлар «яшәгәнлектән», аны кузгату өстеңә зур бәла алуга тиңләшкән.

Кешеләр ыру эчендә үзләренең табигый сәләтләре буенча бүленгән. Берәүләр рухи тормышны алып барса, икенчеләр ыруның куркынычсызлыгын кайгырткан, калганнар – көнкүрешне тәэмин иткән.

Әлеге мәсьәләне өйрәнгән Зиннур Әһлиуллин борынгы төрки катламнарның дүрт төре булуын әйтә. Беренче, югары рухани катламны – камнар, икенчесен – тарханнар, ягъни гаскәриләр, өченчесен – кара будун (гади халык) тәшкил итә, ди. [Аглиуллин: 2007. Б. 3-4]. Дүртенче катламның төркичә аталышы ничек булганын ул әйтә алмый. Автор чагыштырып өйрәнгән традицион һинд җәмгыяте турындагы әдәбиятта язылганга

карасак, дүртенче катламны татарчалатып «адәм актыклары» яки «эшкә яраксызлар» дип әйтергә була торгандыр.

Үзенчәлек ягыннан катламнар бер-берсеннән иҗтимагый җаваплылык белән аерыла. Аларның аталышы халыкның мөстәкыйльлегенә һәм дини карашына да бәйләнгән.

Халык Тәңре аңында булганда, рухани катламны кам, багучылар һ.б., ә ислам дине кабул иткәч – шәех, ишан һ.б. титуллы затлар тәшкил иткән.

Борынгы татар ыруларының үзара элемтәсе аларны кабилә буларак берләшүгә китергән. Угылларны өйләндергәндә төрле ырулар арасында кыз алышу да моңа этәргеч ясагандыр. Инде ул вакытта ук үз ыруыңнан кыз алу йола белән катгый тыелган. Төрки-татар кабиләләре шактый күп булган: байлар, мең, бүләр, гәрәй, кыпчак, янәй, юрми һ.б.

Бер-берсенә якын туган булмаган, ягъни төрле тамгалы ыруларның башлыклары кабиләнең югары катламын, хәзергечә әйтсәк, элитасын тәшкил иткән. Төрле ыру кешеләреннән булган хәрби даирә үзе, кара (гади) халык үзе берләшә һәм җәмгыятьтә үз урын-дәрәҗәсен белеп, укмашып яши. Ырулар берләшү нәтиҗәсендә, аерымлыкны белдерә торган билгеләр: оран, тугра, агач, кош символлары һ.б. барлыкка килгән.

Соңыннан, ыру-кабилә җәмгыятеннән югарырак күтәрелгәч, дәүләт барлыкка килү өчен шартлар туа. Төрки каганлыгы дәверендә үк, көнбатыш төркиләрдә: хазар һәм болгарларда – ә аларның шактый өлеше хәзерге татарның бабалары – ыру-кабилә системасы үзгәреш кичереп, яңа төр – яшәү рәвеше барлыкка килә. Ягъни, каһаннар һәм халыкның югары катламы ныклап торып дәүләтчелек идеясен үстергән, дип әйтә алабыз.

Дәүләтле халык ыру-кабилә җәмгыятеннән түбәндәге билгеләр белән аерылып тора: дәүләт аппараты бар (гаскәр, хөкем институты, төрмә, дәүләт вазифасы башкаручы түрәләр); җәмгыятьтә кан-кардәшлек бәйләнешләренә нигезләнгән бүленешне территориаль принциптагы корылыш алыштыра; салым җыю системасы барлыкка килә.

Болгар чорында кешеләр, үтәгән бурычына карап, төрле социаль катламнарга бүленгән. Бөек Болгар дәүләтенә кергән болгар, ягъни төрки-мөселман булган халыкларның һәркайсы, бер генә социаль катламга керә. Борынгы Хәзәр чорыннан ук килгән закон буенча, бер катлам кешесе икенче катламга керә алмаган. Бу канун болгар чорында да, аннан соң да катгый үтәлгән.

Болгар дәүләтенең көч-куәтен, шәүкәтлелеген тәэмин итүче катлам казаклылар дип аталган. Боларның хөкүмәт алдындагы төп бурычы – ханга хезмәт итү була. Алар дәүләтнең төп терәге, мөстәкыйльлеген тәэмин итүче көче була. Казаклы сословиегә бары болгарлар гына кергән.

Бөек Болгар дәүләте халкының шактый зур өлешен ясаклылар тәшкил иткән. Дәүләт казнасын баетырга бурычлы бу катлам авыл җирләрендә – игенчеләр, ә шәһәр җирләрендә – һөнәрчеләр белән сәүдәгәрләр булган, дип хәзәрләр һәм болгарлар турында җентекле итеп яза Марат Ахунов. (Ахунов: 2005. Б. 110-119)

Кабилә булып берләшү җирләр берләшүгә китерсә, дәүләтчелек административ бүленешне барлыкка китерә. Әйтик, Хәзәр дәүләтендә һәр җир биләмәсе исәптә булып, үзара туганлык бәйләнешләре белән берләшкән җәмгыять ячейкаларына бүлеп бирелгән. Ил дип аталган бу җәмгыятьләр җир кулланган өчен каһанга ясак түли һәм ерак Хәзәрәнгә барып хәрби хезмәт тә үтәргә тиеш була. Җирләргә, илләргә һәм өлкәләргә административ бүленеш Болгар, Алтын Урда, Казан ханлыгы дәүләтләрендә дә урнаштырылган. Әйтик, Иске ил җире, Эчке ил җире, Барс ил җире, Челмат җире, Сабак ил җире һ.б. дип аталганнар.

Инде татар милләте булып оешып беткәч тә катламнарга бүленеш үз үзенчәлеген югалтмый. Дөрес, ул заманнар шаукымы астында бик нык үзгәреш кичерә. Әйтик, советлар идеологиясе тәэсирендә татарның югары катламнары эченә гади кешеләр үтеп керде. Мәнфәгатьчелек күренеше барлыкка килде, ягъни, тарих сәхнәсенә тар интереслар кайгыртучы кланнар килде. Борынгы җәмгыятьтә кешенең теге яки бу катламнан булу статусы - мал-мөлкәткә карата мөнәсәбәте белән билгеләнгән булса, хәзер кешенең җәмгыятьтә социаль статусын – аның мал-мөлкәте (байлыгы) билгели. Без моны бүгенге тормыштан да күрә алабыз. Хакимияттәге татар җитәкчеләре күбесе килеп чыгышы белән өченче, ягъни кара халык катламыннан. (Шәҗәрәләре үк әйтеп тора.) Аларның шәхси баю мәнфәгатен милләт мәнфәгатеннән өстен куюларына бер дә аптырарлык түгел.

Дәүләтләр оешкач, традицион катламнарның җәмгыять һәм бер-берсе алдында җаваплылыгы үзгәрә. Борынгы кеше өчен төп рухи этәргеч гореф-гадәт (йола) булса, үзәкләшкән дәүләт системасы оешкач, кеше каршына дәүләт кануннары мәҗбүрияте килеп баса.

Борынгыча катламнарга бүленешне хәзер юк дип исәпләсәк тә, аның фәлсәфи һәм гамәли асылы, ягъни культурасы бүгенге көндә дә милли яңарыш өчен әһәмиятле нигез булып тора ала. Катламнарга бүленеш традициясе нәрсә белән әһәмиятле соң? Ул барыннан да элек, буыннан-буынга килә торган теге яки бу өлкәгә караган тәҗрибә нечкәлекләрен һәм илаһи (сакраль) белемнәрне ыру-нәсел аша васыять итеп бару гадәтен саклый һәм сакларга өйрәтә.

Хәзерге заман татар кешесенең килеп чыгышы белән нинди катламнан булуын ачыклау гаять катлаулы мәсьәлә, әлбәттә. Бердән, борынгы катламнар бүленеше хәзерге мәдәният күзлегеннән искелек санала.

Икенчедән, моны тәгаен генә хәбәр итәрдәй тарихи чыганаклар да артык күп түгел.

Шулай да, мәсьләнең чишелешен эзләү җәһәтеннән татар нәсел тамгаларын системага салырга һәм, аннары аларны борынгы ыру һәм кабиләләр тамгалары белән чагыштырырга һәм тәңгәлләштерергә мөмкин. Бу уңайдан М. Әхмәтҗанов хезмәтләренең татар тамгаларына багышланган өлеше бигрәк тә игътибарга лаек.

* * *

Мәгълүм булганча, уналтынчы гасыр уртасында төрки-татарның Казан ханлыгы дәүләте белән бергә аның дәүләт корылышы да җимерелә. Шуның дәвамы булып, табигый рәвештә бер-берсенә буйсынып, ялганып килгән иҗтимагый баскычлар, катламнар юк ителә. Болардан чыгып, Мәскәү Казан ханлыгына яу башлаганда, татардан ясак салымы түләтү генә түгел, ә зуррак максат һәм бурычлар куйган булган, дип әйтә алабыз. Ягъни, татарның җәмгыяви катламнарын җимерү һәм татарларны бер-берсенә буйсындыртмау – аның стратегиясе булган. Моңа ирешү өчен озак еллар, дәвер-дәвер чукындыру сәясәте алып барылган. Барлык катламнарда да чукынган белән чукынмаган татар, социаль, рухи һәм сәяси яктан да төрле хәлгә һәм төрле дәрәҗәгә куелган: салым түләүдә, хәрби хезмәт үтәүдә, җиргә хуҗа булу хокукында кешеләрне төрлечә бүлгәлиләр. Моның белән халык эчендә эчке ясалма каршылык тудырыла. Нәсел шәҗәрәсе нигезендә өстенлекле катлам булырга теләгән татар кешесенә чукыну һәм православ исем алу «тәкъдим ителгән». Шулай итеп чукынган морзалар «катламы» барлыкка килгән. Хәрби хезмәткә ялланган татарлар служилый казак «катламына» кертелгән. Аларның да шактые чукынган. Кара халыкка да социаль өстенлекләр, кайбер ташламалар чукыну бәрабәренә генә бирелгән. Ә чукынырга теләмәгән татар аксөякләре гади (кара) халык составына кертелгән. Нәтиҗә булып, Россия империясе заманында татар халкының күпчелеге ясалма бүлгәләнеп, «башкорт», «типтәр», «ясаклы», «казан кешесе», «сәүдәгәр», «чемоданлы», «лашманлы», «иске һәм яңа керәшен», «бөлгән» (бобыль) һ.б. булып исәпкә алынган. Татар халкын исәпкә алган мулла дәфтәрләрендә әлеге атамалар тайфә итеп күрсәтелсә дә, бу дөреслеккә туры килми. «Тайфә» сүзе гарәп теленнән ыру дигәнне аңлата. Ул вакытта татар хәятендә тайфә кешенең катлам-сословиесен түгел, ә социаль статусын гына белдергән. Һәм хәтта әлеге социаль төркемнәр дә империя тарафыннан төрле шартларга куелган. Әйтик, «социаль башкорт»ка имана җиренә ия булу хокукы бирелсә, «типтәр» һәм «ясаклы» аның җирендә ялланып кына эшли алган. Әлеге хәл 1917 елгы Октябрь инкыйлабына кадәр дәвам иткән.

Димәк, татар җәмгыятенең элек-электән килгән катламнар булып яшәү культурасы Казан ханлыны дәүләте җимерелгән вакыттан башлап бетерелә, дип нәтиҗә ясарга була.

**Әдәбият:**

1. З. Аглиуллин. Обобщенные знания о сословиях и классах в обществе / «Безнең юл» гәҗите. - №5. – 2007.
2. М. Г. Ахунов. Татар тарихыннан. Казан: Ш. Мәрҗәни ис. Тарих инст-ты басм. 2005. – 444 б.

## АВЫЛЫМНЫҢ КҮРЕНЕКЛЕ КЕШЕЛӘРЕ

***Ф.Х. Әскарова***

***Аннотация:*** *Чыгышта Сарабикол авылында туып, шунда яшәгән һәм тырыш хезмәт куйган кешеләр турында сөйләнә. «Урал» колхозында эшләгән, зур дәрәҗәләргә ирешкән авылдашларга багышлана. Алар колхозны күтәрүгә үзләренең көчләрен куеп, көнне төнгә ялгап эшләгәннәр. Шуларның нәтиҗәсе булып, авылдашларым төрле бүләкләр, медальләр, орденнар белән бүләкләнгәннәр.*

«Гүзәл Сара, батыр Биккол.

Исемен йөртә авылым...» – дип җырлана Сарабикол авылы турында.

Авылыбыз бик матур җиргә урнашкан. Безнең авылның табигате дә матур. Ул Шушма елгасы буенда, таулар арасында урнашкан. Бер яктан калын урманнар каплап торса, икенче яктан шомыртлы тугайлыклар җәелгән. Авыл уртасыннан Шушма елгасы ага. Ул – авылның хозурлыгы. Миңа үзем яшәгән Сарабиккол авылы якын. Аның табигате, чишмә-елгалары, таулары, урманнары кадерле.

Чишмәләргә бай булган кебек, хезмәт сөючән, батыр, эшкә уңган кешеләре белән данлыклы минем авылым: Советлар Союзы Герое, Социалистик Хезмәт Герое биргән авыл буларак танылган ул. Шулай ук данлыклы язучылар, академиклар, табиблар, судьялар, укытучылар һәм башка һөнәр ияләре чыккан авылымнан.

Ләкин минем сүзем бүген алар турында тугел, ә гади хезмәт ияләре: илгә икмәк, сөт, ит җитештерүчеләр турында. Элек колхозда хезмәт куйган тракторчылар, мал караучылар, тимерчеләр, сыер савучылар...

**Фәрит Фатих улы Ялаков**, Бөгелмә механизация техникумын тәмамлап кайтканнан соң, армиягә киткәнче өч ел тракторда эшли. Ә солдат хезмәтеннән кайткач, колхоздан китү ягын карамый. Чөнки анда эш җитәрлек. Фәрит абыйга җаваплы эш тапшыралар: кырчылык бригадасы бригадиры. Бераз вакыттан соң ул авыл хуҗалыгы техникасы бүлеген җитәкләргә алына. Эше белән бергә Минзәлә совхоз-техникумында да укый. Техникумның агрономия бүлеген тәмамлый. Тормышны, кешеләрне белми торып, үзең башкаларны өйрәтә, аларга күрсәтмәләр бирә алмыйсың. Моны Фәрит абый «Урал» колхозының партия оешмасы секретаре итеп сайлангач аеруча аңлый. 13 ел буена шушы «йөкне» тарта. Фәрит абый 1974 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнә. Аның башка бик күп хөкүмәт бүләкләре дә бар. Болар үзе генә дә Фәрит

абыйның тырыш хезмәте, тынгысыз җан булуы, эшне оештыра белүе турында сөйли.

**Мостафин Зәкиҗан абый** туган колхозы кырларын иңләп, җир сөрә, чәчә, эшкәртә, киләчәк уңышка нигез сала. Күпме буразна сызгандыр, күпме җир эшкәрткәндер үз гомерендә Зәкиҗан абый. Бик күп мактау грамоталары, социалистик ярышларда җиңүче билгеләре һәм, ниһаять, Почет билгесе ордены, В.И.Ленинның тууына 100 ел тулу уңае белән тапшырылган медаль бизәде аның хезмәт юлын. 1984 елда аңа «Татарстанның атказанган механизаторы» исеме бирелгән.

**Төхфатуллин Әнәс абый** кечкенәдән әтисе янында алачыкта була. Үсә төшкәч, бу йөрүе аңа ярап куя. Шофер таныклыгы да ала, ләкин тимерче һөнәренә тугры кала. Техниканы язгы чәчүгә, уракка әзерләү, машиналарны төзек хәлдә тоту һәм башка эшләр – тимерче Әнәс абый вазыйфалары. Авылда аны «Алтын Әнәс» дип йөртәләр. Алтын куллы булгангадыр инде. Авыл хуҗалыгы өлкәсендә зур хезмәтләре өчен Әнәс абый «Татарстанның атказанган механизаторы» исеменә лаек булды.

**Хәнифә Хәмәт кызы Садыйкова** 1952 елда ишле гаиләдә туган. 1968 елдан башлап, лаеклы ялга киткәнче, сыер савучы булып эшли.

16 яшьлек Хәнифә апага кул белән көнгә 25әр сыер саварга туры килгән.

Аның тырышлыгы, эшендә зур уңышларга ирешүе авылда аңа ихтирам һәм хөрмәт китергән. 1978 елда Хәнифә апа III дәрәҗә «Хезмәт Даны» ордены белән бүләкләнгән.

Ирек абый белән өч улларын олы тормыш юлына чыгардылар. Уллары да әти-әниләре кебек тырышлар, уңганнар.

**Вәсилә апа Габбасова** – «Урал» кохозының алдынгы терлекчесе – бозау караучысы. Аның тырышлыгы белән бозаулар һәрвакыт чиста, ашатылган була. Аларның үлеменә юл куймый туры сүзле Вәсилә апа. Аны район, авыл советы депутаты итеп тә сайлыйлар. Ул тугызынчы һәм унынчы бишьеллыклар коммунистик хезмәт ударнигы, «Социалистик ярыш алдынгысы» билгесе иясе. Вәсилә апа тырыш хезмәтләре өчен «Хезмәт Кызыл Байрагы» ордены белән бүләкләнгән.

**Насриев Әнвәр Гариф улы** Сарабикол авылында 1940 нчы елда дөньяга килгән. Әнисе Миннури апа гомере буе колхозда эшләгән, әтисе Гариф абый аңа яшь ярым булганда Бөек Ватан сугышына китә һәм шул китүдән әйләнеп кайтмый. Ятимлектә үсүенә карамастан, Әнвәр абый тормыш авырлыкларына бирешми. Сарабикол мәктәбендә сигез класс тәмамлап, механизатор ярдәмчесе булып эшли. Ә 1959–1962 нче елларда Ерак Көнчыгышта Тын океан флотында хезмәт итә. Армиядә хезмәт иткәндә, шофёрлыкка укып, машина йөртү таныклыгы ала. Хезмәтен тә-

мамлагач, туган авылына кайтып «Урал» колхозына шофер булып эшкә керә. 1970–1973 нче елларда Минзәлә совхоз техникумында укый. Диплом алгач, янә туган колхозына ферма мөдире булып эшкә кайта. Шулай итеп, 1974–1994 елларда «Урал» колхозында баш зоотехник булып эшли. 1995–1997 елларда мелиоратор була. 1998-2000 елларда хуҗалыктан сөт җыя. Олы хезмәтләре өчен төрле медальләр белән бүләкләнә:

– 1970 елда «За доблестный труд в ознаменование 100-летия со дня рождения Владимира Ильича Ленина» медале;

– 1975 елда «Победитель социалистического соревнования» билгесе;

– 1985 елда «Ударник одиннадцатой пятилетки» билгесе.

Ә 2000 елдан бирле Хезмәт ветераны исеменә лаек.

Бүгенге көндә Әнвәр абый лаеклы ялда. Тормыш иптәше Сәмия апа белән 53 ел гомер итәләр. 4 бала тәрбияләп үстерделәр. Бер кызлары, мәктәбебез директоры – Сәлимә. Менә 7 ел инде шушы зур йөкне тарта. Ләкин Сәлимә Әнвәр кызы дан өчен эшләми, ә мәктәптә укытучыларга, укучыларга эшләргә, укырга уңайлы булсын дип тырыша. Коллектив аны хөрмәт итә. Сәлимәнең тормыш иптәше Марсель дә көчен кызганмый. Ул «Үз мәктәбеңә ярдәм ит» акциясенә кушылып, керү капкасын ясады. Аңа зур рәхмәт әйтәбез һәм Сәлимә белән исән-сау, тигезлектә яшәүләрен телибез.

...Басуларда заманча техникалар эшли. Элеккеге кечкенә фермалар урынына тулысынча механикалаштырылган биналар сафка баса. Авылымның терлекчеләре, механизаторларының һәммәсе турында тагын да күбрәк итеп язмалар язарлык. Аларның хезмәте һәм томыш тарихы гаҗәеп бай, эчтәлекле.

Тарихны кешеләр язмышы тудыра. Кешеләр үзләре тарих белән, авылларның үткәне белән кызыксынырга тиеш. Мин авылдашларымның берничәсе турында гына сөйләдем. Ләкин бу соңгысы булмас. Киләчәктә башка авылдашларым турында да чыгыш ясармын дип ышандырасым килә.

**Әдәбият:**

1. Рәшит Якупов. «Сарабиккол (Әби авылы)». Татарстан Республикасы, Лениногорск – 2007ел. – 237 бит.

2. Рәшит Якупов. «Сарабиккол (Әби авылы)». Чаллы «Диамант» нәшрияты – 2011ел.

3. Харис Гомәров. «Авылым, авылдашларым». Очерклар, зарисовкалар. Чаллы, 2009 ел. – 304 бит.

# ЯҢА БИСТӘ ТЕЛЕ ҺӘМ КАЙБЕР ГАДӘТЛӘР

***М. Р. Батулла***

*Сүз башы*

Ана телебезнең үзгә шивәләре (җирле сөйләмнәре) күп: Казан Арты, Керәшен, Мишәр, Кырым, Себер, Типтәр, Нугай... Казан Арты сөйләмен «Татар халкының әдәби теле» дип йөртәләр. Менә шушы тел эчендә тагын бер мөстәкыйль тел яшәгән. Ул Казанда – Яңа Бистәдә, Бишбалтада кайчандыр гамәлдә булган. Һәм әле дә бу телне белүчеләр бар. Тел эчендәге бу телне «жаргон», «арго», «сләң» дип тә атыйлар. Ихтимал, бу күренеш инглиз, урыс һәм татар теле кебек бай телләргә генә хастыр. Үсеп килә торган яшь телдә икенче тел була алмый. Диңгезчеләр сөйләме, караклар сөйләме, хәтта аерым һөнәр ияләренең дә үзара гына аңлаша торган аерым сүзләре, гыйбарәләре була.

Татар теле эчендәге икенче тел (Яңа Бистә сөйләменең) тарихы ерактан ук башлана. Казан ханлыгы җимерелгәч, татар халкының буе сындырылгач (буйсындырылгач) та азатлык өчен көрәш туктамый. Баш күтәрүләр, гыйсъяннар дәвам итә. Татар халкының «настроениесен» алдан белеп тору өчен, патша Русиясе яшерен агентлар әзерли, бу агентлар татарча яхшы белүче урыслар арасыннан да, йомышлы татарларның үз араларыннан да сайлана торган була. Шулай итеп, татарлар арасында җасуслык, шымчылык, әләкчелек тамыр җәя башлый. Әнә шушы шымчыларны ялгыш юлдан җибәрер өчен, саклану өчен, ватансөярләр үзләре генә аңлый торган аерым сүзләр, гыйбарәләр уйлап табарга мәҗбүр булганнардыр. Шулай, әкрен-әкрен тел эчендә тел барлыкка килгән, дип фаразларга була. Ана телебезнең кануннары урынында кала, тик яңа сүзләр, иске сүзләрне күчермә мәгънәсендә куллану, аерым даирә генә аңлый торган тулы тәгъбирләр, гыйбарәләр гамәлгә керә. Яңгырашы саф татарча булса да, сүзнең эченә салынган мәгънәне бары тик бу эшкә багышланганнар гына аңлый алган. Әйтик, «сак булыгыз, жандарм, полицейский, милиционер килә» дип кычкырсалар, бу бөтен кешегә дә аңлашылган булыр иде. «һүррә, җантимер, тимерҗан килә» диелсә, моны бары тик кирәкле кешеләр генә аңлаган һәм саклану чаралары кулланырга өлгергән.

Яңа Бистә сөйләмендәге ясалма сүзләр үзләренең образлылыгы белән таң калдыра. Менә бер сөйләм үрнәге:

– Мач килдеме?

– Ма-ач!

– Күпме булды?

– Ике куян!

Бусы базар тирәсендәге рәтчеләрнең сөйләшүе. Рәтче – карак, бур, бандит дигән сүз. Тәрҗемәсе болай:

– Юлың уңдымы?

– Уңды.

– Күпме, ни урладың?

– Ике капчык ак он.

Яңа Бистәдә 1940 елда туып үскән Сибай атлы бер җегет сөйли:

– Төнә кайтып киләм. Безнең анда караңгы... Каршыга бер рәтче очрады. Чаппах теңәр кыптымән. Пәнҗөкие дә юк, малай. Текесен ал да тай! Икенче көнне: чуен янында берәүне кыптылаганнар, дип сөйләделәр.

Тәрҗемәсе:

– Кичә кичтән кайтып киләм. Безнең анда караңгы... Каршыга бер бандит, кеше талучы очрады. Пычак белән эченә кададым. Акчасы юк иде. Сәгатен алып йөгердем. Икенче көнне тимер юл буенда берәүне пычак белән чәнчегәннәр, дип сөйләделәр.

– Төнә Капчык Сабир койма санады.

Ягъни, кичә Капчык Сабир исерек иде, егылмас өчен коймага таяна—таяна кайтты, дигән сүз.

– Кайда булдың?

– Савытларда керпе сугыштырып кайтам.

Ягъни, фахешханәгә барып, мәткәләр янында кунып кайта икән.

Бу тел гаять бай булган, диләр. Анда гарәп-фарсы, онытылган борынгы төрк сүзләре дә, уйдырма-ясалма кәлимәләр дә байтак. Гамәлдә булган сүзләргә бөтенләй башка мәгънә салып кулланылганнары да тулып ята. Бу тел хәтта гомүм Ана телебезгә дә тәэсир иткән. Шушы сөйләмнән сәмән (акча), әхтәри (уен картасы) кебек сүзләр телебезгә кереп калган.

Яңа Бистәдә яшәүче татарларны төрле якларга таратталар. Алар төрле милләт вәкилләре арасында яшәргә мәҗбүр булалар, шуңа күрә, бу оешканлык таркалганга, Яңа Бистә теле дә гамәлдән чыга бара, тел әкренләп онытыла һәм ул үләргә мәхкүмдыр.

Озын сүзнең кыскасы, телчеләр, диалектологлар, галимнәр, журналистлар, шәкертләр бу телне өйрәнсеннәр иде, дим. Ни генә булмасын, бу тел халкыбызның, тарихыбызның бер өлеше. Менә шушы эшнең башы итеп, мин үзем ишеткәннәр-белгәннерне язып узам.

**Сүзлекчә**

| *Бүгенге тел* | *Яңа Бистәчә* |
|---|---|
| Акча | таш, корт, сәмән |
| Бер сум | ияк |
| Ике сум | дүкәш |
| Өч сум | сикәш |
| Дүрт сум | чарки |
| Биш сум | пәнжөки |
| Алты сум | чаштыкый |
| Унбиш сум | берунпәнҗ |
| Егерме биш сум | почмак |
| Йөз сум | капчык |
| Мең сум | багана |
| Урыс | сәкмалай |
| Аракы | ут, ябалак шулпасы |
| Сыра | пирәш |
| Тәмәке | дохон |
| Икмәк | мандыра |
| Авыз | мандыра савыты |
| Бөртекле чәй | җим |
| Такта чәй | ләүех |
| Шикәр | кәнт |
| Вак шикәр | ком |
| Ит | таҗи |
| Казылык | таяк |
| Он | кершән |
| Бер капчык ак он | куян |
| Костюм | калып |
| Кәлүш | бака кашыгы |
| Эшләпә | камфуркы |
| Сидек кудыру | сәнҗетү |
| Пычак | кыпты |
| Наган | дөмперт |
| Кесә карагы | рәтче |
| Милиционер | шухыр, җантимер, тимерҗан, җантый |

**Кушаматлар**

Ислам диненең мулла кушкан исемнәрне бозмаска боеруы да татарларны куркытмаган, борын-борыннан кешеләр бер-берсен аерыр өчен, үзенә күрә «фамилияләр» уйлап чыгарган. Бу кушаматлар (кушым атлар), өстәмә исемнәр бер исемдәге кешеләрне бер-берсеннән аерыр өчен уңай булса, икенче яктан кеше үзенең холкы, килеш-килбәте, кылган гамәлләре белән үзенә үзе исем «сайлаган». Шуңа күрә, кешенең балачактан картайганчыга кадәрле гомере арасында берничә исеме булган. Төз атучы булса, Мәргән Йосыф, тәртипсез кеше булса, Чорсыз Гафур кебек төгәлләү кушаматлары барлыкка килә торган. Бу гадәт керәшеннәрдә дә, себер татарларында да, Американың җирле халыклары арасында да нык сакланган. Яңа Бистә халкында кушаматлар тагу аеруча киң таралган була.

Иске Исмәгыйль, Яңа Бистәнең егерменче гасыр башындагы иң атаклы карагы, рәтчесе. Госрорчк, Чыптыбый, Кожан, Кәҗә Нурый, Абытым Шәүкәт, Ыштык Мәхмүт, Ибраһим Хәзрәт, артист Фоат Халитнең атасы. Зәңгәр Мәчет Мулласы, Җиңги Садыйк, Галиасгәр Камалның кайнатасы; бик вакчыл булганы өчен аңа шушы кушаматны такканнар. Кәләвәче Вәли, Күтлин Вәли, Абла Фәйзерахман, Мәмәдәл Сабир, Пандырашка Зиннәт, Мәбтәли Сөләйман, Кылтыравык Мөхәммәди, Чатбашы Мәзин, Мыек Шакир, Къарта Габделхак, Чөгендер Һади (борыны кызыл), Җантый Габдулла (милиционер), Аккомасты Шәфи, Аткүз Галим, Песи Исхак, Әчтүч Нәфисә, гомере буе ирләр киеме киенеп йөргән, тәмәке тарткан, аракы эчкән; Алтыбиш Сапый, саный белмәгәне өчен.

Икенче Сугышка кадәр Яңа Бистәдә яшәгән диваналарның кушаматлары. Самавыр (үз исеме Кадыйр), бу бичара якты чырай күрсәткән һәр кешенең өендә берәр чиләк сыешлык самавырны бер үзе эчеп бетергәненә күрә шундый кушамат алган.

Катык Галләм-элек Яңа Бистә базарларында йомыш үтәргә әзер торучы ярымдивана, ярымэшсезләр буталып йөргән. Бер кеше берәр сатучыдан акча түләп әйбер алса: минем өйгә илттереп куй, дип китә торган булган. Сатучы әлеге диванасының берәрсен чакыра да: әйберне сатып алучының өенә илтеп куярга куша. Әлеге Галләм, хәреф—сан танымый торган бер бичара була. Ул бары тик кайсы байның кайда торганын, исемен, кушаматларын яхшы белә. Кибетче әйтә моңар: бар, Галләм, менә бу бер тәпән катыкны Кәләпүшче Гыймайларга илтеп куй, ди. Галләм тәпәнне баш очына куеп, катык илтә китә. Элек әйберләрне кул очыннан ташымаганнар, төенчекне, чиләк-тасны баш очына куеп йөрткәннәр. Бу эшне алар шундый оста башкара торган булганнар, хәтта урыс кунаклары, читтән килгәннәр, Европа кешеләре татарларның товарларны баш

очына куеп, матур-оста йөреткәннәрен карарга махсус рәвештә базарга төшә торган булганнар. Галләм шулай итеп рәхәтләнеп, сызгыра-сызгыра бара икән башына тәпән куеп. Бервакыт ул абынып китә дә, бер тәпән катык Галләм өстенә ага. Шуннан бирле аны «Катык Галләм» дип йөртә башлыйлар.

Берин Зиннәт тә дивана, ләкин дивана булса да, эш йөртә белә. Ул каекчы булып, көймәсенә кешеләр утыртып, ишкәк ишеп көн күрә. Шулай бервакыт ул бер кешене аргы якка чыгарырга тиеш була. Бәһасе бер сум көмеш тора икән. Пассажирның акчасы туксантугыз тиен генә булып чыга:

– Китер бер тиенне!— дип кычкыра Зиннәт.

Бичара пассажир акчасы булмагач, нишләсен, качып китмәкче була. Зиннәт моның якасына ябыша. Көймә чайкалып, болар икесе дә суга барып төшә. Туксан тугыз тиен дә су төбенә китә. Шуннан соң Каекчы Зиннәт «Бертин Зиннәт» булып китә.

## Яңа Бистәдәге кайбер гадәтләр

Элек арбаны дегет белән түгел, атлан май белән майлап йөртә торган булганнар. Чөнки дегет кыйбатка төшә. Бик байлар гына арбаларын дегет? белән майлый торган булганнар.

Яңа Бистә урамнарында, ишегалларында йөрүче һөнәрчеләр, сатучыларның өндәү, чакыру сүзләре.

Җимеш сатучы:

– Кара җиләк, җир җиләк – бер чиләк! Ал тизрәк! Карлыган да бөрлегән – бер дигән!

Самавыр төзәтүче:

– Са-ама-авы-ыр, самавыр! Эш авыр, эш авыр, сәмән бар, сәмән бирр!

Күмер сатучы:

– Шау күме-ерр! Мичегезгә яксагыз, самавырга салсагыз, бәхеткә күмә-әрр!

Пыялачы:

– Пыяла куям! Пыяла куям! Бәһасе бер куян!

Шырданнан килүче катыкчылар:

– Әче катык, төче катык! Салкын катык, җылы катык, чыгыгыз! Утырмагыз катып!

Элегрәк «Пәрәү хәерчеләре» гыйбарәсе булган. Имеш, пәрәүләр бик хәйләкәр булганнар, тәртә башларын яндырып, хәер соранып йөргәннәр икән:

– Менә яндык, ярдәм итегез! – дип халыкны ышандырыр өчен көйгән тәртә башын күрсәтә торган булганнар.

Ишегалларыннан самавырчылар, пәрәүләр узгач, хәерчеләр йөри башлый. Эскрипкәче Дәүли сукыр була. Бичара эскрипкә уйнап тамак туйдыра икән. Бу хәерче бик нык уңыш казана торган була. Ул үзе уйный, үзе җырлый икән. Эскрипкәсен ул тез башына куеп уйный торган була. Эскрипкәче Дәүлинең репетруарында бихисап була.

Хәерчеләрдән соң чегәннәр йөри башлый. Чегәннәр кичкә таба йөрергә чыгалар. Кешеләр эштән кайткач, кер юып , ишегалдына чыгарып элгәч, алар өчәүләп керә дә, берсе хуҗабикәгә күрәзә карыйм дип, фәлән-төгән, дип алдап, тоткарлап тора, ул арада башка чегән хатыннары җәймәләр, күлмәк, сөлгеләрне салдырып чыгып китә торган булалар.

Чегәннәрдән соң көнлекчеләр кузгала. Утын кисү, утын яру эшләре эзләүчеләр. Балта-пычкы үзләренеке, чүпрәк-тирегә пөхтәләп терелгән эш кораллары яннарында.

Яңа Бистәдә атаклы гармунчылар бик күп иде. Аларның кушаматлары да уйнауларына карата бирелгән. Әргәнче Фатих, Саратский Гомәр, Тальян Гайнан...

Бу мәгълүматның барысын да мин Әхмәт ага Гыйззәтулла – Бутафур Әхмәт авызыннан язып алдым. Әхмәт ага Яңа Бистәдә туып –үскән. Театр техникумын тәмамлаган, актерлыкка укыган, соңыннан ул гомер буе, әҗәленә кадәр Камал театрында бутафор – рәссам булып эшләде. Ул гаҗәп җор телле, шаян, көр күңелле, бик күп борынгы җырлар белүче кеше иде. Бу сүзләр 1986 елның егерме дүртенче февралендә театр эчендә язылды. Бу вакытта Әхмәт абыйга җитмеш яшь чамасы булгандыр. Ул инде күптән вафат. Авыр туфрагы җиңел булсын! Урынын Җәннәттән әйләсен! Амин!

Тиллим-тиллим эскрипкә,<br>
Тиллим булса да ярый:<br>
Безгә хатын кирәк түгел,<br>
Кызы булса да ярый, – кебек шаян такмакларда белә иде ул

## ИЗ ОПЫТА РАБОТЫ В МУЗЕЯХ

***Р. С. Кутумова***

*Я, Кутумова Равиля Сибгатулловна, родилась в г. Тобольске Тюменской области 6 декабря 1949 г. в рабочей семье. Девичья фамилия Тушакова. Тушаковы – бухарцы, выходцы из Средней Азии. Предки мои прибыли в Сибирь очень давно, в XVI–XVII вв., с целью развития торговли и просвещения. Фамилия Тушаков произошла от имени Душхан. Тушаковы обосновались в бухарской юрте Миримовские Тобольского уезда, держали свое кустарное предприятие по изготовлению меховых рукавиц из козлиных и оленьих шкур. Мой дед, Сафар Мухминович Тушаков (1882–1937 гг.), родом из этих юрт, он был купцом. В Тобольске имел свою усадьбу и частную лавку. Он был специалистом по пушнине, торговал разными товарами. В 1937 году репрессирован и расстрелян в тобольской тюрьме и реабилитирован в 1959 году. Отец, Сибгатулла Сафарович 1924 г.р., уроженец г.Тобольска, был мастером по шитью сапог и работал кочегаром в мебельной фабрике. Мать, Нуртита Вагаповна, 1928 г.р., уроженка дер. Иштаманы Тобольского района, работала станочницей и была передовицей в мебельной фабрике и депутатом Тобольского городского совета нескольких созывов. Они воспитали шестерых детей, всем дали достойное образование. Я – старшая из всех детей. Отец умер рано, в 1977 году. Мать находится на заслуженном отдыхе.*

*Я выпускница средней татарской школы № 15 г.Тобольска, закончила физико-математический факультет Тобольского государственного педагогического института им. Д. И. Менделеева. В 1972–1974 годах по распределению работала учителем математики в Алтайском крае, в 1974–1977 годах – учителем математики с средней школе № 15 г. Тобольска, в 1978–1995 годах – инженером по претензионной работе воздушных судов Тобольского авиационного отряда. В 1995–2008 годах являлась в муниципальном учреждении «Центр сибирско-татарской культуры» (ЦСТК) заведующей историко-этнографическим музеем сибирских татар. Приложила много усилий по созданию этого музея при центре. Являюсь участницей научно-практических конференций разных уровней, симпозиумов, делегат третьего съезда Всемирного конгресса татар от Тюменской области в г. Казани в 2002 году. Имею Почетные грамоты и благодарности от Центра татарской культуры и Комитета по культуре администрации г. Тобольска, правительства Тюменской*

*области, награждена Почетной грамотой Министерства культуры и профсоюза работников культуры РФ. Являюсь членом Союза журналистов Республики Татарстан.*

*С мужем Габилем Хамитовичем Кутумовым воспитали дочь Юлию 1974 г.р. и сына Марата 1981 г.р. Оба имеют высшее образование. Дочь– высшее педагогическое и юридическое; сын закончил Тюменскую строительную академию, инженер-строитель. Оба имеют свои семьи. Растут две внучки и два внука. Муж умер рано, в 55 лет. Работал бортинженером 1-го класса на вертолётах Ми-8 в Тобольском авиаотряде, был удостоен знаком «За безаварийный налёт 11 тысяч часов».*

*С февраля 2008 года по приглашению работаю заведующей музеем национальной школы при СОШ № 15 г. Тобольска.*

## Из опыта работы в музеях

Школьный музей – это особое место, он хранит фотоснимки, предметы старины, личные вещи. Здесь витает дух истории и живет само Время. Чтобы он не был просто архивом устаревших предметов, даже редких и интересных, в него следует вкладывать душу и силы. В детстве я мечтала стать учителем, затем – врачом. Но вышло так, как вышло. После окончания Тобольского litпединститута я получила специальность учителя математики средней школы. Сначала работала учителем по специальности, затем, как отметила инженером по претензионной работе в авиации (17 лет), научным сотрудником и заведующей историко-этнографического музея с момента основания в Центре сибирско-татарской культуры города Тобольска (14 лет). Здесь находится богатый музей, фонды и экспозиции которого включают около 1500 оригинальных предметов, документов и фотографий, характеризующих экономику, быт и культуру сибирских татар. Тут также расположен музей Якуба Занкиева, в создании которого немало усилий было приложено мною и с 2008 года работаю руководителем Музея национальной школы Тюменской области. «Комната боевой славы», музей «История средней школы № 15» явились прообразом будущего большого «Музея национальной школы Тюменской области», торжественное открытие которого 20 февраля 2009 года было посвящено 90-летнему юбилею средней школы № 15. В дальнейшем музейный комплекс школы расширился, появились кабинеты исторического краеведения, «Тобольск-жемчужина Сибири», музей реки Иртыш.

Концепция Музея национальной школы разработана автором данной статьи, в содержании работы применены её личные архивные материалы, накопленные за многие годы работы в музейной деятельности и архив 15-й школы.

События истории последних лет показали, что в сознании молодежи широкое распространение получает равнодушие, эгоизм, агрессивность, неуважительное отношение к старшим, истории своего народа, ценностям российской культуры.

Школьный музей призван быть центром патриотического воспитания школьников; он осуществляет связь подрастающего поколения с ветеранами войны и труда; является местом знакомства учащихся с историей края, города, района, школы; закрепляет духовно-нравственные основы семьи. Работа, организованная музеем, помогает учащимся лучше понять и освоить предмет «История». Изучение истории своей малой родины – составной части нашей страны – дело, значение которого нельзя недооценить. При этом знакомство с музейными коллекциями стимулирует сопереживание, эмоционально обогащает духовный мир детей и подростков, учит пониманию прекрасного, толерантного отношения к культуре других наций, способствует гуманизации образования.

Поэтому целью работы музея школы является повышение интереса учащихся к изучению своей истории и при этом решаются следующие задачи: активизация самостоятельной творческой, собирательной, поисковой и исследовательской деятельности школьников; расширение знаний по истории родного края, города, района и семьи; укрепление семейных традиций, обычаев, духовно-нравственных основ семьи; ориентирование детей на общие гуманистические ценности.

Основными формами работы в нашем музее являются экскурсии, встречи, конкурсы, викторины, беседы, музейные уроки, участие в конкурсах различного уровня и другие мероприятия.

Р. Хамитов быстро подкупил часть татарских деятелей за счет мандатов депутатов Госсобрания: Загира Хакимова (РКНТ), миллиардера Рамиля Бигнова, Римму Утяшеву (Национально-культурная автономия). Названные деятели бегом пошли трудиться против собственного народа. Именно в эти годы был уволен с поста директора единственной татарской гимназии, интеллигент и ученый Нурмухаммет Хусаинов. Прекратил свою работу единственный татарский национально-культурный центр в дер. Килимово Буздякского района (когда таких центров у русских и башкир по пять). И прекратила свою деятельность единственная 25 минутная телевизионная республиканская передача в месяц для татар, так как для башкир и русских идут круглые сутки, и по нескольким каналам... И всё это частично и за счет налога с татар, что не согласуется с принципом справедливости.

Но татары всегда выступали и выступаем за справедливость, равенство прав всех народов и дружбу между ними. Поэтому надеемся, что рано или поздно татарские проблемы в Башкортстане начнут решаться. А то получается что татары и татароязычные башкиры, составляющие 1/3 населения республики, все еще остаются в республике людьми второго сорта.

# ЮГАРЫ ЧЫРШЫЛЫ АВЫЛЫНЫҢ ӨЧ ГАСЫРЛЫК ТАРИХЫ

***Ә. Ф. Ямаева***

***Аннотация:*** *В публикации рассказывается о трехвековой истории деревни Верхние Чершилы Лениногорского района. В ней даны краткие сведения о возникновении села, жителях деревни, их жизнеописание, о родословных корнях всех жителей деревни. Подводятся некоторые итоги изучения истории деревни. Со всем этим можете ознакомиться в новой книге А.Ямаевой «Ай нурында нәсел сукмагы», которая выпущена в Казани в 2018 году в издательстве «Яз».*

***Ключевые слова:*** *деревня, ревизия, метрика, родословное дерево, захоронения, память.*

Ак сакаллы ил агасы әйтер:
– Тарих юлларында абынгач,
Үткән гомер белән калган хәтер,
Сатып алыйм дисәң, табылмас...

Гамил Афзалның бу юллары безгә кагыла инде. Моңарчы авыл тарихын без күбрәк картлардан гына ишетеп белгән булсак, соңгы унбиш ел эчендә мин күп документлар: белешмә, ревизия, метрика, Диния Нәзарәте документлары, 1900 елгы санисәп материаллары, хуҗалык кенәгәләре белән эшләдем. Аларда чынбарлык язылган, уйдырма түгел. Элек яшәгән бабаларыбызны эзләп, мирасханәләргә ничә меңнәр сарыф иткәнемне төгәл генә әйтә алмыйм, санап бармадым, йөз генә түгел. Сатып алганчы, эзләп табарга кирәк бит әле ул документларны. Патша Россиясендә налог түләтер өчен 10–20 ел саен уздырыла барган ревизияләрнең саны унау һәм анда ясаклы-йомышлы, типтәр-башкорт, ям татары, рекрут, служилый, торговый һ.б. татарларның ревизияләре аерым язып барылган, ләкин аларның шактый өлеше юкка чыккан, югалган.

Менә шулай дистә елга бер генә яктыртылып барган тормышны мин төнге ай яктысына охшаттым. Төнлә чалт аяз күктәге тулган ай яктысы да кояштай бөтен дөньяны яктыртып бетерә алмаган кебек – әйберләрнең иң калкуы, иң зуры, якыны гына күренә бит ай нурында. Аллага шөкер, унөч ел элек чыккан «Чәшелем-асыл илем» китабының дәвамы, шушы документлар нигезендә язылган «Ай нурында нәсел сукмагы» исемле китабым Казанда басылуда. Башлагач, бер тотынган эшне эшләп бетерәсем килде.

Беренче китабымда XX гасырда авылда яшәгән һәр кешенең нәсел шәҗәрәсе бар иде. Икенче китапка архив, Диния Назәрәте, интернет чыганакларын да файдаланып, тирәнгәрәк төшеп, авылның XVIII гасырдан алып бүгенгәчә тарихын өйрәнеп яздым. Ул нәселләр саны 62 дән 14 кә генә калды. Кайбер нәселләр 12–15 буынга җитте.

Шул 14 нәселнең өчесен 1-нче ревизиядән үк барлыйм: алар Чистайдан Акбулат, Зөя буендагы Колгына һәм Норлатның Колбай-Мораса авылларыннан. Биш ыруны 2нче ревизиядән, ике төпне 3нче ревизия һәм дүрт нәселне 4-нче ревизиядән табып, һәр кешене берәмләп, барлык ревизияләрдән күзәтеп чыктым.

1747 елгы 2 ревизия вакытында Шәчәле авылында биш гаилә төпләнеп яши. Анда 11 ир-ат заты теркәлгән һәм шулай ук хатын-кызлар да булырга кирәк. Димәк авылда 22 кеше яшәгән. Алар барысы да бергә килеп утырмаганнар, чөнки төрле яктан килүчеләр. Мәсәлән: Калми Бәҗин Казан өязе Алат юлындагы Бәрәскә авылыннан, Ишмәмәт Килмәмәтов Шөкер авылыннан, Кинҗәгол Казаков Уфа өязе Казан юлындагы Тойняшево авылыннан, Иван Ишмәев Галич юлындагы Шапово авылыннан һәм Гадел Әлмәкәев Уфа өязе Казан юлындагыТойбаш авылыннан. Шәчәлинең Югары яки Түбән икәне билгеле түгел, әмма Шәчәли елгасы буенда икәне язылган. Түбән Чыршылыны Куак елгасы буенда урнашкан дип язалар иде, димәк бу Югары Чыршылы. Моны тагын ике тарихи факт дәлилли:

1. Бу кешеләрнең дәвамчылары һаман да безнең авылда яши.

2. Түбән Чыршылының алдагы ревизияләрендә дә аларның дәвамчылары юк.

Авылның киң үсеш алган чоры 1780–1795 еллар тирәсендә: авыл күчеп килүчеләр хисабына зурайган, даны арткан. Мәсәлән ясаклылар: Сугышлыдан Сәфәр Бикчурин; Кәминкәдән Колмәт Габдулов, Минкә Миңлебаев, Гадел Ниязов, Хәсән Кутуевлар килгән; Ибрай авылыннан Кусадыйковлар күченгән һ.б. Йомышлы татарлар 4 бертуган Сәлиевләр Тимәш авылыннан килеп төпләнә. Ә типтәрләр – 4 бертуган Мөхсиновлар һәм Аккүз Кинҗин Түбән Чыршылыдан менгәннәр. Ачыклыйсы килгәннәр менә шулар. Калганын китаптан укып белә алырсыз.

Лениногорск районы Татарстанда гүзәл табигате белән генә түгел, атаклы шәхесләре, иң күп Советлар Союзы каһарманы үстерүе, җир асты байлыклары белән дә данлыклы. Җырга әверелгән Шөгер авылы, Керкәле тауларын кемнең ишеткәне-күргәне юк? Тимәш-Утыз Имәние һәм беренче нефте белән билгеле, Бәкер-күкертле ләме һәм курорты, Керкәле-балыгы, Сарабиккол-дегете, Глазово-бакыр руднигы, Шөгер-битумы белән билгеле булса, Түбән Чыршылы-мәдрәсә һәм мөгаллимнәре, анда 20 ел яшәгән журналист, галим, мөфти Риза Фәхретдин белән горур-

лана. Зәй-Каратай – галим һәм укытучылары, Туйкиннар белән тарихка кереп калган. Югары Чыршылыда һөнәрчеләрдән итек басучы һәм балта осталары мактаулы булган. Һәм анда бик тырыш, ихлас күңелле халык яши.

Сарабикколның данлыклы кешесе Рәшит Якупов беренчеләрдән булып, туган авылы тарихын язып чыкты. Шуннан соң без дә ирем белән, «чүлмәкчедән күрмәкче» дигәндәй, дәртләнеп, Зиннәтулла Насыйбуллин кулъязмаларына таянып, Югары Чыршылы китабына алындык. Афәрин, Рәшит абый!

Тимәш авылының 1762 елгы ревизиясендә бик кызыклы мәглүмат язылган: 1770 елның 4 августында Утыз Имәни авылыннан 10 кеше «йомышлы татарлар» булып күчеп килгән. Шулар арасында Утыз Имәни һәм Тимәш авылларын бөтен дөньяга танытачак атаклы язучы Габдерәхим Госман улы Сөрмәкәев (1752–1835) тә бар. Алар 4 туган: Димәкәй, Уразмәт, Габдерәхим һәм Җәгъфәр Госмановлар, ике туганнары Габделҗәлил һәм Габдулла Исмәгыйлевләр һәм тагын 4 бертуган Сәли улы Курманаевлар Тимәш авылына күчкәннәр.

Ирем Ямаев Ильяcның нәсел башы Рысай 1 ревизиядә Норлат районы Колбай-Мораса авылында язылган. Рысай улы Курманай, Курманай улы Сәли 1762 елда Кади авылында яшәп, аннан Тимәшкә күчкән. Сәлинең 4-улы 20 еллар яшәгәннән соң Тимәштән Югары Чыршылыга килеп төпләнгәннәр. Утыз Имәни туганнарының берсе – Тәминдар Абдуллин – Югары Чыршылыга, ә күбесе Түбән Мактамага күченгәннәр, кечесе Тимәштә калган. Анда бу елларда шулай ук Түбән Чыршылы, Кәминкә, Ибрай һәм Алешкино авылларыннан да күчеп килгәннәр. Кешеләрнең яхшырак тормыш, мул җирләр өмет итеп башка урыннарга күчеп йөрүе һәрвакыт булып торган. Мәсәлән: Ю.Чыршылыдан 1907 елда аграр реформадан соң 13 гаилә Чыршылы хуторына, 1926 елда Урманайга, 1930 елда Бөгелмәгә, 1932 елда 10 гаилә «Микоян» совхозына күчкәннәр. Ә хәзер Урта Азия илләрендәге карендәшләребез кире авылга кайталар. Буш йортлар юк.

Югары Чыршылы авылының 1830–1930 елгы метрикалары нигезендә 100 елга анда 3404 кеше туган, 2288 кеше вафат. Никахлар саны 838. Шуларның 105 пары аерылган. Уртача елына туучылар саны 34, вафат булучылар 23, никахлар 8 һәм аерылышучы 1 пар килеп чыга. Хәзерге көн белән чагыштырып та булмый!

Нәсел җепләренең бәйләнешен метрикадагы никах язулары аша күрергә мөмкин. Никах туе кыз йортында булып, аның туган авылында теркәлеп калган. Ул вакытларда кыз урлау, ияреп чыгу вакыйгалары да булгалаган. Йөз елга (әмма 10 елның метрикасы сакланмаган!) 838 никах

хөтбәсе укылып, шуларның 290-ы үзебезнең Югары Чыршылы егетләре белән. Икенче урында 3 кенә чакрымдагы Түбән Чыршылы авылы-анда 124 кияү яшәгән. 58 кызыбыз Куакбаш авылы егетләренә пар булган. Чупайдан 47 егет килеп, Чыршылы кызларын алып киткән. Аннан соң Кирлегәч, Зәй-Каратай, Иштирәк, Мактамабашы. Шушы 100 ел эчендә Сарабикколдан 20 ир-егет Чыршылыдан үзләренә яр, балаларына ана тапканнар. Ә күпме Чыршылы егете Әби авылыннан килен алган?! Әле төшеп калган елларны да өстәсәк, 3–4 ел саен Сарабиккол белән Ю. Чыршылы арасы якыная барган, туганлык арткан. Никах язуларында барысы да язылган: кем вәли вәкил, ризалык шаһите, мәһәргә нинди ат һәм сыер бирелгән, никах укучы мулла исеме һәм кул тамгалары да бар.

Инде зиратларга күчик. Югары Чыршылыда ике каберлек бар: югары очта «башкорт» зираты, түбән очныкы «мишәр» зираты. Борынгыдан килгән гадәт буенча, әле хәзер дә кешеләрне нәселенә карап, югары очта яшәсә дә, түбән очка төшереп күмәләр. Хәтта кайсыбер очракларда ир белән хатынны да аерым күмәләр. Моннан 15 еллар элек андагы һәр ташны укып, укый алмаганын фотога төшереп, 573 кабер санап чыккан идем. Соңгы елларда да бик күп әрвахлар күмелде, шәһәрдән дә кайтаралар. Ун елга 127 кабер артты. Бер хыялым да бар: шул каберстанның генпланын ясый алсам иде! Юкса, күп каберләрнең агач буралары череп, чардуганнары ишелеп, ташлары авып, җиргә сеңеп, кабер өстен агачлар басып китте. 15 еллар элек ирем Ильяс үзе Әлмәттән кран чакыртып, ziратта карт агачларны кисү өмәсе оештырган иде. Агач-куаклар нде яңадан үсте. Быел авыл картлары мәчетнең сәдака акчасына җәй-көз айларында ике каберлекне дә бик нык чистарттырдылар. Алланың рәхмәтендә булсыннар.

2014 елда бәйрәмгә ямь, кешеләргә гамь өстәлсен дип, күптән хыялланган эшне башкара алдым! Гарәпчә язылган ташларны фотога төшереп, Казанга җибәрдем. Галимнәр 28 ташны укый алды. Аның исемен укып кына кешесен ачыклап булмый, туган-үлгән елы да сакланмаса. Алар бит 100–200 ел элек яшәгән, фамилияләре юк. Кем икәнен ачыклар өчен мин ай буе архивтан метрика, ревизия материалларын өйрәндем. Беренче чыгарган китабым да ярдәм итте: кайсы төпкә кергәнен ачыкладым. Һәр кабернең иясе табылды. Борынгы ташлар башкортлар зиратында күбрәк сакланган. Мишәрләр зиратындагы ташлар җиргә сеңеп, язулары, тамгалары юылып беткән.

Бу ташъязмаларны укытуның бер сере дә бар иде – Риза Фәхретдиннең абыйсы Минһаҗетдиннең кабере табылмасмы икән, – дип. Минһаҗетдиннең улы Гаязетдин 1924 елдан Югары Чыршылыда имам булып эшләгән. Репрессия вакытында аны кулга алгач, атасы Минһаҗетдин кайгы-

дан авырып, вафат булган. 5 кечкенә бала белән терәксез калган килене Бибиҗиһан Ногайбекова Карабашка абыйсына кайтып китсән. Ул вакытта аның таш яздыру кайгысы булмагандыр шул... Ә бит Минһаҗетдин Фәхретдин улы үзе бик оста кәтиб (ташка язучы) булган. Аның хезмәтләре тирә-як авылларда шактый сакланган. Сарабиккол китабындагы таш та аның хезмәтенә охшап тора. Р.Фәхретдиннең абыйсы Кәшәфетдин уллары Мәхмүт һәм Самат та Чыршылыда имам булып эшләгәннәр. Югары Чыршылының 290 еллык юбилее бәйрәмендә без хәтер яңарттык- Ризатдин Фәхретдин туганнарын авыл бәйрәменә чакырып кунак иттек.

Ата-ананың ул-кызларына васыятендә гореф-гадәтләрне белү өстенә, борынгыдан килгәнчә 7 буын бабасын белү, аларның каберләрен зиярәт итү кебек шөгыльләр фарызлардан саналып (үтәү мәҗбүри), кечкенәдән балаларның аңына сеңдерелсен иде. Монда тәрбияче һәм укытучыларның ярдәме зарур. Төбәгебез тарихы киләчәк буыннарга кәгазьдә басылып калсын. Үз авылының борынгы яшәү рәвеше рухи байлык булып күңелләрне биләсә, йөрәкне җилкендереп, изге эшләргә рухландырып торса, яшәүгә дәрт өстәлер иде. Бабалар рухына дога кылып яшик. Догалы булсыннар!

**Әдәбият:**

1. РГАДА, фонд 350, оп. 2, дело 2450. 2 ревизия материаллары.

2. ЦГИА РТ, РБ. Ревизские сказки

3. Самара губернасы Бөгелмә өязенең 1830 елгы метрика кенәгәсе. И-295, ф. 9, оп. 549

4. Ризатдин Фәхретдин. «Асар». Казан: «Рухият». 1–4 томнар.

5. З. Насыйбуллин, Ә. Ямаева.«Чәшелем-асыл илем». Казан: «Тамга». 2004 – 300 б.

# ВОЗВРАЩЕННЫЕ ИМЕНА: НЕКОТОРЫЕ ТЕОРЕТИЧЕСКИЕ И ПРАКТИЧЕСКИЕ ПРОБЛЕМЫ СОЗДАНИЯ ЭКСПОЗИЦИЙ ЛИТЕРАТУРНЫХ И МЕМОРИАЛЬНЫХ МУЗЕЕВ РТ

***Ф. К. Даминова***

Музейное строительство в Татарстане в последние годы входит в новый этап своего развития. Каждый год рождаются новые музей, строятся новые экспозиции, среди которых значительный удельный вес занимают государственные и муниципальные музеи исторического профиля, музеи персонально-биографические, посвященные видным деятелям татарской культуры и представителям культуры других народов края, ведомственные (музей истории предприятий, вузов, организаций), школьные.

На музейный бум в Татарстане на рубеже тысячелетий наложила отпечаток сложившаяся общекультурная ситуация в республике, связанная со сменой приоритетов, когда прошлое, настоящее и будущее отдельных регионов, предприятий, организаций стало рассматриваться во взаимосвязи. Всё сильнее звучала в этот период мысль о том, что нельзя двигаться в будущее, не зная своих истоков. Исследователями, учёными, музейными специалистами осмысливались и становились всеобщим достоянием целые пласты новых источников, ранее скрытых за стенами спецхранов, архивов и частных коллекций. Столь обширное музейное строительство в Татарстане стало возможным и в связи с тем, что в республике находится один из старейших музеев России – Национальный музей РТ со 115-летней своей историей, где сконцентрированы высококлассные специалисты различного профиля. Поэтому не случайно, что практически все музейные проекты в Татарстане осуществляются при активном участии специалистов Национального музея РТ.

Кардинальная «ревизия» истории татарского народа привела к пересмотру многих политических оценок и ярлыков, в том числе в отношении представителей татарского реформаторства. Это не могло не отразиться на музейном строительстве в республике.

27 мая 1997 годы было принято Постановление Кабинета Министров о создании на родине Г. Исхаки в дер. Яуширма Чистопольского района Историко-мемориального и этнографического комплекса. Предстояло реализовать грандиозный по тому времени проект – соединить воедино сохранившийся кирпичный дом рубежа Х1Х – начала ХХ вв., принадлежавшего Сайфутдину – мужу родной сестры Гаяза Исхаки, и вновь вы-

строенный жилой дом с дворовыми постройками отца писателя – муллы Гилязетдина.

Создание любого музея связано с целым комплексом проблем, которые очень трудно решались из-за отсутствия финансирования. Начавшийся экономический кризис привел к тому, что многие виды работ выполнялись по взаимозачету. Строительство асфальтированной новой дороги, гостиничного комплекса, пункта быстрого питания, благоустройство села и родника, капитальный ремонт Дома культуры и здания средней школы – вот только ряд проблем, которые были в тесной взаимосвязи с созданием музейного комплекса.

Творческой группе ГОМ РТ в составе С. И. Матвеева, А. Д. Хайруллиной, Л. Г. Краевой, Г. Р. Зигангировой, Л. Е. Еньковой, А. Р. Аскаровой была создана музейная экспозиция, которая отражала основные этапы жизни, общественной и творческой деятельности Г. Исхаки. Экспозиция начинается с рассказа о детстве Гаяза Исхаки, его семейном окружении. Воссоздана атмосфера быта дома муллы. О незримом присутствии хозяев дома напоминают Коран, шамаили, здесь же можно видеть традиционную одежду муллы и подлинные четки. Мир матери писателя, Камарии абыстай, воссоздается через предметы женской одежды. Важное место занимает генеалогическое древо семьи. Интересно решена и экспозиция зала, отражающего начало литературной и общественно-политической деятельности Г. Исхаки.

Своеобразным символом его жизни и творчества стала тюремная дверь, изготовленная по подлинному образцу, хранящемуся в фондах НМ РТ. Не раз приходилось ему ощущать на себе внимание российской полиции, которая пристально следила за одним из лидеров татарской нации. Здесь же – фрагмент интерьера кабинета писателя: письменный стол с чернильным прибором, раскрытая книга, керосиновая лампа. Рядом на книжной полке фотографии дочери Сагадат. На стендах – документы, рассказывающие о Г. Исхаки как лидере татарских эсеров, издателе газет «Ил» и «Сүз» и другие архивные материалы. Ряд экспонатов рассказывают о его отходе от эсеровского движения, стремлении к объединению всех слоев татарского народа, деятельности его на посту председателя комитета мусульман г. Москвы и участии в работе Первого и Второго мусульманских съездов.

Значительная часть экспозиции посвящена периоду эмиграции в Харбине, Берлине, Париже, Варшаве, в Турции. Широко представлены произведения Г. Исхаки, изданные за рубежом, в том числе историко-публицистический труд «Идель-Урал», переведенный на многие языки. На многочисленных фотографиях Гаяз Исхаки запечатлен с соотечествен-

никами-эмигрантами в Германии, Финляндии, Китае, Франции и других странах.

Открытие Историко-мемориального и этнографического комплекса Гаяза Исхаки состоялось 30 июля 1999 года. «Гаяз Исхаки вернулся на родину», – сказал Президент РТ М. Ш. Шаймиев на митинге в Яуширме. В церемонии открытия принял участие консул Турецкой республики в Татарстане Ахмет Риза Демирель, благодаря которому были получены документы о жизни Г. Исхаки в Турции и ряд мемориальных предметов.

На первом этаже в сохранившемся кирпичном доме рубежа XIX – начала XX вв., принадлежавшего Сайфутдину – мужу родной сестры Гаяза Исхаки, была воссоздана сельская торговая лавка

К 180-летию известного татарского просветителя и религиозного деятеля Ш. Марджани, в соответствии с постановлением Кабинета Министров РТ, 29 сентября 2000 года был открыт Музей Ш. Марджани в с. Коморгузя Атнинского района.

К моменту принятия решения Кабинета Министров РТ в Коморгузинской средней школе уже существовал музей на общественных началах. В сельском музее были представлены: косметичка, четки, столовые приборы, с которыми Ш. Марджани ездил на хадж; предметы мебели из квартиры Габдуллы Апанаева, зятя Ш. Марджани (шкаф-горка, стол, стулья, комод), которые были переданы музею потомками Ш. Марджани – правнучками Н. Т. Ильясовой и С. А. Мустафиной.

Новый музей создавался творческой группой ТОМ РТ (Ф. А. Зиязов, Р. Г. Гарифжанова, А. Д. Хайруллина, Ф. К. Даминова) в двух классных кабинетах Коморгузинской средней школы. Необходимо было, с одной стороны, сделать его доступным для школьников, с другой добиться, чтобы он имел свое собственное лицо. В процессе работы над художественной концепцией экспозиции было решено увязать ее с религиозной деятельностью Ш. Марджани. Главным художником НМ РТ Ф. А. Зиязовым был выполнен орнамент на потолке, использована цветная живопись по стеклу на окнах, вертикальные витрины были изготовлены в виде окон мечети и горизонтальные – в виде раскрытой книги – Корана.

Ограниченность пространства музея позволила воспроизвести только наиболее характерные типологические предметы интерьера татарского сельского дома, которые могли окружать в детстве будущего ученого. Важное место в экспозиции было уделено годам его учебы в Бухаре и Самарканде, где Ш. Марджани имел возможность познакомиться с трудами Г. Курсави, уроженца дер. Верхняя Курса Арского района. Для придания этому разделу восточного колорита были использованы современные изделия декоративно-прикладного искусства народов Востока, на

окнах размещены цветные витражи, отражающие вехи жизненного пути Ш. Марджани – медресе Кугельдаш, Ширдар, черный камень Кааба, место поклонения мусульман всего мира, куда в 1880 г. ученый совершил хадж.

История любого музея – это, прежде всего история человеческой памяти, гражданственности. В 2000 г.творческая группа ГОМ РТ принимала участие в рождении новой экспозиции – Дома-музея Х. Туфана в с. Ст. Киреметь Аксубаевского района (авторы: Ф. А. Зиязов, Р. Г. Гарифжанова, А. Д. Хайруллина, Т. Б. Чканова).

В соответствии с утвержденным проектом усадьбы планировалось реконструировать дом отца поэта и хозяйственные постройки по точным их описаниям. Сам объект, хотя и строился на месте дома, где родился Х. Туфан, мемориальным можно назвать лишь условно: слишком много времени прошло.

Было решено показать жизнь и творчество Х. Туфана не в хронологической последовательности, а сделать акцент на тех годах, которые он провел в с. Ст. Киреметь. Авторы экспозиции посчитали логичным начать экспозицию с темы, посвященной истории деревни, детским и юношеским годам Х. Туфана.

При выработке архитектурно-художественного решения экспозиции приходилось учитывать специфику самого деревянного здания. Решено было использовать имитацию элементов жилой татарской избы. Вертикальные витрины были выполнены в виде традиционных татарских полотенец, при этом в первом зале стилизовали их под домотканые с красными концами, во втором – полотенца завершались кружевным орнаментом.

Разнообразными оказались книги из личной библиотеки поэта: классиков татарской литературы, чье творчество оказало на него большое влияние – Г. Тукая, Х. Такташ; русской поэзии – С. Есенина, В. Маяковского, В. Пастернака; современников – С. Хакима, Г. Баширова, И. Юзеева, М. Галяу, Ш. Маннура и др. Здесь были книги, изданные в 1930-е, 1950-е, 1980-е годы, на многих из них специфическими, именно Х. Туфану присущими, зелеными чернилами сделаны пометки на полях. Это позволило воочию представить творческую лабораторию поэта, проследить круг его чтения и литературных пристрастий, а также, в какой-то степени, представить историю развития татарской книги на протяжении XX века.

В экспозиции Дома-музея были созданы два интерьера: фрагменты крестьянской татарской избы и казанской квартиры поэта. В первом случае, имея достоверные данные предназначении всех помещений дома и

описание внутренних убранств комнат, интерьер воссоздавался из типологических предметов эпохи, собранных в Ст. Киремети. При воссоздании интерьера казанской квартиры Х. Туфана был осуществлен фрагментарный показ сохранившихся предметов мемориальной обстановки из разных квартир поэта, куда вошли книжный шкаф, стол, два кресла, зеркало.

Большая работа создателями музея была проведена в поисках документов следственного дела Х. Туфана, арестованного в 1940 году. В «Фонде вещественных доказательств» ЦГА историко-политической документации РТ сохранились сигнальный оттиск поэмы «Ант» с авторскими пометками, объявление о провозглашении в 1918 году в Казани Идель-Уральской республики. Пожелтевшие страницы следственного дела, документы о реабилитации... И среди этого обилия документов – небольшая, неровно порванная фотография дочери поэта. Незадолго до своего ареста Х. Туфан снялся в фотоателье г. Казани со своей дочерью Гульнарой, но в обстановке всеобщего страха чья-то рука спешно разорвала ту часть фотографии, на которой был изображен Х. Туфан. Подобная участь постигла многие фотографии, поэтому как немые свидетели эпохи сегодня во многих музеях экспонируются фотографии с выколотыми, выскобленными, замазанными чернилами лицами. Словно в одночасье пытались уничтожить не только самих людей, но и память о них. Немногие из них вернулись после амнистии. Х. Туфану повезло, он выжил в этих нечеловеческих условиях. 16 долгих и бесконечных лет поэт был оторван от родного народа, литературной среды, семьи.

Все рассмотренные выше музеи объединяет одно, их герои являются потомками представителей мусульманского духовенства, самой образованной и уважаемой части татарского общества. В экспозиции этих музеев запечатлена жизнь татарской деревни и политический пафос разных эпох. На судьбы Ш. Марджани, Г. Исхаки, Х. Туфана наложили свой отпечаток социально-политические противоречия действительности, в которой они жили и творили. Это нашло отражение в экспозициях, где использовались специфические способы отбора и обобщения исторического материала, для которых характерны такие черты, как целостность и избирательность, подлинность, образность, конкретность. Благодаря этим свойствам, каждый из этих музейных комплексов занимает свое место в деле формирования исторического мировоззрения населения республики и обогащения исторических представлений о прошлом татарского народа на разных этапах его истории.

# СЕБЕРТАТАР ХАЛКЫ КӨНКҮРЕШЕ

***М.Х. Сәгыйдуллина***

Себер җирлегән һәрбер кеше үзенчә күзаллый: кыргый җанварлар оясы, кырыс салкыннар яки каторжаннар иле. Ничек кенә күзалласаң да, Себер ул төпсез сазлыклар уртасында, бормаланып аккан елгалары буенда бер-бер артлы тезелеп утыручы татар авылларында гомер кичерүче җирле себертатар халкының туган нигезе.

Себер татарлары гомер-гомергә үз көннәрен үзләре күреп, бер карaганда, иркле тормыш алып барды сыман. Әмма чынбарлык тормышта, аларның көнкүреше, яшәеш рәвеше тулаем табигатькә бәйле. Ел әйләнәсендә себертатар халкы күл-урманнар белән бәйләнештә. Һәр фасылның үзенең билгеле бер файда китерә торган мизгеле була. Әлеге мизгелләрне вакытында дөрес һәм файдалы куллана белү – гаиләне акчалы да, тук та итү дигән сүз. Моннан тыш әле туганнарның бергәләп җыелган чагы да була бу.

Себердә киң танылган, ел саен ырудаш-туганнар, кан-карендашлар белән җыйналышып, зарыгып көтеп алына торган вакыт – көз айлары. Әлбәтә, көз ул – елның иң мул, иң бай вакыты. Аның бер көне дә халык өчен ел буе яшәрлек акча эшләргә мөмкинчелек бирә. Әмма көз – себер татарлары өчен үзенчәлекле шөгыльләрдән саналган козык (эрбет чикләвеге) сугу һәм тырнагүз (мүк җиләге) җыю вакыты.

Козык – кедр чикләвеге. Аның нинди бәһәле товар икәнлеге күпләргә таныш. Бары тик Себер төбәкләрендә генә бай козыклыклар бар. Томск, Красноярск, Омск һәм Төмән өлкәләре Россия халкын гына түгел, ә якын тирә чит илләрне дә козык җиме белән тәэмин итеп тора. Төмән өлкәсенең иң уңышлы козыклыклары Вагай районында урнашкан. Бу районда бүгенге көндә киң танылган козыклыклардан – Быково, Полино, Полуяново, Фатеево, Шабры, Шевелево, Тартас җирлекләре санала.

Козык август аенда җитешә. Бу шөгыльне үз итүчеләр июль аеннан козыклыкларны әйләнеп, даими күзәтеп тора. Җимешләре җитлегү белән халык урманга агыла. Якын-тирәдә агачлар булмаган очракта, чатырлар алып, ерагырак авылларга куна баралар.

Элегрәк урман сакчыларының әмере буенча август аеның бер көне (гадәттә ул 15 август була иде), козык сезоны ачылуы буларак махсус бәйрәм ителә иде. Бу көн исә татарлар өчен генә түгел, ә тирә-юньдәге барлык халык өчен зур шатлык булды. Шундый бәйрәмнәрнең иң зурысы Иртыш елгасы ярында урнашкан Катымбуй һәм Быково урманлыкларын

берләштергән аланда уздырылып килде. Иң кызыгы шунда, безнең татарлар, әллә хәйләкәр булганга, әллә инде дөньяның төрле хәлләрен күргәнгәме, бәйрәм ачык дип белдерелү белән ук урманлыкка агыла башлый иде. Вакытны заяга уздырмыйча, күбрәк файда китерү ягын карарга тырыштылар. Бу көннәрдә күп балалы гаиләләр 40–50 капчык чикләвек *«сугарга»* өлгерә! Козык *«сугу»* дигәннән, моның тулы мәгънәсен күпләр аңламаска мөмкин.

*Козыкны ничек сугалар соң?* Бер кеше (гадәттә ирләр, әмма хытын-кызлар булу да ихтимал) агач башына менеп, *«шиштәм»* дигән озын, уртача калынлыктагы колга белән агач башындагы козыкларны сугып төшерә, ә җирдәге кеше козыкларны җыеп капчыкка тутыра бара. Суккан кеше агач башыннан икенче баерак агачны карап төшә. Кайвакытта, җирдәгесе баерак агачны эзләп табып, саклап тора, тегесе исә тагын менеп китә. Алдан әзерләнеп тормасаң, буш агачка да менүең бар, чөнки һәр агачның уңышы төрлечә. Ә мондый чакта һәр минуты кадерле. Капчыклар тулган саен бәйләп билгеле урынга куя баралар.

Август ахырларында козыклар тәмам җитлегеп беткәч, көзге көчле җилләр уйный башлау белән козыклар җиргә коела башлый. Бу көннәрдә урман эче халык белән шыгрым тулган була. Чөнки коелган козыкларны җирдән җыюы җайлырак. Уңдырышлы елларны көненә хәтта 10–15 капчык җыярга да мөмкин.

Козыкны җыеп авылга кайткач, иң кызыгы башлана. Әйтик, тонналаган уңышны тиз арада ничек чистартып, киптереп җитешергә? Һәркемнең үз җае, үз ысулы. Иң кулае – ясалма сепаратор. Агач такталардан казан ясап эченә әйләнмә механизм урнаштыралар. Әлеге җайланма моторга тоташтырыла һәм бензин белән эшләүгә көйләнә. «Сепаратор» аша әйләндергәннән соң чыккан массаны ике төрле *«иләк»* (решето) аша уздырып, козыкны киптерергә җәяләр, аннан вентилятор белән тагын бер тапкыр вак чүпләрен, тузанын чистарталар. Аннан кояш астында җәеп, саклап торып киптерәләр. Чөнки карап тормасаң каргалар тиз ияләшергә мөмкин. Әзер козыкларны капчыкларга тутырып, җилләнеп торучы, әмма тычкан борынын тыга алмаслык амбарларга урнаштыралар.

Козык сезоны үтеп тә өлгерми, тырнагүз вакыты килеп җитә. Бу вакытта күпчелек сунарчылар (табигать байлыкларын җыеп, тормышта шуны кулланып яшәүчеләр) урманда яшәүне кулай күрә. Чөнки якын–тирәдән бала-чага да кайтып керми, шуңа күрә күпләп җыеп булмый. Якын-тирә дигәне ул инде 8–10 чакрымдагы сазлык була. Ераграк сазлыкларда (15–20 чакрым һәм аннан да ераграк) махсус бәләкәй агач йортлар төзелгән, җирле халык аларны *«избүшкә»* дип йөртә. Табигать байлыкларының файдасын күрергә өйрәнгән кеше үзенең балалары, гаиләсе

өчен билгеле бер күлдә үз «избүшкәсен» төзи, ел саен яз-көз айларында шунда яшәп тырнагүз җыя. Сезон җитү белән, җитәрлек итеп азык-төлек хәстәрләп, сазлыкка юл ала...

Әлбәттә, моны сөйләве генә җиңел, чынлыкта исә бу бик газаплы шөгыль. Шушы төбәктә, шушы җирлектә туып-үскән себер кешесенә бу гамәл – гадәти эш. Шунысын да искәртәсе килә, әлеге төбәктә туып, язмышы табигатькә, урманга бәйле булган һәрбер бала кайда нинди күл, нинди сазлык, нинди җирлек урнашканын барысын яттан белә, төнлә уятып сорасаң да аңлатып бирә ала. Боларның һәкайсын белеп тору сунарчылар өчен зур горурлык һәм әйтеп аңлата алмаслык зур байлык.

Соңгы елларда сазлыкта йөрү өчен болотоход дигән ясалма транспорт популярлык казанды. Хәленнән килгән һәр ир-зат әлеге транспортны булдыру юлларын карый. Болотоходка утырып сунар кылу күпкә җайлырак. Җыйган җимешне урманда калдырып йөрмичә йортка кайтарасың, аннан ераккарак та китеп була. Тырнагүз бик нәзберек җимеш, теләсә кайсы сазлыкта үсми. Бер елны ул *көтәле* (кочка) сазлыкта булса, икенче елны цөйлектә (ылыслы агачларның зур бер төркем булып тимгел-тимгел урнашуы) өченче елны – *яланда яки калым* (сулы, калкып ятучы) сазда булуы ихтимал. Сазлыкны, җирлекне белмәгән кеше көне буе урманда йөреп бер килограмм җыймыйча кайтырга мөмкин.

*Тырнагүзне нәрсә белән җыялар?* Тырнагүзне күпләп җыяр өчен иң башта махсус *«кыргыц»* әзерләү мөһим. Элегрәк тирәнрәк консерва савытыннан ясыйлар иде. Башта агач таякны юынып сап ясыйлар (диаметры якынча 2,5–3 см., озынлыгы – 15–20 см). Аннан консерва савытының авызын чүкеч белән төеп тигезлиләр. Эшкәртелгән консерва савытын сапка беркетеп куялар. Хәзер исә халык җайлашты – кибеттән гади чүмеч сатып ала да, тоткычына агачтан сап ясап беркетә.

*Ничек җыярга?* Тырнагүз җыю ул – гадиләштереп авыл телендә әйтсәк, *«бил бөгеп кәлгенеп(селкенеп) йөрү»*. Сул кулга чиләк, уң кулга – кыргыц тоталар. Тырнагүз үскән көтәгә килеп чиләкне җайлаштырып аскарак тотасың. Әз генә иелеп уң кулдагы кыргыц белән тырнагүзне чиләккә таба кыра башлыйсың. Җыеп бетерүгә, икенче көтәгә күчәсең. Кайвакытта табыш көтәсез тигез яланда булуы да бар. Көнозын иелеп кырынып йөрисең. Вакыт-вакыт кул белән чиләк эчен болгата-болгата мүкләрен алып ыргытасың. Чиләк тулгач капчыкка тутырып барасың. Төшке аш вакыты җитү белән тиз генә җәймәгә яки клеенкага җәеп (махсус әзерләнгән була) тырнагүзне «йелтиләр», ягъни чистарталар.

*Тырнагүз йелтәү.* Җәймәне җиргә җайлаштырып җәяләр. Җилгә каршы басып, тырнагузле чиләкле өскә күтәреп селкетә башлыйлар. Тегеләр аска сикерешә торалар, чүпләрен җил очыртып бара. Җил катырак иссен

өчен сызгырып торырга кирәк. Чистартылган тырнагүзне капчыкка тутырып бәйлиләр һәм һәркем үзенең пәтнәсен (тамга) сала. Гадәттә исемен язып куя. Җыйганны һәркем үзе белән алып кайта. Урманда калдырсаң капчыклар тиз «аяклана». Күлдә, яки урманда избүшкәдә куна ятып җыючылар йөк тулуга авылга кайтара торалар. Чөнки азык-төлеккә дә атнага бер тапкыр кайтып килергә кирәк була.

Избүшкәдә куна ятып җыйганда да ераккарак китергә туры килә. Төшке азыкны һәркем үзе белән йөртә. Элегрәк махсус чиләк була иде. Төш вакыты җитү белән көн саен чиратлашып чәй кайнатасың, кайвакытта кайнар аш яки шулпа пешерәсең. Хәзер вакыт уздырып тормыйлар. Кайнар чәйне дә ризыкны да термосларга салып йөртәләр. Аннан тырнагүзле урынга төшсәң кеше төтен исен иснәп синең уңышыңны бүлешеп җыюы бар. Үзе эзләп тапкан өлеш белән беркемнең дә бүлешәсе килми.

Элегрәк шундый гадәт булган: һәр *тогымның* (ыруның, нәселнең) үзенең билгеле бер җирлеге булган. Әйтик, минем бабайның биләмәләре Казанлы авылы җирлегендәге *Ецкә* күлдә һәм *Утраулыда* булган. Бу җирлекләрне аннан да яхшырак белүче булмаган. Чөнки тырнагүзлек теләсә кайсы сазлыкта үсми. Аның кайсы елны нинди урында буласын бары тик шул җирлек хуҗалары гына белеп торган. Ә алар авызыннан артык бер сүз дә яңгырамый. Һәркем үз биләмәсендәге табигать байлыгын үз гаиләсе белән җыя. Без кечкенә вакыттан шушы биләмәләрдә бил бөгеп тир түгеп үстек.

Булдыклы уңган хуҗалар бу биләмәлекләр белән генә чикләнми. Һәр ир зат үз балаларына тайгада йөрергә, яшәргә җайлашырга, аның матурлыгын тоярга, аның белән гармониядә яшәргә, сулышын сиземләргә, гомумән көн күрергә өйрәтеп калдыра.

Себер татарлары урман-тайгадан башка тормышны күз алдына да китерә алмый. Ничек кенә авыр һәм мәшәкатьле булмасын, козык сугу да, тырнагүз җыю да себер татарлары тормышының алыштыргысыз яшәү рәвеше. Бу гаҗәеп гамәлләрне алар яратып, күңел биреп, һәр мизгеленнән тәм тоеп рәхәтләнеп башкара.

# ПРОБЛЕМЫ ИСТОРИКО-КРАЕВЕДЧЕСКОГО ИЗУЧЕНИЯ РЕГИОНА
## (На примере работы Творческой группы «АльметьевскойЭнциклопедии»)

***Р.Х.Амирханов,***
***бывший руководитель Творческой группы***
***Альметьевской Энциклопедии,***
***председатель фонда***
***«Альметьевская Энциклопедия»***

Альметьевский край имеет богатейшую историю, во многом еще не исследованную, является родиной большого числа выдающихся людей. Создание истории Альметьевского края было востребована самой жизнью. Поэтому в последние дни 1995г. руководством ОАО «Татнефть» (генеральный директор Р.Г.Галеев), администрацией Альметьевского района и города Альметьевска (главаадминистрации И.В.Гареев) было принято совместное решение о создании истории Альметьевского края в энциклопедическом варианте. Новосоздаваемая Энциклопедия должна была отразить как историю данного региона, так и сегодняшний день, дать всесторонние сведения об экономике, культуре, образовании края, населяющих его народах, выдающихся личностях. Одновременно создавалась Энциклопедия нефтяной промышленности республики со сведениями об истории отрасли, разработки месторождений, техники и технологии, организации труда, комплексной автоматизации и телемеханизации объектов с региональной привязкой, известных личностях и др.

Приказом ОАО «Татнефть» от 20.15.1995г. написание энциклопедии было поручено нефтегазодобывающему управлению «Альметьевнефть». Учрежден Фонд «Альметьевская энциклопедия», изысканы финансовые и материальные средства. В составе управления «Альметьевнефть» организована специальная Творческая группа по сбору и подготовке материалов к изданию Альметьевской энциклопедии. Созданы приемлемые рабочие места.

Образована научно-редакционно-издательская коллегия, в составе представителей объединения «Татнефть» и администрации Альметьевского района и г.Альметьевска.

Первым нашим шагом в историческую неизвестность стало изучение организации работы института Татарской Энциклопедии АН РТ. В результате недельного ознакомленияс работой института у нас сложилось

мнение, что организация создания Татарской Энциклопедии и «Альметьевской энциклопедии» совпадают лишь целью и названиями. Дело в том, что Татарская Энциклопедия в основном создавалась на ужеопубликованных и научно апробированных материалах, то для создания «Альметьевской энциклопедии» материалы предстояло еще выявить, их извлекать, собрать, написать и научно апробировать. Для всего этого требовалось найти и привлечь к работе соответствующих исполнителей, обеспечить финансированием, работать в архивных организациях различных городов, написать статьи, обсудить их на конференциях и различных круглых столах, также довести до широкого круга читателей и т.д.

Так как Альметьевск является не университетским городом, а традиционно промышленным моногородом с ВУЗами технико-экономического характера, то для выполнения поставленной задачи мы были вынуждены привлечь иногородних ученых соответствующей квалификации республики. Установлены творческие связи, как с отдельными специалистами, так и целыми группами ученых, а также организаций. В составе Института истории АН РТ организован Казанский центр содействия Альметьевской энциклопедии, который выполнял повседневную координирующую работу среди казанских ученых. Творческие связи группы не ограничивались только с этим институтом, а были установлены и с другими научными учреждениями за пределами республики.

В зависимости от предстоящих задач состав творческой группы постоянно менялся. Специалисты, выполнившие свою часть работы, уходили, на их место приглашались другие. В общей сложности в работе над энциклопедией приняли участие около 350 чел., проживающие в городах Альметьевск, Казань, Бугульма, Лениногорск, Бавлы, Азнакаево, Набережные Челны, Москва, Уфа, Самара, Подольск. Из них около 85% были иногородними, в частности из Казани до 60% и Бугульмы около 15%. Было привлечено к работе 18 докторов и 68 кандидатов наук, что составляло около четверти коллектива группы. В сборе материалов для Альметьевской энциклопедии оказывали помощь краеведы, активисты, отдельные жители деревень и города. Естественно, организация работы в условиях разбросанности исполнителей, потребовало сравнительно избыточных затрат на связь и автотранспорт.

Была проведена довольно масштабная и комплексная подготовительная работа.

Создана методическая база Энциклопедии. Вместе с учеными подготовлена концепция Энциклопедии, одобренная руководством ОАО «Татнефть», Альметьевскнефть» и администрации района и города.

Составлен многостраничный Словник, который отражает общее содержание Энциклопедии и представляет собой полный перечень названий статей, которые в нее должны быть включенными.

Разработаны соответствующие методические материалы по составлению научных статей различной сложности и др. Проведена болезненно-щепетильная работа по включению личностей в Альметьевскую Энциклопедию.

При этом уместно будет отметить и то, что в общей деятельности творческой группы около 2-х лет потрачены на ее организацию.

Интенсивно велись архивные изыскания внутри и за пределами республики. Вот перечень городов, куда были командированы работники творческой группы для работы в различных архивах и библиотеках: Казань, Уфа, Оренбург, Самара, Екатеринбург, Москва, Санкт-Петербург, Ялутурово.

Здесь уместно привести несколько примеров, являющиеся знаковыми в кратковременной деятельности Творческой группы.

Выполнены обширные работы по археологическому обследованию региона: открыты древние культуры, изучены жилища и погребения, оставленные древним населением, установлено более 70-ти памятников культуры и т.д. Выполнены портретное изображение и бюст жителя эпохи бронзы, найденного при раскопках около реки Зай. Есть основание считать, что Альметьевский регион является наиболее археологический изученным на территории республики, а наши археологические находки позволяют нам заглянуть в глубину истории более чем в три тысячи лет.

Проведены археографические, эпиграфические, топонимические, фольклорные, искусствоведческие и др. экспедиции. На 160 кладбищах изучены надмогильные камни.

В процессе работы обнаружено множество ценных материалов, относящиеся к Альметьевскому краю. Некоторые из материалов уникальные, например, о Надыровской волости, на исторической территории которой стоит фактически весь Альметьевский район, не говоря уже о высокопродуктивных нефтяных месторождениях. Регион достаточно хорошо исследован в историческом плане, например, две пересекающие территорию р-на Закамские засечные лини с крепостями, повстанческое движение среди местного населения в 1735 и 1773–1774 гг. и др.

Можно с уверенностью сказать, что Альметьевский регион перспективен для въездного международного туризма.

Собран богатейший материал по самым разнообразным аспектам истории предприятий акционерного общества, учреждений и организа-

ций, нефтяных месторождений и площадей, технологических процессов и др.

Накоплены интереснейшие данные по биографиям известных личностей района и нефтяной промышленности, установлены новые имена. (Всего около 1600 имен).

В результате творческая группа в начале XXI столетия располагала большим комплексом материалов по истории образования и становления населенных пунктов, земледелия и промышленности, развития образования, здравоохранения, культуры и др.

Много уникальных материалов связано с традиционной культурой разных народов, живущих в Альметьевском районе.

Часть этих материалов носят эксклюзивный характер и впервые вводятся в научный оборот. Все они являются основой для статей Альметьевской энциклопедии.

С целью изучения края были организованы конференции, симпозиумы и др. (Приложение 1). Материалы конференций опубликованы в типографских изданиях и будут представлены в Альметьевской энциклопедии.

Так как в энциклопедию могут быть включены только те материалы, которые уже введены в научный оборот, т.е. опубликованы и прошли научную апробацию, было опубликовано около двух десятков различных изданий (Приложение 2). В них апробированы многие новые факты, исторические сюжеты и др.

На наш взгляд, Альметьевская Энциклопедия создавалась впервые, сведения о других подобных проектах в пространстве РТ и РФ нам пока не известны.

К середине 2002 г. Творческая группа завершила этапа сбора и подготовки материалов для Альметьевской энциклопедии. Приказом по НГДУ «Альметьевнефть» от 23.08.2002 г. на группу была возложена задача написания энциклопедических статей, в связи с чем стала именоваться «Творческая группа по созданию «Альметьевской Энциклопедии».

Издание «Альметьевской Энциклопедии» планировалось на двух государственных языках РТ – татарском и русском.

Структура и объем «Альметьевской Энциклопедии» и Энциклопедии нефтяной промышленности Республики Татарстан предполагались следующим образом.

Том 1. Природа Юго-Востока Республики Татарстан. 632 стр. Издан в 2006 г.

Том 2. История и культура Альметьевского региона. Всего в 3-х книгах. Кол-во статей – 2,1 тыс., объемом – 1,7 тыс.

Том 3. Энциклопедия Нефтяная промышленность Республики Татарстан.В 3-х книгах. Кол-во статей 1,3 тыс., кол-во стр. 3,0 тыс.

Том 4. Персоналии. В 2-х книгах.Кол-во биографических статей 5,7 тыс., кол-во стр. 1,0 тыс. В том «Персоналии» включаются жители Альметьевского р-на и нефтяники, независимо от места их проживания, т.к. в среде нефтяников много уроженцев этого р-на. Личности в том «Персоналии» включаются согласно разработанного критерия.

Каждый том Энциклопедии состоит из развернутых статей и «черных» слов. По ходу ревизии архивов, а также с возможно ожидаемыми новыми статьями кол-во статей и страниц могут быть изменены.

Весной 2005 г. работы по созданию «Альметьевской энциклопедии» на основе решения руководства объединения были приостановлены.

В 2017 г. руководством ПАО «Татнефть» работы по созданию «Альметьевской энциклопедии» возобновлены.

***

В период своего функционирования участниками Творческой группой приобретен достаточный опыт работы в архивах и в изучении собственно региона, который может быть использован в других районах республики.Вот некоторые из обязательных примеров в описании истории населенных пунктов.

Документально достоверная история населенных пунктов может быть написана лишь на базе архивных источников. Материалы хранятся в архивах различных городов и не бесплатно. Конкретно это касается получения копий ревизских и метрических материалов, спорных и земледельческих сведений и др., что обязательны в описании многовековой жизнедеятельности самих сельчан. Выявление и цифрокопирование архивных материалов этой тематики желательно централизовать за счет финансовых средств Республики и разместить их на сайте Института истории. Для перевода метрических материалов с арабицы на кириллицу было бы привлечь студентов Исламского университета, например, в качестве либо курсовых, либо экзаменационных, либо общественных работ. Эти материалы также могут быть сосредоточены на сайте Института истории.

В написании истории селений эти материалы составляют основу, т.к. история деревень – это есть история каждого хозяйства, каждой семьи. А ревизские и метрические материалы являются неотъемлемой частью не только в составлении документальных родословий сельчан, но и служат в качестве аналитических источников в оценке аграрной экономики населенного пункта в целом, продолжительности жизни сельчан с выделе-

нием их возрастных групп, брако-разводных дел, видов болезней, потери трудовых ресурсов в голодные годы и др.

Без документально достоверных родословий организовать в селах «шәҗәрә бәйрәмен» просто невозможно. Эти праздники объединяют сельчан, что установлено нами из множества подобных мероприятий. Это особо важно в наше, непростое, время.

История селений непременно требует кратографической поддержки. Этого вопроса также желательно решить централизованно. В нашем случае речь идет о Планах генерального межевания (ПГМ), губернских, уездных, районных, лесоводческих и топографических карт. Правда, часть перечисленных карт присутствует в интернете, но довольно низкого качества. Картографического материала также можно разместить на сайте Института истории.

Имеется настоятельная необходимость охвата археологическими изысканиями территории республики повсеместно. Это важно не только для установления культур прошлых тысячелетий, но и для топоопределения мест существования исчезнувших деревень и захоронений. Например, из числа известных 173 деревень Альметьевского региона на сегодня существуют лишь 100 селений. За последние 50–70 лет 73 деревни перестали существовать. Трагическая судьба постигла, в основном селения, основанные в периодыправления Столыпина и «большевизма» (1910–1920–1930-е гг.). Места расположения некоторых исчезнувших деревень нам не удалось установить, в т.ч. и места захоронений. Археологическая помощь могла бы наши проблемы решить.

Было бы желательно внести ряд изменений в деятельность всех без исключения архивных организаций республики: обеспечить ежедневный доступ краеведов к архивным материалам, оказать им поисковую помощь и бесплатную оцифровку необходимых материалов и др. Желательно организовать бесплатного получения картографических и иных архивных материаловпо линии межархивного обмена. Это значительно ускорило бы и удешевило поисковые работы. Желательно архивных работников приравнять краеведам с повышением зарплаты. Без совместно-заинтересованной работыархивистов и краеведов добиться эффективного конечного результата не стоитожидать.

Организация и проведение научно-практических конференций в каждом из районов республики обязательны и могут быть организованы собственными силами в пределах их компетенции. На востоке Республики таковые уже осуществляются и довольно полезны. При этом особо важными являются организация конференций при сельских школах, для

подрастающего поколения это станет связью прошлого с будущим. Подобные работы осуществляются, например, в школе села Сары Биккулово Лениногорского района.

Республиканскому телевидению, радио и журналистамтакже будут интересны исторические находки и новости. Наши деревни заслужили быть представлены в научной среде не только в Республике, но и за пределами страны.

Желательно продумать и на республиканском уровне решить вопросы морально-материальной поддержки краеведов, селений и активных руководителей районов, особо отличившихся в осуществлении рассматриваемой благородной задачи. Например, ввести в практику награждение именными и престижными дипломами республиканского масштаба. Установить звание «Заслуженный краевед Республики Татарстан». Почему бы нет?

В мире растет интерес к туризму. У нашей республики с богатейшей историей имеются реальные шансы привлечь потока иностранных и внутригосударственных туристов. Кто перехватит потока туризма, тот сумеет пополнить свой бюджет, прежде всего в инвалюте. Въездной туризм, в свою очередь, дает шансы районам и селам республики развивать малого и среднего бизнеса, занять сельчан не только монотонным сельским трудом, но и разнообразными формами деятельности в индустрии туризма.

***Приложение 1***

### *Конференции и симпозиумы*

23–25 ноября 1999 г., г. Альметьевск. Конференция «Альметьевский регион: проблемы историко-культурного наследия».

25–27 мая 2000 г., г. Альметьевск. Симпозиум «Проблемы изучения истории заселения и образования населенных пунктов Альметьевского региона».

05–09 декабря 2000 г., г. Альметьевск. Симпозиум «Проблемы изучения этнокультурных процессов Юго-Восточного Татарстана».

Апрель 2001 г., г. Казань. Симпозиум «О времени основания села Альметьево».

Осень 2001 г., г. Казань. Круглый стол «Об истории Ногайской Орды»

На конференциях и симпозиумах приняли участие руководители ОАО «Татнефть», НГДУ «Альметьевнефть», администрации города, известные ученые научных учреждений и учебных заведений гг. Альметьевска, Казани, Уфы, Москвы, Санкт-Петербурга, Самары, Оренбурга, Ижевска и Челябинска.

***Приложение 2***

***Список книг и журналов, изданные в рамках подготовки Альметьевской энциклопедии. (Тиражи 1 тыс.)***

Серия «Из истории Альметьевского региона»

1. Из истории Альметьевского региона. Вып. I. – Казань: Изд-во Татполиграф, 1999. – 350 с. (Два издания).

2. Е.П. Казаков, З.С. Рафикова. Очерки древней истории Восточного Закамья. Вып. II. – Казань: РИЦ «Дом печати», 1999. – 120 с.

3. А.Г. Галлямова, Р.Н. Гибадуллина. «Альметьевское дело». Трагические страницы из истории крестьянства Альметьевского района (конец 20-х – начало 30-х гг.). Сборник документов и материалов Вып. III. Казань, Изд-во «Гасыр», 1999. – 192 с.

4. М. Әхмәтҗанов. Дастаннарватаны. Кама аръягының көнчыгыш төбәкләре һәм татар әдәбиятетарихы. IV – че китап. – Казан: «Мәгариф», 1999. – 159 б.

5. М. Әхмәтҗанов. Үлгәннарнеңкаберен бел. Әлмәт төбәге эпиграфик истәлекләре. V – че китап. – Казан: «Мәгариф, 2000. – 159 б.

6. Альметьевский регион: проблемы историко-культурного наследия. Материалы научно-практической конференции. Альметьевск, 23 – 25 ноября 1999 г. Вып. VI. – Казань: Изд-во РИЦ «Дом печати», 1999. – 240 с. Посвящена к 70-летию Альметьевского района.

7. Проблемы изучения истории заселения и образования населенных пунктов Альметьевского региона. Материалы симпозиума. Альметьевск, 25 – 27 мая 2000 г. Вып. VII. Казань: РИЦ «Дом печати», 2000. – 208 с. Посвящена 280- летию села Альметьево.

8. Д.Б. Рамазанова. Татары Восточного Закамья: их распространение, особенности говора. Вып. VIII. – Казань: Изд-во«Магариф», 2001. – 207 с.

9. Ф.С. Баязитова. Әлмәттөбәгетатарлары. Рухимирас: көнкүрешһәмйолатерминологисе, фольклор текстлары. IX – чыкитап. Казан: «Мәгариф», 2001. – 320 б.

Серия «Из истории нефтяной промышленности»

10. Р.К. Уразманова Быт нефтяников-татар Юго-Востока Татарстана (1950–1960 гг.). Этносоциологическое исследование. Вьш. I. – Альметьевск, 2000. – 158 с.

11. Р.Х. Амирханов История нефтепромысла «Миннибаево». Нефтепромысел №2 треста «Бугульманефть», 1950–1952 гг. Вып. II. – Казань: Изд-во «Матбугатйорты», 2000. – 192 с.

12. К.А. Назипова Татарские нефтяники: начало большого пути. Вып. III. – Казань: Изд-во Магариф, 2004. – 152 с.

Журнал «Мирас», посвященный истории региона:

13. Мирас. №11, 2000 г.

14. Мирас. №11, 2001 г.

Другие издания:

15. М.Г.Госманов, Р.Ф.Мәрданов. «Шура» журналыныңбиблиографиккүрсәткече. – Казан: Милли китап, 2000. – 264 б. Посвящена литературно-газетной деятельности Р.Фахретдина.

16. Русско-татарский нефтепромысловый словарь. Более 27 000 слов. Русча-татарча нефть сәнәгатесүзлеге 27 000 нәнартыксүз. – Казан: Мәгариф, 2004. – 415 с.

17. Әлмәт Альметьевск. – Казань: Идел-Пресс, 2003. – 737 с. Посвящается 50-летию образования города Альметьевска.

18. Альметьевская Энциклопедия. Т.1. Природа Юго-востока Республики Татарстан. – Казань: Изд-во «Рухият», 2006. – 632 с., с илл., карты. Тираж 3 тыс.

## Мәктәптә төбәк тарихын куллану/ Применение краеведения в школах.

# ӘЛМӘТ ТӨБӘГЕНЕҢ ЯКТЫ МӘГЪРИФӘТ УЧАГЫ
## (Әлмәт шәһәре № 1 мәктәпнең 100 еллыгына багышлана)

***Б. Ә. Заһиров***

***Аннотация:*** *В начале XX века в деревне Альметьево (центр Альметьевской волости Бугульминского уезда) для религиозного обучения мальчиков существовали два медресе и один мектеб. Мударисом (заведующим) в медресе второго прихода мусульман с 1903 года стал Атласов Хади – известный просветитель, историк. Он как мугаллим (учитель) реформатор, учил детей в медресе по новому методу (Джадит), где давали детям светские науки: арифметику, географию, историю, рисование и т.д.*

*В 1918 году после Октябрьского переворота Совет народных комиссаров издал Декрет, запрещающий религиозное обучение в школах. В Альметьево, на оснавании этого декрета, начали учить детей демобилизованный красноармеец Миннехузин Миннегалим и Надыров Газизьян. В 1924 году директор Насыбуллин Касым организовал неполную среднюю школу (семилетку), а директор Ахмадиев Шарип в 1935 году открыл среднею школу.*

***Ключевые слова:*** *Деревня Альметьево, медресе и мектеб, мударис Атласов Хади, 1918 год, Декрет СНК об образовании, первые учителя школы Миннехузин Миннегалим и Надыров Газизьян, директор Насыбуллин Касым, директор Ахмадиев Шарип.*

## КЕРЕШ СҮЗ

Лингвистлар татар телен кыпчак-болгар сөйләме группасына кертәләр. Кытай хроникалары кыпчакларны динлиннар нәселеннән булуын Безнең эрага кадәр III гасырда ук язып калдырганнар икән. Аларның сәяси күтәрелеше куманнар, татарлар, монголлар белән бер чорда башланган (хуннар, сәнбиләр чоры артта калгач). Кайбер галимнәр болгар, чуваш, сары уйгурлар (Кытай провинциясе Гансу) һәм якут телләре борынгы телләр булган дип уйлыйлар. Бүген Скифларның теле турында бернәрсә дә әйтеп булмый, әмма аларның бер өлеше шулай ук төрки телдә сөйләшкәнн дип фаразлыйлар. Төрки телләрнең

бер үк тамырлары булуы аларның хуннардан (сннәрдән) чыгышлары белән аңлатып була. Безнең эрага кадәр 170 ел элек Хуннар Кытай белән сугышка 60 меңлек атлы гаскәр туплый алганнар, димәк халкы 300 меңнән дә ким булмаган дип уйларга кирәк, бу ул вакыт өчен бик зур сан. Бүгенге көндә күп тикшеренүчеләр хуннар төрки телдә сөйләшкәннәр дип тәкъдир итәләр, шулай ук аларның һинд язуына охшаган язулары булуын әйтәләр, әмма хәзергә берниниди язу үрнәкләре табылмаган. Татар телендә язу эзләре шулай итеп бик борынгы тарихка кереп югала [Амирханов: 2005 г.].

Телебез борынгы заманнардан ук камилләшә килеп, үзенә бүгенге көнгә күбесе югалган телләрдән дә кыйммәтле өстәмәләр алып югары үсешкә ирешкән. Алтын Урда чорында татар теле дөнья күләм аралашу теле булып саналган. Бүгенге көннәрдә татар теле һәръяклап югары үсеш алган төрки тел булып, ЮНЕСКО тарафыннан бөтен дөнья халыкара аралашу теле дип танылган 14 тел арасында).

## ПАТША ДӘҮЛӘТЕ ВАКЫТЫНДА АВЫЛДА МӘГЪРИФӘТ

Татар халкы гомер-гомергә аң-белемгә омтылып яшәгән. Китап элеккеге чорларда бик кыйммәт булганлыктан, аны барлык гаиләләр дә сатып ала алмаган, булганын бик кадерләп саклаганнар. Гаиләләрдә аларны кичләрен үзләре дә, күрше-тирә белән җыелып та укый торган булганнар.

Татарлар яшәгән төбәкләрдә элек-электән үк барлык авылларда да диярлек дини мәктәп, мәдрәсәләр эшләгән. Борынгы вакыттан ук XX гасыр башына кадәр «Кадимчә» укыту дәвам иткән, күп вакытны буш сүзләр сөйләп (схоластика) уздырганнар. Татар авылларында мәктәпләр, мәдрәсәләр гасырлар буенча халык акчасына яшәп килгәннәр. Нинди генә авырлыклар булмасын, татарлар үзләренең балаларына башлангыч белем булса да бирергә тырышкан.

Казан ханлыгы руслар тарафыннан алынгач, патша чиновниклары, поплар мөселман диненә, мәгърифәтенә каршы басымны көчәйтәләр. Казан өязендә 1742 елга барлыгы 536 мәчет һәм мәктәп булса, 1742 елдан мәчетләр, мәдрәсәләр яндырыла, җимерелә, яңаларын салу тыела. Шуңа карамастан, татар халкы бирешмәгән, үзенең мәдәниятен, мәгарифен саклап калган.

Русия эчке эшләр министрлыгы җыйган мәгълүматларга караганда, 1839 елда 111 мәдрәсә (мәктәпләр саны күрсәтелмәгән), аларда 16 мөхтәсиб, 52 мөдәррис, 426 имам булган. Синодның чит диннәрне тотучылар эше департаменты мәгълүматлары буенча, 1858 елда Казан губернасында 430, Оренбург губернасында 418 мәктәп һәм мәдрәсә булган. 1912 елда

Казан губернасында татар мәктәпләрендә 83 824 бала укыган [Амирханов: 2005 г.].

1876 елда Казанда Татар укытучылары мәктәбе ачыла һәм ул рус теле һәм арифметиканы башлангыч татар училищеларында укыту өчен укытучылар хәзерли башлый. Анда физика, табигый тарих, химия һ.б. фәннәрне өйрәнү бүлмәләре оештырыла. Аңа башлангыч рус училищесен тәмамлаган татар яшләре экзамен белән алына (10 укучы). Татар укытучылары хәзерләү мәктәбенең беренче инспекторы итеп 27 еллык укыту тәҗрибәсе булган Мөхәммәтгали Мәхмүтев билгеләнә.

Казан Татар укытучылары мәктәбен «отлично» га тәмамлаган Шакирҗан Таһиров шушы ук мәктәптә рәсем ясау, матур язу дәресләре укыта башлый. Шакирҗан Таһиров беренче буларак татар балалары өчен авазлар кулланып өйрәтү өчен Әлифба төзегән шәхес. Бу Әлифба 1893 елдан башлап 15 тапкыр бастырылып чыгарыла.

Милләт мәгърифәтен күтәрүгә зур хезмәт куйган, шөһрәт казанган күпкырлы галим Каюм Насыйри (1825–1902) гыйльми эшчәнлек белән мәдрәсәдә укыганда ук шөгыльләнә башлый. Ул татар, гарәп, фарсы, рус, төрек телләрен камил белгән, фәннәрнең төрле тармаклары белән кызыксынган. Аның математика, фәлсәфә, география, медицина, игенчелек һ.б фәннәр буенча язган китаплары берничә буын татар халкының уку-укыту әсбаплары булып торалар. Гарәп язуын татар теленә тулырак яраклаштыру кирәклеген беренчеләрдән булып Каюм Насыйри күтәреп чыга. Ул белем-тәрбия бирүдә милли халык тәҗрибәсен кулланып хезмәтләр яза, үзе исән вакытта гына да 40ка якын китабы басылып чыга.

Мөселманнарның мәгърифәтен яңача үзгәртеп коруга тормышын багышлаган тагын бер бөек галимебез Шиһабетдин Мәрҗәни хәзерге Әтнә районының Ябынчы авылында туган. Башлангыч белемне атасы ачкан һәм укыткан данлы «Ташкичү» мәдрәсәсендә алып, гыйлемен күтәрү өчен 11 ел буе Бохара, Сәмаркәнд уку йортларында тирәнтен төрки халыкларының философиясен, тарихын өйрәнә. Туган ягына кайткач Беренче мәхәллә мәчетенең имамы һәм баш мөдәрисе итеп билгеләнә, 1860 елда Казан шәһәренең ахуны һәм мөхтәсибе була.

Зур каршылыкларга дучар булуга карамастан ул 1871 елда мәхәллә акчасына яңа ысул белән укытучы мәдрәсә ачтыра, анда рус теле, тарих, астрономия фәннәре укытыла башлый һәм ул татарларга дөньяви фәннәр укытуның мөһимлеген күрсәтә.

Ш. Мәрҗәни татарларның килеп чыгышы турында фәнни эшләр башлап, 1877 елда Казанда узган IV-нче Бөтенроссия археологлар съездында Болгар, Казан тарихы буенча чыгыш ясый. 1885 елда татарлар тарихына багышланган, мирасханә мәгълүматларын, бик тә кыйммәтле

этнографик, археологик мәгълүматларны кулланып язылган «Мәстәфадел-әхбар фи әхфали Казан вә Болгар» китабының беренче томы басылып чыга. Аның гарәп телендә язылган 30-дан артык фәлсәфи һәм тарихка багышланган хезмәтләре билгеле, шулар арасында 6000-ләп Көчыгыш галимнәренең, язучыларының тәрҗемәи хәле турында хезмәте кызыклы.

Гарәп язуын, орфографиясен камилләштерүгә зур өлеш керткән галимнәр арасында Әхмәтһади Максудины (1867–1941) күрсәтеп узарга кирәк. Аның 1892 елда «Мөгаллимә әүвәл» әлифбасы чыга һәм ул утыздан артык басмада басыла (гомуми данәсе 1 млн. 200 мең чамасы). Бу әлифбаны үзбәкләр, казакълар, кыргызлар, Кырым татарлары да кулланганнар.

Тарихчылар төрки дөньяда милли буржуазия аңының күтәрелүен Кырым татарларыннан чыккан Исмәгыйль бәй Гаспралы (1851–1914) белән бәйләп күрсәтәләр. Патша офицеры гаиләсендә туган Исмәгыйь башта мәктәп тәмамлап, атасы ярдәме белән Мәскәү хәрби гимназиясендә укый башлый. Соңрак Стамбулда, Парижда булып, Европа һәм Төрек мәдәнияты белән тирәнтен таныша. Ул Парижда чагында француз мәгариф министрының башлангыч дөнъяви белем бирү программасы белән танышып хозурлана һәм бу аның соңрак үзе алып барган «ысулы җәдит» хәрәкәтенә нигез була. Исмәгыйль Бахчасарайда яңа ысул белән гыйлем бирү мәктәбе ачып, яңа мәктәпләр өчен укытучылар хәзерли.

Исмәгыйль Гаспралы китап басу эшләрен дә башлап җибәрә, аның кул астындагы басмаханәләрдә әдәби төрки телдә күп сандагы газеталар, журналлар, дәреслекләр һәм матур әдәбият басыла. Бу хезмәткә төрки-татар дөньясының зыялылары Фатих Кәрими, Сәедгәрәй Алкин, Йосыф Акчура, Һади Максуди, Рәшид Ибраһим, Муса Бигиев, Әлимәрдән Төпчебаш һ.б. тартылалар.

1914 елда Бөгелмә өязендә татар балалары 109 мәктәптә, 8 мәдрәсәдә белем алганнар, бу бөтен укыту йортларының 58 % тәшкил иткән. Беренче мәртәбә бер класслы рус-татар мәктәбе (училищесе) Бөгелмәдә 1909 елның 1-нче ноябрендә ачыла, аны сәүдәгәр Шакир Хәкимов ача. Бу уку йортында көннең беренче яртысында мөселман дине, гарәпчә язу бирелсә, төштән соң рус теле, арифметика, рус язуы белән шөгыльләнгәннәр.

Әлмәт, Бәйрәкә авылларында да ир һәм кыз балалар өчен шундый ук мәктәпләр 1912 елдан ачыла. Соңрак Бигәш, Яңа Кәшер авылларында да шундый мәктәпләр ачылып, Яңа Кәшер мәктәбендә туку һөнәренә дә өйрәтә башлыйлар. Рус класслары ачу чыгымнарының бер өлешен өяз земствосы капласа (1890 елда 1200 сум), калган өлешен мөселман җәмәгате түләгән (һәр укучы өчен 25 тиеннән 1 сумга кадәр). 1916 елга шун-

дый 14 рус-татар мәктәпләре оештырыла. Моңа кадәр дә Әлмәт авылы мәдрәсәсендә (1898 елдан) рус теле дә укытылган дигән мәгълүмат бар.

1913 елда Әлмәт авылында 4 класслы русча укытучы мәктәп ачыла, аның инспекторы Ильясов булган. Исмәгыйлов Галимҗан, Гарипов Нәкыйп, Каюмов Кәрәм (Шакир улы), Каюмов Фатых (Каюм улы) бу мәктәпнең беренче укучылары булалар. Вәләкин бу мәктәп озак яшәми, ябыла.

Әлмәт авылы мөселманнары XX гасыр башында өч мәхәлләгә бүленеп яшәгәннәр, өч мәчетләре һәм алар янында мәктәп, мәдрәсәләр булган. Беренче мәхәллә мәчете, зиратка якынрак урында, авыл аркылы агучы, хәзерге Нариман елгачыгының уң як яры буена урнашкан булган һәм мәдрәсәдә имам – мөдәрис Нәүширванов Нургали укыткан. Икенче мәхәллә мәчете базар мәйданы янында була (хәзерге вакытта «Иске Әлмәт» мәдәният йорты урнашкан). Анда күптәннән базар эшләп килгән, шулай ук, бу урында ярминкә уздыру Оренбург хәрби губернаторы әмере белән 1831 елдан башлана һәм ул икмәк сату-алу белән тирә-юньгә та-ныла. Бу мәхәлләнең мәдрәсәсе Зәй елгасы буендагы урамга урнашкан булган. Мәдрәсә яңача ысул кулланып укыту белән танылган, 1903–1909 елларда мәдрәсәнең мөдәрисе алдынгы карашлы мөгаллим, танылган тарихчы Һади Атласов була.

Әлмәт авылында мәгариф өлкәсендә зур хезмәт куйган алдынгы карашлы дин әһеле, мәгърифәтче, тарихчы Һади Атласов (1876–1938) турында язганда аның турында соңгы елларда чыккан мәгълүматны кулланабыз (М. Әхмәтҗанов «Дастаннар ватаны», 1999 ел; М. Госманов ред. «Бертуган Туйкиннар», 2007 ел).

Атласов Һади хәзерге Татарстанның Чүпрәле районы Иске Чәке авылында Мифтәхетдин мулла гаиләсендә туган. Башлангыч белемне әтисе мәктәбендә ала, атаклы Буа мәдрәсәсендә укуын дәвам итә. Атасы ярдәмендә үзлегеннән белем ала, рус, немец, гарәп, фарсы, төрек телләрен өйрәнә. Оренбургның Каргалы бистәсендә укытучылар хәзерләүче семинарияне тәмамлый. Буа мәдрәсәсенә кайтып укытту эшенә керешә, яңалыклар кертүгә күп көч куя. Аның «Гыйльме һәйәт» (астрономия), «Тарихы табигый» китаплары чыга.

1903 елда Һади Атласов Әлмәт авылы мәдрәсәсенә имам һәм мөдәрис итеп чакырылы. Түбән Чыршылының (Чәлшеле) авылыннан Габделфәттәх хәзрәт кызы белән гаилә коргач, Һадый үзләренең йортында, үзенең чыгымнарына кызлар мәктәбе оештыра. Үзе 15 кыз балага тарих, география укыта, ә җәмәгате Хөсникамал гарәп графикасын өйрәтә. Кәгазь, каләмгә кытлык булганлыктан такталарга акбур белән язып фәннәрне өйрәнәләр. 1916 елда патша хөкүмәте әһелләре бу мәктәпне ябалар.

1872–77 еллар арасында салынган өченче мәхәлләнең «Ак таш» мәчете авылның Көнбатыш кырында, Чистай шәһәренә баручы олы юл буенда булган һәм ул «Югары Оч» мәчете дип тә аталган (Совет власте чорында озак еллар китапханә вазифасын башкарган бина). Бу мәчетнең имамы һәм мәктәп мөдәрисе булып Яруллин Рәшит хезмәт итә. Мәчетнең икенче атамасы «Байлар мәчете», анда күбрәк байлар гыйбадәт кылган, бай балалары укыган, күрәсең.

## ХАЛЫК КОМИССАРЛАРЫ СОВЕТЫ МӘКТӘБЕНДӘ УКЫТА БАШЛАУ – 1918 ЕЛ

1918 елның 20 январендә РСФСР Халык Комиссарлары Советы (русча кыскартып СНК РСФСР) үзенең иң беренчеләрдән булган декретын (Югары Дәүләт органы карарын). игълан итә Бу декрет «Чиркәүнең дәүләттән һәм мәктәпнең чиркәүдән аерылуы» дип аталган. Декрет буенча барлык дәүләт, җәмәгать һәм хосусый укыту йортларында нинди дә булса дин белеме бирү тыела. Һәрбер РСФСР гражданына теләсә нинди дин тоту, яисә тотмау иреге саклана, ләкин дини оешмаларның юридик хокуклары юкка чыгарыла, чиркәү һәм башка барлык дини оешмаларның милке национализацияләнә (дәүләт карамагына күчерелә) һ.б.

Өяз вакытлы башкарма комитеты Бөгелмә шәһәрендә 1918 елда татар-башкорт мөгаллимнәре өчен Советча укыту-тәрбия курслары оештыра. Бу курсны оештыручы өяз мәгариф бүлеге җитәкчесе Һади Атласов (элеккеге Әлмәт авылы мәдрәсәсе мөдәрисе), ә әгъзаләре Нәдеров Газизҗан (Әлмәт авылы мөгаллиме), Зәйнуллин Сабир (Әлмәт авылы мөгаллиме), Даутов Фахразый (Миннебай авылыннан), Фазыл һәм Кәбир Туйкиннар һ.б. булалар. 1919 елдан Бөгелмә өяз Халык мәгарифе бүлеге мөдире вазифасын Бигәш авылыннан Рәфыйков Гариф башкара.

1918 елда Әлмәт волостендә, яңа хакимият – Волость башкарма комитеты сайлана һәм Халык мәгарифе бүлеге булдырыла (ВолОНО), аның җитәкчесе итеп Гыймаҗетдинов Зыя (Зыятдин) тәгаенләнүе мәгълүм. Зыятдин Гыймаҗетдин улы 1885 елда Әлмәт авылында ярлы җир эшкәртүче гаиләсендә туган, башлангыч белемне авыл мәдрәсәсендә алган, бик сәләтле бала буларак үзе дә мәдрәсәдә балалар укыта башлаган. Ул Казан шәһәрендә белемен күтәреп, Алабуга, Петербург шәһәрләренең татар мәктәпләрендә укыта, 1916 елдан Әлмәт авылында кызлар өчен яңача укыту мәктәбе оештыра («Дәрел-мөгаллимәт»). Гыймазетдинов Зыя 1918–1921 елларда Әлмәттә ВолОНО мөдире булып эшли.

1918 елда Әлмәт авылында Ватандашлар сугышында катнашып, яраланып кайткан кызылармияче Миңлехуҗин Миңлегалим һәм Нәдеров Газизҗан (Яңа Кәшердән) балалар укыта башлыйлар. Шулай итеп Әл-

мәт авылының «Югары Оч» мәхәллә мәктәбе (имам-мөдәрис Яруллин Рәшит мәктәбе) Халык мәгарифе комиссариатының татарча гомуми белем бирүче башлангыч сыйныф мәктәбенә әверелә. Мәктәп хәзерге Мәктәп (Школьная) һәм Совет урамнары чатында булган, соңрак бу урында «Раймаг» кибете корылган. Нәдеров Газизҗан башлангыч белемне туган авылы Яңа Кәшер мәдрәсәсендә ала. Урсалы авылының (бу вакытта волость үзәге) приходская школасында 3 ел укый, аннан соң белемен Акташта 3 еллык училищеда күтәрә. 1915–16 елларда Казан-Екатеринбург тимер юлы төзелешендә эшли, инкыйлабтан соң туган якка кайта, Әлмәт авылында балалар укыта башлый. Газизҗан 1919 елда Бөгелмә Өяз комитетына сайланып, ВКП(б) сафына керә, Бөгелмә Революцион комитетының Милләт эшләре бүлеге җитәкчесе итеп билгеләнә, Бөгелмә өязе авылларында ярлылар комитетлары оештыруда, мәктәпләр ачуда башлап йөри. Миңлехуҗин Миңлегалим турында мәгълүмат табылмады.

Алга таба, Совет укытучылары хәзерләү курсларында укып чыгып, мөгаллимнәр: Саттаров Газиз, Солтанов Кыям, Ханнанов Шаһгали, Хафизов Харис, Әшрәпов Котдус, Назаров ?, Хәтәмтаев Вәгыйзларның мәктәптә эшләгәнлеге мәгълүм.

1918 елда Габдрахман авылында да (Габдрахман волосте, соңрак Әлмәт волостенә карый) Совет мәктәбе ачыла. Аны авылга кайткан зыялы шәхесләр Таһиров Афзал, Нәбиуллин Миассар (Югары Мактамадан, Бөгелмә өязе Партия комитеты хезмәткәре) оештыралар. Мәктәптә Исламов Тәкый (тумышы белән Кодаш авылыннан) укыта башлый. Безнең төбәкне Колчак гаскәрләре басып алгач, алар Исламовны гаиләсе белән бергә кулга алалар, үзен Әлмәткә озаталар, анда аны кыйнап, язгы ташуда Зәй елгасына бәреп төшерәләр. Гәүдәсе ташу узгач, яр буендагы таллар арасында табыла, аны Әлмәт зиратына җирлиләр.

Яңа Кәшер авылында да (Урсала волосте, соңрак Әлмәт волостенә карый) 1918 елда зыялы нәселдән чыккан Нәдеров Хәббән (Нәдер Уразмәтев нәселе), Котлыбаева Хөмәйрә, Бөгелмә өяз мәгариф бүлеге юлламасы белән килгән Ныйгъмәтева Әминә (Бәркәтә авылыннан, имам-хатыйп һәм мөдәррис Таһир кызы) байлар йортларында балалар укыта башлаганнар.

Совет җөмһүрияте урнашуның беренче елларында 5 сыйныфлы мәктәпләр, икенче төрле 1-нче баскыч гомуми белем бирү мәктәпләре, ачылган булсалар да, Бөгелмә кантонында 2-нче баскыч гомуми белем бирү мәктәбе Бәйрәкә авылында гына була.

Бу елларда мәгарифнең никадәр начар хәлдә булуы, хәтта Әлмәт Волисполкомының 1925 елдагы Бөгелмә Кантонына юллаган отчетында да күренә, ул халык мәгарифе турында яхшы хәбәр бирә алмаган.

Отчетта язылганча, Әлмәт волостында беренче баскыч 11мәктәп ачылган, шулардан русча укытучы 1, татарча 8, мордвача 1, крәшенчә бер мәктәп эшли. Дәүләт хисабына 9, ә яшәүчеләр хисабына 2 мәктәп яши. Укытучылар саны барысы 18 һәм милләте буенча түбәндәгечә: 15 татар, 1 рус, 1 мордва,1 крәшен укытучылары. Мәктәпләр дәреслекләр белән бик начар тәэмин ителгән. Мәктәптә укучы балалар саны 1027, ә укымаучы балалар 2345 (шуларның кайберсе өйдә укырга өйрәнә).

Наданлыкны бетерү өчен оештырылган 3 мәктәптә (школа ликбеза) 1924–25 елларда 215 ир-ат, 35 хатын-кыз татарлар укыган. «Ликбез» мәктәбен узмаган кешеләр аз белемлеләргә (малограмотные) карыйлар.

## ҖИДЕЕЛЛЫК МӘКТӘП ОЕШТЫРУ – 1924 ЕЛ

Егерменче еллар ахырына авылларда крестьян яшьләр мәктәпләре (кыскартып КЯМ, русча ШКМ), ә шәһәрләрдә эшче яшьләр мәктәпләре (русча кыскартып ШРМ) барлыкка киләләр. Аларда укыту җиде ел дәвамында алып барыла. Авылда гомуми белем бирү белән бер рәттән бакчачылык, агрономия, умартачылык һ.б һөнәр нигезләрен бирәләр. Шәһәр мәктәпләрендә (ШРМ) югары сыйныф укучыларын укытучы, китапханәче, электромонтёр, хисапчы һ.б. белгечлекләренә өйрәтәләр. Кайбер шәһәрләрдә фабрика-завод һөнәр өйрәтү мәктәпләре (ФЗӨ) ачыла.

Бөгелмә кантонында 1924–25 укыту елларында тагын бер 7 сыйныфлы мәктәп ачу РСФСР Халык Комиссарлары Советының мәгарифне күтәрү бюджетына кертелә. Кантон башкарма комитетының Халык мәгарифе идарәсе (русча кыскартып – КУНО) бу мәктәпне Әлмәт авылында (волость үзәгендә) ачарга карар итә. Җидееллык мәктәпне оештыруны КУНО Насыйбуллин Касыймга йөкли һәм ул мәктәп мөдире итеп билгеләнә.

Баштагы елларда мәктәп иске мәдрәсәдә, байлардан калган төрле урындагы биналарда урнашкан була. 1924 елда Совет һәм 1-нче Май урамнары чатында (хәзерге Г. Баруди урамы) җидееллык мәктәп бинасы корыла башлый. Мәктәп бинасы 1924–25-нче уку елында төзелеп бетә, аның каршында бакча барлыкка килә. Бу зур, берничә бүлмәдән торган йорт Нагорное авылы сәүдәгәре Вороновныкы булган, аны сүтеп Әлмәт авылына күчерәләр. Мәктәп бинасы каршында базар мәйданы һәм икенче мәхәллә мәчете урнашкан булган.

Коммунальная урамында өч катлы яңа таш мәктәп салынгач бу бина читтән килеп укучы кызлар интернаты бинасы булып хезмәт итте.

1925 елда РСФСРда башлангыч дүртеллык мәҗбүри белем бирү турында закон кабул ителә. Бу чорда мәктәпләрдә укытучыларга кытлык

булганлыктан, сәләтле 7 сыйныф тәмамлаган үсмерләр, волость авылларында башлангыч сыйныф балаларын укытырга җибәреләләр.

Шушы елларда рәсемле әлифбалар да басыла башлый. Ләкин аларның яшь буын өчен әһәмияте инде югала,Татарстан Халык мәгариф комиссариаты латин алфавитына нигезләп, татар алфавиты төзеп, уку-язуга өйрәтү юнәлешен ала һәм ул 1929 елдан гамәлгә кертелә.

Мәктәп янында бюджет акчасына читтән килеп укучылар өчен интернат оештырыла, аның янында ашханә булдырыла, һәр укучыга 75әр сум стипендия түләү карала. Мәктәпкә Мәгариф комиссариаты тарафыннан Ленинград, Мәскәү шәһәрләреннән күргәзмә әсбаплар кайтарылып, физика, химия бүлмәләре, укытучылар һәм укучылар өчен махсус аерым китапханәләр оештырыла.

Укуны хезмәт белән бәйләп алып бару игътибар үзәгендә була, моның өчен мәктәп янында столярлык мастерское ачыла. Анда Әлмәтнең танылган агач эшләре остасы (столяр) Сәитов Садыйк дәресләр алып бара. Мастерскойда укучылар көче белән күп санда парталар һәм башка кирәк-ярак ясап чыгарыла.

Мәктәп Бөгелмә кантоны җирлегендә иң көчле мәктәпләр дәрәҗәсенә күтәрелә. Мәктәпкә Әлмәт волостеннан гына түгел, бәлки тирә-як төбәкләрдән дә килеп укыйлар. Башка милләт балалары арасында да уку теләге зур булганга күрә, русча укыту класслары да ачыла. Әлмәт мәктәбе Бөгелмә кантоны волостьлары өчен үрнәк мәктәпкә әверелә, шуның өчен ул Әлмәт терәк мәктәбе атамасы белән йөртелә.

## ӘЛМӘТ РАЙОНЫ ОЕШУ ҺӘМ СОВЕТ МӘГӘРИФЕ ӨЛКӘСЕНДӘ ЯҢАЛЫКЛАР

1930 елда ТатЦИК карары белән республикада административ-территориаль үзгәрешләр кертелә – республика районнарга бүленә. Шул елның август аенда яңа чикләр белән Әлмәт районы оештырыла (район үзәге Әлмәт авылы). Аның карамагына 25 авыл Советы керә; халкы 40957 кеше, шулардан татарлар 33736 кеше (82,4 %).

1929–30 елларда Халык мәгарифе өлкәсендә дә җитди үзгәрешләр була: татар мәктәпләре гарәп имласыннан латин алфавитына (Яңалифкә) күчереләләләр. Бу елларда татар мәктәпләрендә белем бирү нык кыенлаша. 1930–31 уку елыннан авыл җирләрендә дүртеллык, ә шәһәр һәм эшче поселокларында җидееллык гомуми мәҗбүри белем бирү карала.

1932 елда Әлмәт район Советы башкарма комитеты каршында Мәгариф бүлеге (русча Районный отдел народного образования, кыскача РОНО) оештырыла. Аның җитәкчесе итеп, моңа кадәр Әлмәт районы Партия комитеты сәркатибе (1930–31 елларда) вазифасын үтәгән Әхмә-

диев Шәриф билгеләнә. Алдагы елларда Мәгариф бүлеге белән Кәримов Сәлах, Вәлиев Габдулла, Шагалиев Габдерахман, Габдуллин Нигъмәт, Кәримов Самат, Фатыйхов Зәйни, Мөһетдинова Хәдичә, Кәримов Әбүзәр идарә итәләр.

Бу чорда авыл мәктәпләре Крестьян яшьләре мәктәбе (кыскартып КЯМ, русча ШКМ) атамасы белән йөртелсә, шәһәрләрдә Эшче яшьләр мәктәбе (русча кыскартып ШРМ) аталалар. Соңрак җидееллык мәктәпләрне Тулы булмаган урта мәктәп дип атый башлаганнар (кыскартып ТБУМ, ә русча НСШ).

Әлмәт авылы мәктәбе дә 1931 елның язында Крестьян яшьләре мәктәбе аталып, аңа 5 гектар «Тәҗрибә җире» бүлеп бирелә. Бу җирдә укытучылар Латыйпов Харрас, Ильясов (?) җитәкчелегендә башаклы, кузаклы усемлекләр, тамыразыклар карап үстерәләр. Җирне ашларга көл, тирес кулланып зур уңыш җыеп алалар. Җыелган уңыш интернатта торып укучыларга ашамлыклар хәзерләү өчен файдаланыла.

Башлангыч мәктәпләр мәҗбүри укытуга күчү сәбәпле, укучыларның яше төрлечә була, чөнки укымыйча калган яшьләр укуга тартылалар.

Әлмәт авылы ТБУМында да сыйныф бүлмәләрендә укучылар саны 40 тан да ким булмый, укыту бүлмәләре җитешми. Дәресләр ике алмашта (сменада) алып барыла. Хәзерге Баруди урамындагы элеккеге мәчет бинасында өч төркем укучылар укый. Кулакка чыгарылган Хөсәен байның алты почмаклы йорты мәктәп бинасына әверелә. Тирә-яктагы Бигәш, Колшәрип авылларыннан кулакка чыгарылган хуҗалыклар йортларын күчереп тагын 4 бүлмәле бина корыла. Мәктәп ишек алдындагы элеккеге рус баеның кибете пионерлар клубы итеп файдаланыла, ә сугыш чорында бу бина балаларга ашханә хезмәтен үти.

Зәй елгасы буендагы «Металлопром» артеле бинасы (элеккеге икенче мәхәллә мәдрәсәсе бинасы) мәктәпнең мастерское итеп үзгәртелә. Аның янындагы агач бина «Русская школа» атамасын йөртә, чөнки анда ике рус класслары урнаша. Соңрак бу бина яшь укытучылар өчен вакытлыча квартира итеп бирелә, аларның күбесе берәр еллык укытучылар курсын тәмамлаган укытучылар булалар.

1930–35 елларда мәктәптә Баязитова Мәбрүрә, Гатина Хәлимә, Дәүләтбаева Хәдичә, Зәйнуллин Сабир, Мөлекова Саҗидә, Нәдерова Хәтимә, Насыйбуллин Сәмикъ, Рамазанов Шәһит, Садыйков Әхәт, Сафина Мөхтәрәмә, Хәтәмтаев Вәгыйз, Шакирова Разыя кебек тәҗрибәле укытучылар укыталар. Әлмәт мәктәбендә химия-биология фәннәрен Казан авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлаган Латыйпов Харрас Харис улы укыта башлый. 1929–06.1932 еллар арасында мәктәп мөдире булып, элек бу мәктәптә укыткан Хәтәмтаев Вәгыйз Хәтәмтай улы эшли. 1932–

1933 елларда мәктәп мөдир вазифасын үтәүчеләр: Мөхәмәтҗанов Әбүбәкер, ә 1934 елда Гөбәев Шәех Ш. булалар (6 ел укыту тәҗрибәсе булган). 1934 елда үзе укыган мәктәпкә эшкә Вәлиев Гаяз Камал улы кайта, аны укыту-тәрбия эшләрен оештыру буенча мөдир урынбасары (завуч) итеп билгелиләр (7 ел укыту тәҗрибәсе булган).

## ӘЛМӘТ АВЫЛЫНДА ГОМУМИ УРТА БЕЛЕМ БИРҮЧЕ МӘКТӘП ОЕШТЫРУ – 1935 ЕЛ

1935/36-нчы уку елында Әлмәт җидееллык мәктәбе, гомуми урта белем бирү мәктәбе итеп үзгәртелә һәм төрле елларда 7 сыйныфны тәмамлаган укучылардан беренче 8 нче сыйныф укучылары туплана. Бу чорда мәктәп мөдире булып Әхмәдиев Шәрип (Шәрифҗан) эшли. Ул 1932–33 елларда Әлмәт район башкарма комитеттында мәгариф бүлеге (РОНО) җитәкчесе булып эшләгән.

Шушы вакытта Коммунальная урамында таштан беркатлы мәктәп бинасы да төзелә, әмма бу бина 1952 елда янгын чыгып янган һәм җимерелгән.

1936–38 елларда ТАССР «Наркомпросы» тарафыннан район мәктәпләрендә ныклы тикшерүләр уздырыла, укытучыларга аттестация үткәрелә. Район мәктәпләре арасында Әлмәт урта мәктәбенең торышы югары бәяләнә һәм 1937 елдан «Наркомпрос» приказы буенча Максим Горький исемендәге Үрнәк терәк мәктәп (опорно-показательный) атала башлый. Бу уңайдан мәктәпнең укыту-тәрбия эшләрен көйләүгә бераз финанслар бүлеп бирелә һәм укытучыларның айлык хезмәт хакы 25 % арттырыла. Бу әлбәттә мәктәп коллективы алдына зур бурычлар да куя. Шушы статуска бәйле буларак, мәктәп каршында Бөгелмә укытучылар институтының консультация бүлеге ачыла, атна саен студентларга дәресләр уздырыла. Кышкы һәм язгы каникуллар вакытында методик чаралар (күргәзмәләр) оештырыла. Бу җаваплы эшләрне үткәрү өчен әлбәттә югары белемле укытучылар кирәк була. Наркомпрос ярдәме белән, институт тәмамлаучылар белән килешеп, аларны мәктәпкә кайтару мөмкинлеге туа. Шулай итеп яхшы яшь белгечләре, тырыш, дус хезмәткәрләре булган мәктәп коллективы оеша.

Шушы чорда мәктәпкә эшләгән укытучылар: Баязитова Мәбрүрә (башлангыч сыйныф), Вәлиев Гаяз (математика, физика), Вәлиева Рәйсә (баш. с-ф), Гатина Хәлимә (баш. с-ф), Гыймазетдинов Зыя (татар теле), Дәүләтбаева Хәдичә (баш. с-ф), Зәйнуллин Сабир (баш. с-ф), Исхаков Мирсал (рус теле), Йосыпова Мөгаллиә (татар теле), Латыйпов Харрас (химия, биология), Мөлекова Сәҗидә (татар теле), Мөхәмәтдинова Рокыя (математика), Нигмәтуллина Габидә (баш. с-ф), Насыйбуллин Сәмикъ

(баш. с-ф), Сарбулатов Габдулла (тарих), Сафина Мөхтәрәмә (баш. с-ф), Федоров Михаил (татар теле), Харисова Шәмсия (баш. с-ф), Хәбибуллина Разыя (биология), Хәлфин Сәгыйть (тарих), Хәбибуллин Габдерахман (география), Шакирова Разыя (баш. с-ф), Әхметов Гәрәй (математика) һ.б.

1938–1939 еллар татар мәгарифе өчен бик тә катлаулы була: 1938 елда ВКП(б) Үзәк комитетының һәм Совет Халык Комиссариатының (Совнарком) «Рус телен милли республика һәм өлкә мәктәпләрендә мәҗбүри өйрәнүне тормышка ашыру» карары чыга, 1939 елда Татарстан ВКП(б) өлкә комитеты «Татар алфавитын латин графикасыннан рус графигы нигезендә төзелгән алфавитка күчерү» дигән карар чыгара.

Наркомпрос һәм башка органнарның тикшерүе сәбәп булгандыр, директор Әхмәдиев Шәрип эшеннән алына һәм Кәләй мәктәбенә география укытучысы итеп билгеләнә. 1938 елда Әхмәдиев Шәрипне кулга алалар, әмма гаепләрен тапмагач чыгаралар.

1938-нче елда Әлмәт татар урта мәктәбендә беренче чыгарылыш була. 12 укучыга урта белем алу турында аттестат тапшырыла. Аларның исемнәре, әлбәттә, мәктәп тарихы бүлмәсендә (музейда) сакланган.

1938 елда авыл мәктәпләрендә укытучылар җитмәүне искә алып, «Татнаркомпрос» күрсәтмәсе буенча соңгы уку елы ахырында 10-нчы сыйныфны тәмамлаучы укучыларга педагогика буенча дәресләр бирелә һәм алар башлангыч сыйныф укытучысы таныклыгы алып чыгалар. Бу чыгарылыш укучылары барысы да комсомол оешмасы әгъзалары булып, тырышып укыйлар, тыңлаучан, күндәм булалар, җәмәгать эшләрендә теләп катнашалар. Укучылар арасында Акбәрова Рәшидә, Әхмәтҗанова Хәтимә, Гыйльманова Рәхимә, Заһирова Рокыя, Сәйфуллина Әминә, Сәлимов Мәсәлим, Әхмәдиева Чәчкә (икенче чыгарылыш) аерата тырышлык күрсәтәләр һәм алар хезмәт юллары итеп укытучы һөнәрен сайлап, гомер буе шул юлдан баралар. Бу чорда мәктәп мөдирләре: Харисов Фәйзи – 1937–39 елның беренче яртысында, Кәримов Сәлахетдин – 1939–40 елның беренче яртысында, Исхаков Гали – 1940–41 елның беренче яртысында эшлиләр.

## ДӘҺШӘТЛЕ СУГЫШ ЕЛЛАРЫНДА МӘКТӘП

Әлмәт урта мәктәбе үзенең 4-нче чыгарылышын бәйрәм итә, мәктәпне тәмамлаучыларга аттестатлар тапшырыла. Гаять матур кояшлы, тыныч якшәмбе көне. Зәй елгасы буендагы болынлыкта Әлмәт район Җыены – «Сабантуе» уздырыла. Якын-тирә авыллардан кыңгыраулы атларда, машиналарга төялеп, бәйрәмчә киенгән кешеләр агыла. Болын җыр, бию, гармун тавышы белән гөрләп тора. Менә зур бәйрәм башланырга тиеш.

Шул вакытта ачык «ГАЗ»ик машинасына утырып Әлмәт район Партия комитетынан мәйданга киләләр, араларыннан берсе мәйдан уртасына чыгып, җыелган халыкка Гитлер Германиясенең 1941 елның 22 июнендә Советлар иленә каршы сугыш башлавын белдерә. Мәйдан тынып кала. Бәйрәм шатлыгы урынына кешеләр кайгы «төяп» кайтыр юлга юнәләләр.

Ир-атларны, мәктәп тәмамлаган егетләрне фронтка озату башлана. Аттестат алып хезмәт юлына, яисә институка юл тоту турында ниятләнгән егетләр сугыш кырына озатылалар. Ир-ат укытучыларны да сугышка алалар. Мәктәп тормышында зур кыенлыклар туа башлый.

Мәскәү, Харьков һәм башка җирләрдән эвакуациләнүчеләр килеп тула, алар арасында мәктәп яшендәге балаларда күп була. Шунлыктан русча укыту класслары ачыла. Мәктәптә 1941 елдан 1951 елга чаклы белем бирү татар һәм рус телләрендә аерым сыйныфларда алып барыла.

1944 ел башында Әлмәт районында 6419 хәрби хезмәткәрләр гаиләләре (22519 кеше) яшәгәнлеге билгеле, шуның өстенә 1320 эвакуацияләнгән гражданнар килгән (З. И. Гильманов. Татарская АССР в Великой Отечественной войне. Казань, 1977, стр. 78).

Фронтка киткән укытучыларны эвакуация белән килгән Л. А. Биксина (математика), И. У. Будовниц (тарих), О. Короф (химия-биология), И. П. Кульжинский (математика), В. Я. Кульжинская (чит тел), В. А. Розова (чит тел), яңа гына мәктәпне тәмамлаган С .Г. Бәкерова, Б. Х. Нәдерова, С. И. Зәйнуллина, А. Ф. Барашова һ.б. алыштыралар.

Дәреслекләр юк диярлек, дәфтәрләр аз, укучылар иске китап, газеталарга язып (язылмаган юлларга) укыйлар. Язу өчен караны суган кабыгы, имән агачы кайрысын кайнатып, аңа тимер салып тутыктырып ясыйлар. Укучыларның киемнәре кырык ямаулы бишмәт, аякларында чабата. Ашау-эчү ягы бик кыен ягулык юк. Ягулык һәм керосин җитмәү сәбәпле, Коммунальный урамындагы бер катлы таш мәктәпне ябып, мәчет бинасында 2 алмаш ясап (смена), ә элек ашханә итеп кулланылган бинага тимер мич куеп, югары классларны шунда укытырга туры килә. Керосин, шәмнәр булмаганда дәресләр бөтенләй өзелә. Бу чорда хатын-кыз укытучылар үзләре утын кисеп, ярып, пичләрне ягып уку бүлмәләрен җылытканнар. Мәктәпне дә уку елына үзләре хәзерләгәннәр, колхоз кырында да, фермада да эшләгәннәр. Керосин булмау сәбәпле укытучылар бергә җыелып төнлә мәктәптә дәрес бирергә хәзерләнгәннәр, укучыларның дәфтәрләрен тикшергәннәр.

СССР Мәгариф халык комиссариаты, урта мәктәпләрдә югары белемле укытучылар бик нык азайганлыктан, 1943 елда декабрь аенда «Читтән торып педагогик белем алуны ныгыту» турында карар кабул итә. Укы-

тучылар җилкәсенә шушы авыр чорда үзләренең белемнәрен күтәрү йөге дә төшә.

Сугыш вакытында колхозларның күрсәткечләре бик нык түбәнәя, эшләргә кеше калмый, атлар азая, яхшылары фронтка озатыла, иң авыр эшләр дә хатын-кыз, бала-чага, картлар көче белән башкарыла. Укудан соң балалар икмәк җыю, суктыру, җилгәрү, печән, салам җыю кебек эшләрдә катнашалар. Колхозчыларга эшләгән өчен бернәрсә дә бирелми. Укытучы гаиләләренә кайбер чакта айга берничә килограмм кибәкле он биргәләгәннәр.

Иң авыры – укучы балаларның аталары, туганнары үлү хәбәре килү була. Укытучылар моңсу карашлы, ач-ялангач балаларга бернигә карамыйча белем бирүне дәвам итәләр. Шундый авыр шартларда да балаларның күпчелеге тырышып укыйлар, үзләрен тәртипле тоталар. Укытучылар авыр хәлдә калган балаларга «Всеобуч» фонды оештырып өс-баш киемнәре (оекбаш, чабата, яулык, бүрек һ.б.) белән булышырга тырышалар.

Дәһшәтле сугыш чорында, 1941 елдан 1942 елның декабрь аена чаклы Шәйдуллин Гариф, ә 1942 декабрь аеннан, сугыш кырыннан каты яраланып кайткан, орден, медальләргә лаек булган Таһиров Мирза мәктәпне җитәклиләр.

Мәктәптә укыткан ир-атларның барысыда диярлек (14 кеше) сугыш кырында булалар, шуларның 6 генә төрле яралар алып әйләнеп кайта. 1938–41 елларда Әлмәт урта мәктәбен тәмамлаган күп укучылар – егетләр һәм кызлар да яу кырында һәлак булганнар. Мәктәп музеенда сугыш кырында һаләк булган мәктәп укытучыларының, 25 мәктәпне тәмамлаган укучының исемлеге, фотосүрәтләре бар.

Бу сугыш афәтенең барлык авырлыкларын үз җилкәләренә күтәргән укытучылар: Баязитова Мәбрүрә, Вәлиева Рәйсә, Вәлиева Камал, Гатина Хәлимә, Дәүләтбаева Хәдичә, Йосыпова Мөгаллимә, Латыйпов Харрас, Таһирова Рокыя, Шакирова Разыя, Әхмәтҗанова Хәтимә исемнәре мәктәп тарихында онылмас булып калдылар.

Сугыш чорында фидакарь хезмәт күрсәткән укытучыларның, шулай ук, исемлеге төзелгән һәм мәктәп музеена куелган.

## МӘКТӘП СУГЫШТАН СОҢ ЕЛЛАРДА

Сугыш тәмаланганнан соң, 1949 елдан авыл җирләрендә дә мәҗбүри җидееллык белем бирү кертелә. Күп башлангыч мәктәпләр җидееллык итеп үзгәртеп корылалар. СССР Югары Советы президиумының 1940 елның сентябрь аеннан кертелгән указы буенча ата-аналар балалары 8–10 класларда укыган өчен елына 150 сум түләргә тиеш булганнар. Карар су-

гыш чорында да һаманда үз көчендә калган. Бу хурлыклы карар 1950 еллар уртасында гына, Н. С. Хрущёв вакытында юкка чыгарыла.

1952 елны мәктәпнең Коммунальная урамындагы төп таш бинасы янгын чыгып җимерелгәч, укыту вакытлыча нефтьчеләр өчен төзелгән, такталардан корылган бинада (Мәктәп урамындагы, барак тибындагы бинада) алып барыла. Таш бинаны пичләр белән утын ягып җылыткан-нар, янгын чыгу сәбәбе ут белән саксыз файдалану аркасында булгандыр. 1954–56 елларда мәктәпнең төп укыту бинасы урнашкан урын Первомайская 38-нче йортта күрсәтелгән.

Әлмәт авылы төбәгендә нефть чыгару сәнәгатенең тиз үсеш алуы сәбәпле авылның да иҗтимагый халәте дә нык үзгәрә. СССР төрле почмакларыннан эшчеләр, хезмәткарьләр күченеп киләләр. Әлмәттә нефть чыгару белән бәйле оешмалар корыла, күп катлы йортлар төзелә, яңа мәктәпләр ачыла. 1953 елдан Әлмәт авылы нефтьчеләр шәһәре дип атала башлый. Мәктәптә 1951 елдан русча укыту класслары ябылып, яңадан татар телендә белем бирә башлыйлар һәм ул «Әлмәт шәһәренең № 1 гомуми белем бирүче татар урта мәктәбе» дип йөртелә башлый.

1950 елның сентябрь аеннан 1955 елның сентябренә кадәр мәктәп мөдире булып Раскулов Газыйм Хәбибрахман улы эшли. Ул Ватан сугышында катнашкан. Фронтта укчы полк командиры, укчы-миномет взводы командиры була, «Батырлык өчен», «Ватан сугышында Германияне җиңү өчен» медальләре белән бүләкләнгән. Гвардия лейтенанты званиесендә «запаска» озатыла.

1955 елның сентябрь аеннан 1970 елга чаклы өзлексез мәктәп белән яңадан Таһиров Мирза Каюм улы җитәкчелек итә. 1957 елга 3 катлы яңа мәктәп бинасы төзелеп бетә. Аның диварлары Коммунальная (хәзерге Мирза Таһиров урамында) ак таштан күтәрелә. Бу бина хәзерге вакытта да үз вазифасын башкара. Әлмәт шәһәренең беренче йортлары да шушы Чупай авылы янындагы таудан чыгарылган ак таштан төзеләләр, шуның өчен халык аны «Чупай ташы» дип атый да.

1958 елда СССРның Югары Советы Халык мәгарифен үзгәртеп кору турында закон кабул итә, үзгәртүнең төп нигезе итеп укытуны җитештерү хезмәте белән бәйләп алып бару бурычы куела. 1960–61 уку елында җидееллык мәктәпләр күбесе сигезьеллык, ә барлык урта мәктәпләр унберьеллык итеп үзгәртеләләр, мәктәпләрдә гомуми урта белем бирү белән бер рәттән төрле һөнәрләргә өйрәтүгә юнәлеш бирелә. Шул җәһәттән Әлмәтнең 1-нче урта мәктәбендә дә төрле эшче һөнәрләренә өйрәтү кертелә. 8-нче сыйныфтан тимер эшкәртү станокларында эшләргә өйрәтсәләр, 9-нчы сыйныфтан 11-нче сыйныфка кадәр аерым программалар белән ир балаларны йөк машинасын йөртүче, электр җиһазларын

көйләүче һөнәренә, ә кыз балаларны пешекче, тегүче, шәфкать туташы һөнәренә өйрәтү башлана. «Әлмәт шәһәренең № 1-нче унбереллык эшче һөнәрләренә өйрәтүче политехник мәктәбе» – дип аталып, мәктәпне тәмамлаучыларга гомуми урта белем алу таныклыгы белән беррәттән эшче һөнәре таныклыгы да бирелә. Бу елларда төрле татар авылларыннан җыйналган балаларга, Әлмәт районында гына түгел, ә Татарстанда «Таһиров мәктәбе» исеме белән танылган тирән белем бирү һәм һөнәргә өйрәтүче мәктәпләрнең берсе була. Сугыш чорыннан ук мәктәп мөдире вазифасын башкарган Таһиров Мирза Каюм улының мәгариф өлкәсендәге хезмәтләре югары бәяләнә, ул Ленин орденына лаек була, аңа РСФСРның атказанган укытучысы исеме бирелә.

1970 елдан 1985 чаклы мәктәп белән Каюмов Фатыйх Каюм улы җитәкчелек итә. Ул шулай ук Бөек Ватан сугышында катнашып, орден-медальләргә лаек булган укытучы, сугыштан соңгы чорда Республиканың Партия һәм Совет оешмаларында җаваплы урыннарда эшләгән. 1965 елдан Әлмәт шәһәренең № 3 нче урта мәктәбенә мөдир итеп билгеләнә, ә 1970 елдан № 1 урта мәктәп мөдире вазифасын башкара. Фатыйх Каюм улы тыныч тормыш вакытындагы хезмәтләре өчен дә орден һәм медальләргә лаек була, аңа РСФСРның атказанган мәктәп укытучысы исеме бирелә.

Бу елларда Советлар Союзында уйлап чыгарылган «интернационализация» шаукымы күтәрелә һәм Татарстан шәһәрләрендә, эшче посёлокларында мәктәпләр тулаем русча укытуга күчәләр. Әлмәт шәһәренең ярты гасырдан артык татарча белем биргән № 1-нче мәктәбе дә 1970 елдан русча белем бирүгә күчерелә.

1978 елда 1-нче мәктәптә Республика педагогларының «Мәктәпләрдә рус һәм татар телләрен укыту» программасы буенча конференциясе уза, анда башка регионнан килгән рус, татар теле укытучыларыда катнаша. Әлмәт мәктәбендә бу юнәлештәге эшләр югары бәяләнеп, берничә укытучы «Халык мәгарифе отличнигы» исеменә лаек булалар.

1980 еллар уртасында балаларга ана теленә хөрмәт, милли горурлык, патриотик тәрбия бирүнең әһәмияте күтәрелә башлый. Шушы юнәлештә, мәктәптә Ватан сугышында әсирлеккә төшсә дә сынмаган, дошманга баш иймәгән балалар язучысы Габдулла Алишев (Габдулла Алиш) тормышына багышланган истәлек бүлмәсе оештырыла. Бу эшләрдә башлап йөрүче һәм аны оетыруга күп көч куючылар татар теле, әдәбияты укытучысы Нәсимә Миңнеханова, математика, тарих укытучысы Сөембикә Бәкерова булалар. Соңрак бу эш киңрәк колач алып, укытучы Нәсимә Миңнеханова тырышлыгы белән мәктәп тарихына багышланган, бай истәлекләр тупланган музей булдырыла.

1985–2010 елларда мәктәпне Хуҗин Әлфис Хөсәен улы җитәкли. Ул шушы мәктәпне тәмамлап, белемен Әлмәт физик культура техникумында күтәрә һәм 1969 елда физик культура тәрбиясе бирү буенча үзе укыган мәктәпкә эшлкә килә. Тырыш, таләпчән һәм төрле чараларны оста оештыручы укытучыны хезмәттәшләре 1985 елда директор вазифасын башкарырга тәкъдим итәләр. Әлфис Хөсәен эшләгән чорда, 1991 елдан мәктәптә яңадан татарча укыту башлана, аңа мәктәп-гимназия статусы бирелә. Беренче мәртәбә гимназия сыйныфлары ачыла, анда яңа укыту программасы буенча төрле яңа фәннәр укытыла башлый: диннәр тарихы, гарәп графикасы, ритмика, сәнгать, шахмат уйнау һәм логика. Шулай ук инглиз телен башлангыч сыйныфтан ук тирәнтен өйрәнү максаты куела. Мәктәп-гимназия укытучылары шәһәр, район, республика күләмендәге семинарлар үткәреп, аларның хезмәтләре югары күрсәткечләргә ия булалар. 1994 елда мәктәп каршында татар музыка мәктәбенең филиалы ачыла, соңрак 2002 елда «Татех» АҖ ярдәме белән мәктәпнең төп бинасы янына аерым күп катлы яңа бина төзелә, анда спорт залы, музыка мәктәбе урнаша. Хуҗин Әлфис Хөсәен улы 25 ел буе зур тырышлык белән мәгариф өлкәсендәге яңалыкларны кулланып мәктәпнең дәрәҗәсен югары тота, аңа Татарстан Республикасының атказанган укытучысы исеме бирелә.

Данлы бай тарихы булган 1-нче Әлмәт татар урта мәктәбенең Халык мәгарифе комиссариаты тарафыннан нигезләнүгә 80 ел тулу (1998 елда) һәм 90 ел тулу уңаеннан (2008 елда) бәйрәм чаралары үткәрелде. Бу бәйрәмнәрдә төрле елларда белем алган сыйныфташлар, сабакташлар, чал чәчле укытучылар белән очрашып, аралашып, гөрләшеп истәлекләр яңарттылар. Илгә, Республикага, шәһәр-авылларга нинди һөнәр ияләрен генә тәрбияләп бирмәгән бу белем йорты?! Алар арасында галимнәр дә, шагыйрьләр дә, язучылар да, нефтьчеләр дә, төзүчеләр дә, укытучылар да, табиблар да һәм башка өлкә хезмәткарләре күп. Районның киң җәмәгатчелеге теләге белән 1-нче номерлы шәһәр урта мәктәбе урнашкан урамга мәктәпнең мәшһүр директоры Мирза Таһиров исеме бирелде. 2015 елның 9 декабре көнне Әлмәт шәһәрендә тагын бер күркәм вакыйга булды. Мәктәп диварына Татарстанның Атказанган укытучысы, Бөек Ватан сугышы ветераны, Ленин һәм III дәрәҗә Дан орденнары кавалеры Таһиров Мирза Каюм улына Истәлек Тактасы эленде. Әлмәт шәһәренең № 1-нче урта мәктәбе Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының 2016 ел 03 март карары белән «М. К. Таһиров исемендәге № 1-нче гомуми урта белем бирүче мәктәп», – дип атала башлады.

2010–12 елларда мәктәп белән Давыт Азат улы Мөхәмәтганиев һәм Фәридә Котдус кызы Шиһапова җитәкчелек итәләр. 2012 елның икенче яртысыннан мөдир вазифасын Рәсимә Әнвәр кызы Фәрдиева башкара.

# ӘЛМӘТ МӘКТӘБЕНДӘ МӨДИР (ДИРЕКТОР) ВАЗИФАСЫН БАШКАРГАН ШӘХЕСЛӘР

НАСЫЙБУЛЛИН КАСЫЙМ. Эшләгән еллары 1923–29. Әлмәт авылында тулы булмаган урта (җидееллык) белем бирүче татар мәктәбен оештырган;

ХӘТӘМТАЕВ ВӘГЫЙЗ. Эшләгән еллары 1929–32.

Вәгыйз Хәтәмтай улы 1923–28 елларда Әлмәт җидееллык мәктәбендә укытучы булып эшләгән.

МӨХӘММӘТҖАНОВ БӘКЕР (ӘБҮБӘКЕР). Эшләгән еллары 1932–33.

ГОБӘЕВ ШӘЕХ Ш. Эшләгән елы 1934.

ӘХМӘДИЕВ ШӘРИП (ШӘРИФҖАН). Эшләгән еллары 1934-1936.

Шәрип 1930–31 елларда Әлмәт район партия комитеты сәркатибе, ә 1932–33 елларда район башкарма комитетының Халык мәгарифе бүлеге җитәкчесе вазифасын башкарган (РОНО). 1935 елда Әлмәттә урта белем бирүче татар мәктәбен оештырган.

ХАРИСОВ ФӘЙЗИ. Эшләгән еллары 1937–39 елның беренче яртысы.

1932–37 елларда Әлмәт районы Габдрахман авылында 7 еллык мәктәп мөдире һәм укытучы булып эшләгән. 1939–41 елларда Яңа Нәдер 7 еллык мәктәбендә мөдир һәм укытучы. 1941елдан фронтта була, аннан яраланып кайтып, 1943–44 елларда Нәдер авыл Советы рәисе вазифасын башкара. 1944–69 елларда Яңа Нәдер мәктәбенең мөдире булып эшли.

КӘРИМОВ СӘЛАХ (СӘЛАХЕТДИН). Эшләгән еллы 1939–40 елның беренче яртысы.

1930 еллар уртасында Әлмәт районы башкарма комитетының Халык мәгарифе бүлеген җитәкләгән. Сугыш кырында һәлак булган.

ИСХАКОВ ГАЛИ. Эшләгән еллары 1940–41 елның беренче яртысы. Аның 1938 елдан укытучы булып эшләве генә мәгълүм.

ШӘЙДУЛЛИН ГАРИФ. Эшләгән еллары 1941–11.1942.

ТАҺИРОВ МИРЗА (МИРЗАҖАН) КАЮМ УЛЫ. Эшләгән еллары 12.1942–08. 1950. һәм 09.1955–1970; (чыганак – личный листок учёта кадров). Эвакуацияләнгән гаиләләрнең балаларын укыту өчен рус класслары оештыра. 1951 елдан татар телендә генә белем бирелә.

РАСКУЛОВ ГАЗЫЙМҖАН ХӘБИБРАХМАН улы. Эшләгән еллары 09.1950–08.1955.

КАЮМОВ ФАТЫЙХ КАЮМ улы. Эшләгән еллары 1970–1985. 1971 елдан мәктәп рус телендә белем бирүгә күчерелә.

ХУҖИН ӘЛФИС ХӨСӘЕН улы. Эшләгән еллары 1985–2010. 1991 елда мәктәпкә гимназия статусы бирелә. Яңадан татар телендә белем бирү башлана.

МӨХӘМӘТГАНИЕВ ДАВЫТ АЗАТ улы. Эшләгән еллары 2010–2011.

ШИҺАПОВА ФӘРИДӘ КОТДУС кызы. Эшләгән еллары 2011–2012.

ФӘРДИЕВА РӘСИМӘ ӘНВӘР кызы. Эшләгән еллары 2012 дән бүгенге көнгә чаклы. Әлмәт шәһәренең № 1 нче урта мәктәбе Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының 2016 ел 03 март карары белән «М. К. Таһиров исемендәге № 1-нче гомуми урта белем бирүче мәктәп», – дип атала башлый.

**Әдәбият:**

1. Р. У. Амирханов. Татарский народ и Татарстан в начале XX века. Казань: ТКИ, 2005.

2. А. Г. Галлямова и др. История Татарстана и Татарского народа. Казань: Изд. КФУ, 2014.

3. Деятельность Советов Татарии.1917–78 годы, документы и материалы. Казань: ТКИ, 1983.

4. Мәктәп музеенда саклanучы истәлекләр язылган кульязма китаплар.

5. Образование Татарской АССР. Сборник документов и материалов. Казань, 1963.

6. В. Г. Сальников. Бугульминское земство. Изд. Второе, дополненное, Бугульма, 2005 г.

7. Х. Солтанов. Нараттау чишмәсе. Яңа Кәшер авылы, аның мәгърифәте турында. Яр Чаллы, 2015 ел.

8. Ф. М. Султанов. Татарское национальное движение. Казань: «Магариф», 2000.

9. И. Р. Тагиров. История национальной государственности татарского народа и Татарстана. Казань: ТКИ, 2008.

10. А. Ю. Хабутдинов. Лидеры нации. Казань: ТКИ, 2003.

11. Р. С. Хакимов. Письмо Татар. Статья в газете «БИЗНЕС ONLAINE», 2015.

12. Р. Ә. Шакирҗанов һ.б. Мәшһүр татар галимнәре. Казан: ТКН. 2011.

13. М. И. Әхмәтҗанов. Дастаннар ватаны. Казан: «Мәгариф» нәшрияты, 1999.

# ПАТРИОТИК ТӘРБИЯ ФАКТОРЫ БУЛАРАК УКУЧЫЛАРНЫҢ ТУГАН ТӨБӘК ТАРИХЫ БУЕНЧА ЭЗЛӘНҮ ЭШЧӘНЛЕГЕ

***Р. Ф. Гиматдинова***

***Аннотация:*** *Статья посвящена исследовательской деятельности школьников по краеведению. На основе анализа одной исследовательской работы анализируется поэтапное выполнение исследовательской работы. Раскрывается важность этого вида деятельности для патриотического воспитания молодого поколения.*

***Ключевые слова:*** *Исследовательская работа, ФГОС, исследовательские методы, краеведение, патриотизм.*

Илебездә кертелгән яңа федераль стандартларның нигезендә укучыларның актив уку-танып белү эшчәнлеге ята. Укучылар дәрес һәм дәрестән тыш эшчәнлек кысаларында универсаль уку эшчәнлегенә өйрәнергә тиешләр. Бу юнәлештә эш эзләнү һәм проект эшчәнлегенең нигезләрен өйрәнү, кирәкле күнекмәләрне формалаштыру, эш нәтиҗәләрен күрсәтә белүгә юнәлдерелгән булырга тиеш. Шулай ук укучыны шәхес буларак формалаштыру өлкәсендә: патриотизм, туган илгә хөрмәт, күпмилләтле илебез халкының үткәнен һәм бүгенге тарихын, мәдәниятен өйрәнү дә хәзерге җәмгыять таләбе булып тора. Шуның өчен дә туган төбәк тарихы буенча укучыларның эзләнү эшчәнлеге зур әһәмияткә ия, ә патриотик тәрбия өлкәсендә тәҗрибә уртаклашу хәзерге укыту-тәрбия процессының төп өлешен тәшкил итә.

Теләсә нинди эшчәнлек белән шөгыльләнү өчен уңай мотивация булдыру шарт. Тәҗрибә күрсәткәнчә, монда иң беренче чиратта укучыларның яңа белемгә омтылу теләгенә таянырга, туган төбәк, үз гаиләсе, якын кешеләре тарихына кызыксындыру уятырга, логик һәм фәнни фикер йөртү формалаштырырга кирәк.

Эзләнү эшчәнлеге башкару укучыларның билгеле бер күнекмәләрне үзләштерүен күз алдында тота. Болар: проблеманы, гипотезаны куя белү, үз эшчәнлеген планлаштыру, эзләнүне үткәрү, нәтиҗәләр ясау һәм аудитория алдында үз эшен яклау. Эзләнү эшчәнлеге күнекмәләрен булдыруда түбәндәге алымнар ярдәм итә:

• объектка кереп китү методы (укучы объектка күчә, аны эчтән өйрәнә),

• проблеманы куя белүгә юнәлдерелгән «әгәр дә...»дигән метод (укучы әгәр дә дөньяда нәрсә дә булса үзгәрсә ул нинди булыр икәнлеген тасвирлый),

• гипотеза кую күнекмәсен булдырыга «Блум ромашкасы» ярдәм итә (укучы төрле сораулар куярга һәм аларга җавап бирергә өйрәнә),

• шулай ук чагыштыру методы, эвристик эзләнү методлары да кулланып була.

Формалаштырган күнекмәләргә таянып эзләнү эшченлеге башлана. Мин музей җитәкчесе буларак, укучыларны аның эш юнәлешләре белән таныштырам. Укучылар үзләренә якын булган, кызыксындырган темаларны сайлыйлар һәм эшләнү эшенең этаплары белән танышалар. Бергә эшнең актуальлеген, максатын, бурычларын, эзләнү методларын билгелибез. Шуннан соң укучылар эзләнү үткәрә, нәтиҗәләргә анализ ясый, йомгакны формалаштыра. Башкарылган эшләр таләпләргә туры китереп рәсмиләштерелә һәм төрле дәрәҗәдәге конференцияләрдә яклана, призлы урыннарга лаек була. Эзләнү эшләренә таләпләрне, башкару этапларын слайдларда күрсәтеп була. Бик еш укучылар сугыш темасын сайлый һәм һәркем бу теманы үз күзаллауларыннан чыгып ача. Безнең мәктәп укучылары түбәндәге темалар буенча эшләр башкарды:

– «Сугыш һәм хатын-кыз» (безнең авылның зенитчы кызлары);

– «Сугыш чоры балалары» (сугыш чорына балачаклары туры килгәннәрнең язмышлары;

– «Фаҗигале язмыш» (тоткынлыкта булган хатын-кызның истәлек язмалары);

– «Герой якташлар» (Иске Шөгер авылы Советлар Союзы Геройлары);

– «Сугыштан килгән хатлар» (авылда сакланган сугыш чоры хатлары);

– «Минем бабамның сугыш һәм хезмәт батырлыгы»;

– «Шөгер-нефть төбәге» (сугыш чорында Яңа Шөгер авылы янында беренче Татарстан нефте табылу);

– «Сугыш чорында мәктәп» (сугыш чорында укучылар, укытучылар, укытучы-ветераннар).

Бу эшләрнең һәрберсе укучыларны битараф калдырмый, аларны туган илне яратырга, өлкән буын кешеләренә хөрмәт белән карарга өйрәтә. Әлбәттә эзләнү сугыш темасы белән генә чикләнми. «Иске Шөгер авылы тариха», «Яңа Шөгер авыл тарихы», «Авыл топонимикасы», «Авылыбызның күренекле шәхесләре», «Муллалар нәселе», «Мәктәп тарихы», «Минем гаилә шәҗәрәсе» һәм башка бик күп эшләр башкарылды. Шулар арасында берсенә тукталып үтәсем килә. Ул эш «Музей экспонаты нәрсә

турында сөйли ала» дип атала һәм ул сугыш чоры журналларын өйрәнү нәтиҗәсендә башкарылды. Шулай ук бу эш Сарабикул авыл тарихына да кагылышлы. Бу эшне башлап җибәргәндә иң катлаулы этап булып эзләнү эшенең планын төзү булды. Без үзебезгә сорау куйдык «Чынлык та да без бу журналлар буенча нәрсә белә алабыз соң?» Бу сораугa җаваплар табу нәтиҗәсендә түбәндәге план барлыкка килде:

– укучылар һәм укытучылар контингенты;
– укытылучы предметлар, хәзергеләр белән чагыштыру;
– белем сыйфаты;
– дәресләргә йөрү;
– таныш кешеләрне табу;
– уку кирәк яраклары;
– укучыларның Бөек Җиңүгә керткән өлеше.

Әлбәттә, кайбер сорауларны тулыландыру максатында сугыш чоры журналларында исемнәре булган кешеләргә ярдәм сорап мөрәҗәгать итәргә туры килде. Иске Шөгер мәктәбе райондагы иң беренче урта мәктәп булган. Аның беренче чыгарылыш укучылары барысы да диярлек Бөгелмә шәһәрендә кыска сроклы курсларны тәмамлап укытучы була. Урта мәктәпне тәмамлап югары уку йортына керергә теләгән якын-тирә мәктәп укучылары монда интернатта торып белем ала. Сугыш чоры журналларын өйрәнгәндә без таныш кешеләрне эзләдек. Бер журналда республикабызның танылган язучысы Җәмит Рәхимовның билгеләренә тап булсак, 9 сыйныф журналында Роза Хафизова фамилиясенә игътибар иттек. Танылган язучы, Сарабикул мәктәбендә укыган Роза Хафизова икәнлегенә икенче бер документны-аттестатлар бирү журналын өйрәнеп исбатладык. Анда 1946 елда Сарабикулдан 1929 елда туган Хафизова Роза Саитовнага аттестат бирелү турында язма бар. Бу эшне башкарып укучы Лениногорск шәһәре музее үткәргән конференциядә чыгыш ясап беренче урынны алды.

Безнең укучылар шулай ук Хәтер китабын тулыландыруда да катнашты, мәктәп музеennан, халыктан кирәкле мәгълүмат җыйдык.

Укучылар тарафыннан башкарылган эшләр барысы да мәктәп музеена тапшырыла. Экскурсияләр әзерләгәндә алар кулланыла. Сугыш чорына багышланган эшләрдән «Иске Шөгер авылы сугыш чорында» дигән виртуаль экскурсия оештырдык. Шулай ук мәктәпкүләм чаралар үткәргәндә дә без бу эшләргә таянабыз, алар кулланылмыйча тормый. Мәктәп музеендагы безнең стендлар да укучыларның эзләнү эшләренә таянып ясалган. Шулай итеп музей да укучылар һәм укытучыларның бердәм социаль проеты булып тора. Эзләнү эше башкарып аны мәктәптә генә түгел район, зона, республика күләмендә яклау укучыларда

зур горурлык хисе тудыра һәм киләчәктә дә бу юнәлештә эшне дәвам итәргә этәрә.

Нәтиҗә ясап бу педагогик эшчәнлекнең практик әһәмиятенә басым ясыйсы килә, аның барышында укучыларда иҗади, интеллектуаль, танып белү һәм коммуникатив сәләтләр үсеш ала. Федераль дәүләт стандартларының шәхес формалаштыру юнәлешендәге максатларына ирешелә.

**Әдәбият:**

1. Иске Шөгер мәктәбе музее. Сугыш чоры журналлары. Инв. №56
2. Иске Шөгер мәктәбе музее. Аттестатлар бирү журналы. Инв. №57

# ИЗ ОПЫТА СОЗДАНИЯ УЧЕБНИКА ПО ИСТОРИИ САБИНСКОГО РАЙОНА

***И. Ф. Сафин***

Изучение истории – важный элемент обучения и воспитания подрастающего поколения. Прошлое нашей Родины состоит из прошлого ее малых городов и сел. Краеведение давно стало одним из ключевых элементов учебно-воспитательного процесса. В рамках образовательной стратегии разработана программа Министерства образования и науки РТ «История родного края». В Сабинском районе в рамках этой программы создан учебно-методический комплект «История Сабинского района». Он включает программу курса, тематическое планирование учебного материала (34 учебных часа), учебник для учащихся (220 страниц), методическое пособие для учителя, диск с презентациями к уроку и полуторачасовым видеофильмом по историческим местам родного края.

Учебник адресован учащимися среднего звена общеобразовательных школ района. Педагогическая целесообразность данного учебника обусловлена тем, что при изучении истории России в школе малая родина зачастую выпадает из поля зрения педагога и учащихся. Этот курс призван помочь учителю расширить знания детей о родном крае, увидеть его в общем ходе истории, ощутить свою связь с прошлым и настоящим страны. Учебник по истории родного края позволяет преподавателям совершенствовать свою деятельность по патриотическому, нравственно-эстетическому воспитанию молодежи.

Особенность данного учебника состоит в том, что он изначально ориентирован на изучение богатого историко-культурного наследия Сабинского района, собранного сотрудниками краеведческого музея, учителями истории, любителями старины.

Учебник адаптирован к условиям образовательного процесса общеобразовательной школы, в которой проводится работа по изучению истории малой Родины, в нем собран краеведческий материал (документы, воспоминания, предметы материальной культуры)

Учебник «История Сабинского района» создан авторским коллективом из пяти преподавателей истории. Научный руководитель – Заслуженный деятель науки Республики Татарстан Альберт Ахметзянович Бурханов. Рецензент – ведущий сотрудник Института истории им. Ш. Марджани АН РТ, кандидат исторических наук Розалинда Нуриевна Мусина. Авторы учебного пособия стремились отразить на его страни-

цах все сферы жизни и деятельности, самые важные вехи истории Сабинского края. Все события, отраженные в учебнике, основаны на архивных документах, воспоминаниях современников, письмах, фотографиях. Был максимально использован археологический материал, содержащий огромный социокультурный потенциал. Благо, в нашем районе проводилось несколько археологических экспедиций. В 1925 году на территории нынешнего Сабинского района работала этнографическая экспедиция под руководством Н. И. Воробьева. 1998–2001 годах под руководством археолога, академика РНАН А. А. Бурханова проведены крупномасштабные исследования и стационарные раскопки на территории Сабинского района. Основным объектом изучения стало Утернясское городище. Раскопки выявили уникальные находки и дали важные результаты, подтверждающие данные письменных источников. Исследователи связывают остатки данного городища с упомянутым в русских летописях, в частности Никоновской летописи, а также Царственной книге, Мешинским городком в 70 верстах от Казани.

Сабинская земля имеет свою многовековую историю. О ней упоминается в историческом народном дастане «Идегей» (повествующий о трагических событиях конца XIV века), где она значится в ряде городов булгар-татар как «Сабы в глубине лесной». В течение многих веков – до и после Октябрьской революции – наши умелые предки славились своими успехами в области земледелия, животноводства, занимались кустарничеством, были высокопрофессиональными мастерами по изготовлению изделий из серебра, деревянной посуды, возделыванию меха и кожи, пошиву одежды. Продолжая их благородные дела, труженики Сабинского района преумножают славу родной земли. Широко известны достижения наших хлеборобов, животноводов, лесоводов, газовиков, строителей, транспортников и работников сферы обслуживания. Все это легло в основу данного учебника.

Содержание курса предполагает работу с разными источниками информации: географическими картами, учебниками, дополнительной литературой, диаграммами, рисунками. Содержание каждой темы учебника включает в себя самостоятельную (индивидуальную или коллективную) работу учащихся. При организации занятий целесообразно создать ситуацию, в которой каждый ученик мог бы выполнить индивидуальную работу и принять участие в работе группы. Важно организовать подготовку учащимися устных сообщений с использованием различных источников, информации, литературных источников материалов периодической печати, информационных ресурсов Интернета. Рекомендуется проводить исследовательские работы по изучению истории развития и современного

состояния Сабинского района, составление проектов о перспективе развития района, разработки возможных туристических маршрутов.

Основные цели курса: создание условий для формирования и развития у учащихся интереса к изучению родного края, к самостоятельному приобретению знаний, развитие творческих способностей и коммуникативных навыков.

Принципы учебного пособия «История Сабинского района»:

1. Принцип научности – включение в содержание основных исторических понятий, системность обучения и воспитания;

2. Принцип демократичности – достигается не только тем, что общеобразовательное учреждение определяет вариант ее реализации, но и тем, что учитель самостоятельно избирает пути достижения планируемого программой результата деятельности; включает в планирование изучение истории родного села и школы.

3. Принцип практической направленности – практическая направленность реализуется за счет введения в каждый блок практических занятий, экскурсий, творческих заданий.

4. Принцип гуманизации – достигается за счет ведения краеведческого материала, позволяет сделать основные исторические события ярче, ближе и интереснее для учащихся, способствует эффективному формированию ценностных ориентаций, развитию интереса и уважения к истории своего народа, своего края. Школьники получат сведения об истории, познакомятся с выдающимися людьми: деятелями науки, культуры, образования, экономики, внесшими свой вклад в освоение и развитие района.

К внетекстовым компонентам учебника относятся иллюстрации, вопросы и задания, документы, а также указатели. В учебнике более 100 различных фотографий. Иллюстрации и фотографии используются для создания образов прошлого, раскрывают содержание книги средствами образной и знаковой наглядности.

При издании учебника соблюдены регламентируемые форматы учебников на основании ОСТа 29.116-87 «Учебники и учебные пособия для 1–11(12) классов общеобразовательной школы. Издательское оформление и полиграфическое исполнение с изменениями № 1 от 01.01.88 и № 2 от 31.01.92».

Учебник пока издан в издательстве «Идел-Пресс» в единственном экземпляре в 2012 г. и участвовал в республиканском конкурсе по разработке программ и учебно-методического комплекта курса «История родного края».

Как было сказано выше, в комплекте с учебником изданы методическое пособие и компакт-диск с презентациями к каждому уроку и полуторачасовым видеофильмом.

Пособие для учителя содержит краткие конспекты уроков учебного курса «История Сабинского района».

Конспекты уроков включают:

– список ключевых понятий и наименований, время событий.

– информацию об исторических личностях;

– подробные рекомендации по организации изучения нового материала;

– широкое применение мультимедийных технологий.

Ведущей целью создания и применения видеофильмов по истории Сабинского района является достижение более глубинного запоминания краеведческого материала через образное восприятие, усиление эмоционального воздействия, «погружение» в атмосферу исследования.

В методическом пособии представлен краеведческий библиографический указатель. В нем даны материалы о Сабинском районе, охватывающие период с 1940 по 2002 гг. Они расположены по темам, указанным в разделе «Содержание». Информация расположена в хронологическом порядке, в некоторых тематических разделах – по алфавиту. Для удобства пользования в конце издания дается именной вспомогательный указатель.

При составлении указателя использованы следующие источники: Летопись печати Республики Татарстан с 1930 по 2002 гг.. Систематическая картотека газетно-журнальных статей Республики Татарстан, каталог книжных изданий; электронные базы данных; библиографические данные, представленные Центральной библиотекой имени Абрара Каримуллина Сабинского района.

Учебник может использоваться на уроках изучения родного края за счет школьного компонента (1 час в неделю), при организации факультативных курсов, элективных курсов и во внеклассной работе.

**Литература:**

1. А. А. Бурханов. Столица в изгнании// Татарстан. 2001. №12. - С. 32-35.

2. А. А. Бурханов. Мешинская заповедная зона – мечта или реальность?// Татар.края. 2002. № 15. – С. 2.

3. Е. П. Казаков, П. Н. Старостин, А. Х. Халиков. Археологические памятники Татарской АССР. Казань: Татар. кн. изд-во, 1987. С. 193-197. Сабинский район.

4. Н. С. Фаттах. Язык богов и фараонов. Историко лингвистическое исследование. Казан: Татар.кн.изд-во, 1999. – С. 188–244.

5. Исторические очерки, статьи, научные труды по истории Сабинского района. Казань: Отечество, 2007.

## Мирасыбызның төбәк тарихына кагылышлысы/ Наше историко-краеведческое наследие.

# «МӘЛИКӘ КИТАБЫ» ТАРИХЫ

***Ф. З. Яхин***

***Аннотация:*** *Әдәби-мәдәни тарихыбызда «Мәликә китабы» аерым әһәмиятле урын тота. Хезмәттә шушы борынгы әдәби ядкәргә әдәби-текстологик анализ ясала, аның нәтиҗәләрендә әсәрнең язылган чоры һәм авторы ачыклана, жанр үзенчәлеге, тарихи дәвере, мәгънәләре белән бәйле мәсьәләләр чишелә.*

Иске әдәби ядкәрләребезнең классик ятмалары өйрәнелеп, бәяләнеп, ачыкланып беткән дә кебек тоела кай вакытларда. Әдәбиятыбыз тарихын яктырткан томлыкларда һәм татар әдәбиятына караган хезмәтләрдә, элеккерәк чорлардагы, Т. Ялчыгол, Г. Чокрый, К. Насыйри, Ш. Мәрҗани, Р. Фәхретдинов, Г. Сәгъди, Г. Рәхим, Г. Газиз кебек XIX-нчы гасырга һәм XX-йөз башына караган иске язмалы гыйльми тикшеренү әсәрләреннән гайре, һәм хәтта аларда да, телгә алынмаган, фән каһарманнары тарафыннан әлегә бөтенләй дә кузгатылмаган, шулай булуга да карамастан, аңны һәм күңелне әсир итәрлек әдәби мирасыбыз катламы табылмаган хәзинәдәй халык күзеннән һаман да яшерен яткырыла. Шул байлыкларыбызның бер энҗесе – «Мәликә китабы». Электән аны татар халкы укып яшәгән. Әсәр милләтнең рухи терәге хезмәтен үтәгән, ул чын мәгънәсендә әдәби-мәдәни тарихи байлыгыбыз. «Мәликә китабы» 1846-нчы елда Казан университеты карамагындагы «Азиатской нам табигъханәсе»ндә урта форматта, 16 сәхифә күләмендә беренче тапкыр бастырылып чыгарыла. Моңа кадәр дә күптөрле кульязма күчермәләрендә укылган китап, нәшер ителүенә, үзенең кулланылу ареалын тагын да киңәйтә һәм татар сәүдәсенең керемле төп товары сыйфатында Урта Азия, Кырым, Себер, Кавказ, хәтта Төркия һәм Европаның төрки төбәкләренә кадәр барып ирешә. Аны белем учаклары булган университетларның китапханәләрендә дә очратабыз. Китапны Бәрәскә авылыннан (хәзерге Татарстанның Әтнә районына карый) Габденнасыйр улы мулла Мөхәммәдшакир текстологик яктан хәзерләп, хашиясенә (текст читләренә) әсәрдә очраган кайбер сүзләргә тәрҗемәләр биреп бастырып чыгара.

Дөнья йөзенә шушы кадәр киң таралуына һәм иске заманнарыбызда төп уку китапларыбызның берсе булуына карамастан, «Мәликә китабы» әдәбият, тарих, тел һәм дин, фәлсәфә галимнәре тарафыннан өйрәнел-

ми калган булуы белән тагын да гаҗәпләндерә. Һәрхәлдә аны әдәбиятчылар, телчеләр һәм дин галимнәребез беренче чиратта өйрәнергә тиеш иделәр, чөнки әсәрнең теле – иске әдәби татар телебез, аның эшләнешен, лексик-грамматик дәрәҗәсен ачык саклаган, сыйфатын да ачык күрсәтә, эчтәлегендә дини тәгълиматлар, мәдәни кыйммәткә ия мәгънәләр схоластик нигездә, бәхәссез итеп әдәби формада бирелгәннәр. Шулай да кайбер мәсьәләләрдә дини карашлардан читкәрәк «чыгу», «тайпылу» (мәсәлән, яман-бозык кешеләрдән төрле хәрәми хайваннарның барлыкка килүләре хакындагы хәбәрләр һ.б.) күренешләрен дә аңарда күзәтергә мөмкин.

«Мәликә китабыны»ның хикмәте шунда, ул халкыбыз аңы үсешенең аерым бер тарихи чорының барлык үзенчәлекләрен үзендә чагылдыра. Аның әдәби стиль ягы да кызыклы. Дөрес, бу әсәрдә Алтын Урда дәверенә яисә аннан соңгырак чорлардагы прозага хас шомартылган, матур әдәби тел юк. Ул гади, халык әдәбияты әсәрләре формасына корылган. «Мәликә китабы» гыйбрәт өчен, тормыш мәгънәсен аңлар өчен түгел, укучыга дини-фәлсәфи карашларны җиткерү максатыннан чыгып язылган. Шулай да ул әдәби әсәр, чын мәгънәсендә матур әдәбият әсәре. Аның хәтта корылышы да могҗиза һәм маҗара хикмәтләрен үзенә җыйган, гади булсын, әмма геройлар тарафыннан алып барылган сорау-җавап ярышы мавыктыргыч рәвештә төзелгән. Менә шушы мавыктыру көче могҗиза һәм маҗара тойгысын тудыра да инде.

Шушы кечкенә генә хикәят китабы, үз вакытына хас төрле фәннәрдән хәбәрләрне бергә җыюы сәбәпле дә күңелдә калын роман кадәр әсәр уку тойгысын калдыра. Әсәр хакында Г. Рәхим болай дип яза: «Мәликә китабы»ның кем тарафыннан һәм кайчан язылуы китапның үзендә әйтелмәгән. Ул татар арасында йөри торган хикәятләрнең иң борынгы тел белән язылганнарыннан. Бу безнең халыкта бик макбул бер китап. Хосусан катын-кыз аны укучан» [Г. Газиз, Г. Рәхим: 1923. Б. 89]. Ул хаклы да, шул ук вакытта аның белән бик үк килешеп тә бетеп булмый. Асылы белән бу китап гуманитар фәннәрнең төрле өлкәләре өчен дә фәнни кызыксыну ягыннан әһәмиятле һәм шулай ук әдәбилек үзенчәлегеннән караганда да заманча белгеләмәләр нигезендә тикшерелеп бәяләнергә хаклы милли язма ядкәрләребезнең берсе булып тора. Әмма гыйльми тикшеренүче алдына килеп баскан төрле мәсьәләләрдән күбесен җиңел генә хәл итү дә мөмкин түгел. Бу милли әдәби мирасыбыз энҗесенең үзенчәлекләрен һәм эчтәлеген аңлау-аңлату өчен күпкырлы фәнни эзләнүләр алып барырга туры килә.

## I

Әсәрнең «китап» дип аталуы кызыклы. Аның 1846 нчы елгы басмасыннан гайреләре дә 110×170 мм. үлчәмле кәгазь битләренә басылган нибары 16 сәхифәдән гыйбарәт, ягъни ул «уртакул» зурлыкта. Сәхифәләрнең дә бе-

ренчесе титул битенә туры килә, анда, гадәттәгечә, китапның исеме, цензура рөхсәте, кайда басылуы һәм типографиясе бирелә. Кайбер басмалары юка кәгазь тышлыкка тегелүдә тәкъдим ителгән. Әсәрнең тексты икенче биттән «бисмиллаһ» белән башланып китә, кызыл юлсыз, җөмләләре үзара тоташ бара. Тыныш билгеләре бөтенләй юк. Сәхифә номерлары өске якта уртада, җәяләр эчендә бирелеп бара. Текст төзек рамкалар белән каймаланган. 90×135 мм. зурлыктагы ул кысалар татар басма китабы өчен гадәти күренеш булып тора. Җөп номерлы сәхифәләрнең аскы ягында сулда, рамкадан тыш урында алга таба киләчәк биттәге текстның беренче сүзе бирелгән. Болар барысы да «Мәликә китабы»ның татар китап культурасы шартларында эшләнелешен ачык күрсәтеп торалар. Аның кулъязма вариантлары да шундый ук рәвештә һәм сыйфатта булулары белән әһәмиятлеләр. Әмма сораулар туарлык урыннар да бар. Аларның берсе: зур күләмдә булмаган әсәрне, һәм гомумән дә бу әсәрне ни өчен «китап» дип атаганнар? Кыйсса да түгел, хикәят тә диелмәгән. Асылда бу төр әсәрләрнең басмалары тышында жанры күрсәтелә. Монда әсәрнең жанры «китап» дип куелуны аерым игътибарга алмый мөмкин түгел, чөнки бу мәсьәләне ачыклап узарга кирәк дип саныйбыз. Басмага әзерләүчеләр «китап» сүзен «хикәя»гә яки башкага алыштырмаган. Бусы да әһәмиятле. Әсәр, ничә басмасын алып карамыйк, һаман да шулай «китап» буларак дөнья күргән. Бу хәл әдәбият тарихыбызда чәчмә әсәрләрнең жанрлары ачыкланмаган дәвердә үк әсәрнең язылган булуы хакында сөйли. Ә нигә башка чор, яңарак дәвер күчерүчеләре аны, мәсәлән, «Мәликә хикәяте» дип атамаганнар? Җавабы гади: андый үзгәртүнең кирәге булмаган.

Татарда әдәби әсәрне дә, шәригать белән бәйле хезмәтләрне дә һәм, гомумән, төпләнелгән һәммә төрле нөсхәләрне «китап» дип билгеләп йөртү яши. Бездә хәтта «таш китап» дип VII–VIII йөз кабер таш язмаларын да атау бар. «Ташка басылган» дигән гыйбарәбез исә «мәңгелек», «югалмаслык» төшенчәләрен бирә, ныклыкны, катгыйлыкны, үзгәрмәслекне аңлата.

Гарәптән телебезгә кергән бу сүзгә кадәр бездә «битиг» (X гасыр китабы «Ырк битиг»не искә төшерик) сүзе кулланылган. «Китап» сүзе гарәптә «кәтәбә» (язу) сүзеннән булган кебек, безнең борынгы телебездәге «битиг» тә «битү» (язу) [ә «Ырк битиг»тә: «батидим» (яздым) дигән] сүзеннән ясалган. Бу факт исә «Мәликә китабы» язылган чорда халкыбыз телендә «китап» сүзе «бетек»не алыштырган һәм кулланылышка кертелгән булган дигән фикергә этәрә. Әгәр дә «Ырк битиг»нең X йөздә иҗат ителүен искә алсак* һәм әсәр жанрын «битиг», ягъни «китап» дип атау

* Күп кенә хезмәтләр «Ырк битиг»нең IX йөздә язылуын белдерәләр. Европа галимнәреннән Дж. Р. Гамильтон аның тәмам булу датасы 930 нчы елның 17 нче марты икәнлеген ачыклаган [Карагыз: Кляшторный: 2006])

традициясе сакланган чорда «Мәликә китабы»ның язылган булуын искәрергә тиешбез. Аннары тагын да шунысы бар: гарәп сүзләре кулланылса да (алар икесе дә – «Мәликә» дә, «китап» та – гарәп сүзләре), алар төрки тезмә формасында бирелгәннәр. XII йөзләрдә яки аннан соңрак тудырылса, бу әсәрне бездә гарәп-фарсы калыбында «Хикәяте-Мәликә» яки инде «Китабы-Мәликә» исеме белән атар иделәр. Һәр чорның үз стиле, язма традицияләре, әмма бездә алар кайберәүләр өчен әлегә ачыкланылып кына җитмәгәннәр кебек.

XII гасыр шагыйре Ә. Яссәвинең (1091–1166) китаплары «дәфтәр» дип аталганнар: «Дәфтәри-әүвәл» («Беренче дәфтәр», ягъни «Беренче китап») һәм «Дәфтәри-сани» («Икенче дәфтәр», ягъни «Икенче китап»). Инде, күренеп тора, сүзләр гарәп-фарсы калыбында урнаштырылганнар. XV–XVI-нче йөзләр шагыйре Мәҗлиси генә «Сәйфелмөлек дастаны»нда «китап», «дәфтәр» урынына себер татар сүзе «тута» («тота») сүзен куллана. Бу фактлар гыйльми эзләнүләр өчен зур әһәмияткә ия һәм күп кенә тарихи мәсьәләләрне ачык күзалларга мөмкинлек бирәләр. Әсәрнең борынгы әдәби ядкәрләрдән булуын белдергән Г. Рәхимнең сүзләренә шик калмый да төсле. Әсәрнең сорау-җавап тәртибендә төзелешенә игътибар итеп ул: «Бу мәүзугъ Шәрык дөньясында бик борынгы заманнарда ук ясалган булырга кирәк,– дип белдерә,– чөнки легендаларда «Саба» мәликәсе «Бәлкыйс»нең дә Сөләйман патшага, шундый читен сөальләр биреп, Сөләйман аларга җавап биреп, Бәлкыйстән бик күп мал вә хәзинә отып алганлыгы сөйләнә» [Газиз, Рәхим: 1923. Б. 88]. Г. Рәхим алга таба «Кәләф белән Турандык» әсәренең дә шушындый ук формада язылуын искәртә һәм: «Мондый хикәятләрдән безнең татарда күп элек таралганы «Мәликә китабы» [Газиз, Рәхим: 1923. Б. 88],– дигән нәтиҗәгә килә.

Жанрына караганда, «Мәликә китабы», бәхәссез, хикәяткә туры килә. Әдипнең фантазиясе нигезендә тудырылган, чәчмә яки тезмә формада язылган, бер сюжет линиясенә корылган әдәби әсәрләр борынгы әдәбиятта хикәят дип йөртелә [Әдәбият белеме сүзлеге: 1990. Б. 204]. Хәзерге әдәбиятка хас хикәя жанрының килеп чыгышы хикәятнең тарихи үсеше белән бәйле. Әмма хикәядән хикәят яки әкиятрәк, ә әкият жанрыннан исә дөньявирак булуы белән аерылып тора, катырак жанр буларак да бәяләнергә мөмкин. Аның һәм хыялый, һәм рационалистик нигезгә корылуы да әһәмиятле. Үзенең тарихи үсешендә хикәят, кыска анекдотлардан күләмле повесть-кыйссаларга кадәр, күптөрле жанрларга бәйле уртак исем белән кулланылып йөртелгән. Рационалистик нигезләргә корылган булуы сәбәпле аңа Шәрык әдәбиятларында төрле әдәби-фәлсәфи агымнарга караган әдипләр мөрәҗәгать иткәннәр. Хыялый сюжетка корылганнарыннан әкиятләр барлыкка килгән. Тезмә яки чәчмә белән язылуы

исәпкә алынмаган, чөнки һәр төргә әдәби әсәр тезмә яки чәчмә рәвештә тудырыла, яши, укыла ала. Бу – авторның талантына бәйле.

«Мәликә китабы»ның үз чорына хас матур әдәбият кысаларында язылганлыгы һәм гади укучыга аталган булуы эчтәлегеннән аңлашылып тора. Мәгънәләрне бирү ягыннан формасы да кызыклы. Әсәрнең төп өлеше сорау-җавап тәртибенә корылган. Аның халык әдәбияты әсәре тибында төзелүе исә тарихта сакланып калуын тәэмин иткән. «...Татар теле башта әдәбиятның хикәяләр, кыйссалар бүлегендә нык оя ясады,– дип яза Г. Рәхим, халык әдәбияты мәсьәләләрен кузгатып. – Бу төрле әдәбият «голамә» өчен түгел, бәлки «гаувам» [гавәм]** өчен. Киң халык массасына уку материалы итеп языла һәм нәшер ителә, шунлыктан аның халык теленә иң якын булган бер телдә булуы һәм матлуп һәм табигый иде. Шулай итеп, хикәят китаплары әдәби татар теленең барлыкка килүе юлында бер күпер, бер баскыч ролен үтәделәр» [Газиз, Рәхим: 1923. Б. 95].

«Мәликә китабы»ның эчтәлеге, формасы һәм адресаты, ягъни нинди укучыга атап язылганлыгы, аның халык әдәбияты ядкәре (халык иҗаты, ягъни фольклор ядкәре түгел) булуын ачык белдереп торалар. Ул тел җәһәтеннән дә халыкчан, әмма сөйләм телендә язылган әсәр түгел, үз чорының әдәби теле кысаларында барлыкка китерелгән. Анда берникадәр чыгтай әдәби теле элементының булуы, госманлы әдәби теленең бөтенләй тәэсире юклыгы, беренчедән, госманлы әдәби теленең әлегә мәйданга куелмавы (ә госманлы әдәби теле XIV гасырда көчле үсеш ала), икенчедән, әсәрнең суфичыл даирәләр белән бәйләнеше азлыгы, яисә бөтенләй юклыгы хакында да ачык сөйли, чөнки суфичылык үскән елларда безнең Идел-Урал халкы чыгтай әдәби телле Урта Азия белән тыгыз бәйләнештә яшәгән.

Ә менә әдәби әсәрнең жанрын «китап» дип атау яссәвичеләргә кадәр үк булган. Шунысы кызыклы, ул чорда әсәр әгәр дә «китап» дип аталган икән, аннары да ул шул атамасында калдырылган, мәсәлән, «Кисекбаш китабы». Ә XIII гасырда язылган әсәрләр, аерым китап формасында төпләнеп йөртелсәләр дә, жанрларына бәйләнештә исем алганнар, һәм шунысы кызыклы, XIX йөздә басма китап төсен алгач, традицион үз аталышларын саклаганнар, мәсәлән, С. Бакырганиның (1111–1186) «Ярты алма кыйссасы», «Мәрьям ана кыйссасы». Әмма шунысын да искәртү урынлы: С. Бакырганиның тормышы турында язылган әсәр исә «Хәким ата китабы» дип атала. Моның хикмәтенә төшенү өчен ул әсәрне аерым алып тикшерү хәерле...

Тарикать гыйлеменә бәйле хезмәтләрен суфилар XIII йөздә «дәфтәр» дип атап йөрткәннәр, Ә. Яссәвинең «Хикмәтләр» китабы да авторы тарафыннан «дәфтәр» диелгән. Әмма яңа суфи тарикатьләрендә алга таба, башка гасырларда үзгәрешләр барлыкка килә.

«Дәфтәр» сүзе фарсыдан телебезгә кабул ителгән, ул да шулай ук «битиг», «китап» мәгънәләренә ия [Клевцова: 2000. С. 268]. Әмма бүгенге көндә телебездә «дәфтәр» һәм «китап» сүзләре үзара синонимнар буларак саналмыйлар. Дәфтәрне – язу өчен, китапны – уку өчен дип беләбез. Иске замандагы сүзләрнең хәзерге мәгънәләренә туры килмәве сәер, очраклы хәл түгел.

Татар халкы, башка мөселманнар кебек үк, китапта язылган сүзләргә зур хөрмәт белән караган. Бездә басма сүзне үзгәртү өчен зур укымышлы булу соралган. Андый эшкә Г. Утыз Имәни кебек галимнәр генә алынган. Ә аларның халык әдәбияты әсәрләрен «карап чыгу»ны кирәк табулары хакында бер хәбәр дә юк. Бу сәбәп белән булыр, «Мәликә китабы» нинди исем белән мәйданга чыгарылса, шулай аталып һәм укылып йөртелгән, иске заманнарда татар хыялы белән тудырылган хәлендә гасырдан-гасырга кала биргән. Телендә чыгтай сүзләре очраштыру исә халкыбызның сөйләме иске заманнарда Урта Азия төркиләренеке белән бәйле булганлыгы хакында сөйли, бусы – бер, икенчедән, «Мәликә китабы» авторының укымышлы кеше, затлы аристократ-аксөякләрдән икәнлеген искәртә. Ул халык әдәбияты әсәрен тудыруын үзе дә яхшы төшенеп эш иткән. Ислам дини тәгълиматыннан аның белемнәре камил. Укучыга әйтер сүзе дә төгәл, ачык. Мәзһәбләрнең серләрен аның дәрәҗәсендә белгән кешеләрне хәзерге көндә дә сирәк очратасың. Болардан чыгып бу фикергә килми мөмкин түгел: «Мәликә китабы» дөньяны һәм ахирәтне танытып белдерә торган дини-фәлсәфи тәгълиматны халык хәтеренә салу максаты белән язылган. Әгәр дә автор башка юлны сайласа, эшенең ахыры китабына һәм үзенә рәсми дини даирәләрдән бәддога ирешү белән тәмамланыр иде. Ә әсәр XIX гасырның беренче яртысыннан инде басма китап рәвешендә бастырылып таратыла башлагач, эчтәлегендә нәрсә ятканлыгын төшенгән-белгән кешеләр өчен ул халык әдәбияты ядкәре буларак күзалланган, укучыны эчтәлеге белән сокландырган, ә фикерләрен, бирелгән сорау-җавапларның мәгънәләрен бәяләргә теләүчеләр табылмаган.

## II

«Мәликә китабы»ның эчтәлеге һәм төзелеше гади. Аның төп өлеше сораулар һәм җавап бирүләр, шул җавапларга Мәликәнең соклануын хәбәр итү урыннарыннан гыйбарәт. Мондый форма әсәрнең схоластикага корылуын «оныттыра». Бирелгән сораулар һәм аларга дөрес, тапкыр җаваплар, никадәр коры булмасыннар, дөреслекләре белән мавыктыру, могҗиза тудыру көченә ияләр. Инде бер-бер сорау җавапсыз калыр, яки ризасызлык тудырыр, дисең. Әмма ялгышасың. Сораулар да, җаваплар да үзара тапкырлыкта ярыша башлыйлар. Җавапның дөрес булуы гына аз авторга, соравы да хикмәтле булсын. Менә шул сорауның, яисә җавапның мәгънәви тирәнлеге тагын да бер мавыктыргыч рольне башкара. Мондый хәл әсәрнең башыннан

ахырынача дәвам итә. Дөрес, ул сорауларның тапкырлыгын, җавапларның хикмәтле булуын аңлар өчен укучының үзендә шактый яхшы белемнәр туплануы шарт икәнлеген дә онытырга ярамый. Бу рәвешле сорау-җавап формасына өстенлек биреп язылган әсәр әлбәттә укучының үзеннән дә тапкырлык таләп итә. Әсәр шушы ягы белән дә мавыктыра.

Кызыклы якларның тагын да берсе шунда – сорау-җавап бәхәскә әверелдерелми, хәтта дәлилләр дә күпчелек урында сорау бирүче ягыннан таләп ителми. Әмма, дәлилләр соралганда, менә-менә бәхәс башланып китәрдер сыман тойгы тудырыла. Әсәр шулай төзелгән: укучы да җавапларны хакыйкать буларак кабул итә.

Ул сорау-җавапларны тематик яктан 22 төрле төркемчәгә төркемләргә мөмкин. Шулай иткәндә әсәрнең эчтәлеге яхшырак ачыла һәм аңлашыла башлый. Аларны аерым бүлекчәләр итеп аерымлау да уңышлы.

Әсәр «Равилар мондаг риваять кылдылар кем, Рум шәһәрендә Мәлик дигән бер падишаһ бар ирде. Угылы-кызы юк ирде...» (ягъни, «Вакыйгаларны сөйләүчеләр мондый риваять сөйләделәр: Рум [Византия] шәһәрендә Мәлик дип аталган бер падишаһ бар иде. Улы-кызы юк иде...») дип, әкияти мотивта башланып китә. Монда «мәлик» сүзе исемне түгел, бәлки титулны белдерә дип тә аңларга мөмкинлек бар, ягъни «император аталган бер падишаһ бар иде» рәвешендә.

Тагын да шунысына игътибар итми мөмкин түгел: әсәрдә хөкемдар «хан» дип түгел, бәлки «падишаһ» дип күрсәтелә. XIX йөз ахырында, бигрәк тә XX гасыр башында һәм хәзерге әдәбиятыбызда авторлар аны «патша» дип язарлар иде. Татарда «падишаһ» термины Рәсәй дәверендә активлаша, ул «рус патшасы» тезмәсендә, «рус падишаһы» формасында кулланыла. Дөрес, әкиятләребездә «хан» да бар, «татар патшасы» да очрый. Әмма Рум императорын бездә «падишаһ» дип атау борынгыдан бар. Әсәрдә бу традициягә игътибар бирелү кызыклы. Моның сәбәбе яки аның борынгыда язылуына бәйле, яки инде тарих гыйлемендә маһир әдипнең эше бу. Әмма беренче гипотеза ышанычлырак сыман, андый фараз дөрескә якын кебек: ягъни, Рум иле белән бәйле булганлыктан хөкемдар «хан» дип түгел, «падишаһ» рәвешендә аталган.

Әсәрнең мондый башлангычы бер үк вакытта әкияти дә, тарихи хакыйкать тә кебек аңлашыла: кайчандыр кемдер булган, аның балалары юк икән. Һәм менә Мәлик шул мәсьәләдә сагыш эчәргә, кайгыга төшәргә мәҗбүр.

Шулай итеп, «Мәликә китабы» беренче җөмләләреннән үк укучының күңелен кузгата һәм зиһенен мавыктырып өлгерә. Моның ахыры әлбәттә могҗиза булырга тиеш. Әмма Мәлик аңа ничек ирешә? Баласы туамы? Әллә Мәлик ул мәсьәләне чишәр хәлдә түгелме? Бу сораулар укучы күңелендә туарга һәм аны алга таба әсәрне кызыксынып укуга ымсынды-

рырга тиеш. Мондый типтагы әдәби әсәрнең хикмәте әлбәттә мажарада, әмма мажара могҗизасыз була алмый.

Мәлик, Кәгъбәгә барып, кырык тивә (дөя) корбан итә һәм Аллаһы тәгаләдән бала бирүен сорап үтенә, ягъни дога кыла. Әсәрдә «дога кылды» дип түгел, бу гамәл «хаҗәт теләде» рәвешендә бирелә. Аны хәзерге әдәби телебездә «хаҗәте үтәлүен теләде» дип аңларга тиешбез. Бу факт исә, беренчедән, «Мәликә китабы» иҗат ителгән дәвердә әдәби телебезнең җитәрлек дәрәҗәдә эшләнелмәгәнлеген, ягъни әсәрнең чынлыкта шактый иске булуын сөйләсә, икенчедән, татар теленең ул вакытларда шактый үзенчәлекле, сүзләрне сайлап алу һәм куллануда да аерылып торуы хакында белдерә.

«Аллаһы тәгалә догасыны кабул кылды, бер кыз бала бирде» дигән җөмлә аннары килеп, аның хәзерге әдәби телебездә дә үзгәрешсез сакланып, шушы ук формада кулланылуы гаҗәпкә калдыра. Текстларны өйрәнгәндә мондый фактларга аерым игътибар бирергә кирәк. Алар әдәби телебезнең грамматик формаларны сайлап алу юлын күрергә, тарихын төшенергә ярдәм итәләр. Бертөрлеләре гайре табигый төзелештә, икенчеләре – хәзер дә телебезгә грамматик яктан туры килеп торалар.

Кызның исемен «Мәликә» дип куялар. Әсәрдә «атыны» (ягъни, «исемен») дип язылган. Димәк, инде хәзер төгәл ачыклый алабыз: әсәрдә бу хәл «Мәлик» дигәндә – «император», «Мәликә» дигәндә «императрица» күздә тотылганнан булып чыкмый. «Мәлик» – хөкемдарның, «Мәликә» – аның кызының исемнәре икән.

Кыз акыллы, зирәк, яхшылык-күркәмлек иясе булып үсә. Әсәрдә аның укымышлыгына аерым игътибар бирелә һәм ул шәһәрдә Мәликәдән гайре башка андый гыйлем иясе юклыгы текстта махсус искәртелә.

Кызны укырга муллага бирәләр – монысы инде саф татар күзаллавында гына туа ала. Мулланы бөтен гыйлемнәрдә дә маһир буларак бездә генә белгәннәр. Мәликә дә «җәмигъ [барча] гыйлемнәрдин өлеш ала».

Әсәрдә кызның киң белемле булуы, ул гына да түгел, һәммәләрдән дә шушы ягы белән өстенлеге мәгърифәтчелек идеалларына бәйле тасвирлаудан дип аңлату урынсыз, әлбәттә. Хикмәт гыйлемле кешенең тормыш-яшәешне үзгәртүен ачыклауда түгел, бәлки каһарманның акыл һәм зирәклек иясе булуын конкретлаштыра төшеп сурәтләүгә бәйле. Хатын-кызның гыйлемдә ир-егетләрдән һич тә ким түгеллеген сиздереп алу да тарихи яктан әһәмиятле.

Шушылар белән әсәрнең беренче өлеше тәмамлана. Аны экспозиция буларак карарга кирәк. Әмма автор төп вакыйгалар бәяненә күчми, әсәрдә яңа экспозиция өлеше бирелә. Шулай итеп башлам өлеше башка юнәлеш ала, көтелмәгәнчәрәк дәвам итә, хәтта катлауланып та китә, геройларның булачак вакыйгалардагы позицияләре үзгәртелеп, сюжетның реэкспозициясе тудырыла.

Бу реэкспозиция «Мәликә китабы»на яңартылган башлам бирә. Мондый алым укучыны җәлеп итү көчен арттыра, әсәргә өстәмә мавыктыру, сюжетка көтелмәгәнлек көче бирә. Вакыйгаларның сурәтләнеше «Көннәрдән беркөн...» дип башланып китә. Падишаһның бердәнбер кызы бар икән. Шушы кызын кияүгә бирергәме-юкмы икәнлеген белешеп, сорау белән Пәйгамбәре Ходага (ягъни Аллаһының пәйгамбәренә) илчесен җибәрә ул. Сүз, әлбәттә, Мөхәммәд пәйгамбәр хакында бара икәнлеге дип аңлашыла. Шушы рәвешле вакыт һәм урын күзаллана, әмма хронотопта буталыш та ясала. Әмма аны укучы сизми. Рум падишаһы, чынлыкта, берничек тә мөселман булмаганы кебек, Мөхәммәд пәйгамбәр чорында муллалар да юк. «Мулла» сүзенең төректә кулланылган «мәүланә»не (суфи-диндар мәүлави берләшмәләре XIйөздә генә туа башлыйлар) татарда, тел табигатенә бәйле рәвештә кыскартып, ягъни редукцияләү юлы белән ясалуын да (мәсәлән, Мөхәммәд исемен кыскартып бездә «Мөхи», яисә «Мамай», йә инде Мөхәммәдҗанны «Мокамай» дигән кебек) искәртергә тиешбез. Динилек тә, суфичылык та, гыйлем-хикмәт иясе булуы да һичшиксез исәпкә алына. Дөрес, XXйөз татар әдәбияты тарихы фәнендә «мулла» сүзенә «менла»ны каршы куеп, «менла»ны «укымышлы кеше» мәгънәсенә ия буларак аңлату яшәде. Асылда алар икесе дә бер үк «мулла» дигән сүз генә, югыйсә. Фонетик вариантлардан гына гыйбарәт, «Тәрҗеман» газетасы (1883–1914) теленә хас үзенчәлек. Аларның мәгънәләре дә бер үк. Бүгенге көндә дә җирле сөйләшләрдә «менла» да, «мулла» варианты да кулланыла.

Мулла сүзенә бәйле XIXйөз төрек галиме Шәмсетдин Саминең «Камусы-төрки» китабында («Икенче җильд») «мулла» сүзенә бәйле мондый мәкалә бирелгән: «**Мулла** } яхуд **Менла** [гар. «Мәүланә»дә] 1. Мәүлият сахибе, бөек казый: *Мәккә, Мисыр мулласы*, 2. Мәүлият пайәсендә булынан зат[1], 3. Бөек галим, хуҗа[2]: *Мулла Җами = Мәүланә Җами*; *Менлаи Рум = Мәүланә Җәлалетдин Руми*, 4. Голуме динийә вә аләйһи талибы[3]; талибәи голумнән улан[4]: *Кәл, бакалым, мулла, менла[5]// Мулла бәк = риҗале гыйльмия[6], асыл зат кәнендә итълак улыныр[7]»*[8]. «Мулла» сүзенә үзенең «Асар» хезмәтендә Риза Фәхретдинов та туктала, аның гарәп сүзе «мәүланә»дән алынуын, сөйләмдә «мулла» яки «дамилла» әйтелешендә кулланылуын, язмада да соңрак «мулла» булып китүен аңлата[9].

1. Мәүлият пайәсендә булынан зат – мәүланә хезмәтендә булган кеше.
2. Хуҗа – ишан, мөритләр җитәкчесе.
3. Голуме динийә вә аләйһи талибы – дин галимнәре һәм аларның шәкертләре.
– Татар токымлы атларны 2010 елда туплый башладым. Аңа хәтле биш ел чамасы, бу эшне ничегрәк оештырырга икән, дип уйлап йөрдем. Авылда әби-бабай белән үссәм дә, әүвәл авыл хуҗалыгында эшләрмен дип уйламаган идем. Техникум тәмамлап, нефтьче булып киттем. Себердә эшләдем. Армиядә хезмәт итеп, старшина булып кайттым. Кайткач геофизиклар янына эшкә урнаштым да, анда геофизиклар төркеменә җитәкчелек иттем. 1991–92 елларда җәмгыятебездә үзгәрешләр башланды. Энекәшем Фәнис тә минем белән Себердә эшләп йөргән иде. Әлеге үзгәрешләр башлангач, энекәшкә, якын иткән егетләргә, хәзер безнең хакта дәүләт кайгыртмаячак, инде хәзер нишлик, үз-үзебезгә ышанып эш йөртсәк кенә отылмаячакбыз, дип әйттем. Нефть геофизикасы берләшмәсе каршындагы яшьләрнең фәнни-иҗади оешмасын да җитәкләгән, комсомол оешмасы башлыгы да булып торган вакыт бу. Алга таба үсеш юллары шәйләнмәгәч, бу тармактан китәргә булдым. Гаилә дә корырга, алга таба ничегрәк яшәргә дип бик нык эзләнгән чаклар иде бу.

***– Атчылыкка алынуыңа күпмедер дәрәҗәдә Бәзертиновның йогынтысы булган дип беләм.***

– Әйе, ул зур этәргеч бирде. Аңа хөрмәтем зур. Китапларын да укыганым бар. Гомумән, атчылык белән шөгыльләнә башлаганчы төрле-төрле эшкуарлыкка алынып карадым. Тик аларның берсе дә күңелемә ятып бетмәде. Инде атларга килсәк, татар күңеленә, холкына бик якын бит бахбайлар. Зиннәт бабам да ат асраган. Гомумән, Карабаш атлары 1812 елгы сугышта да, Беренче һәм Икенче Бөтендөнья сугышларында да катнаш-

кан. Шактые атка атланып сугышка киткән. Хәтта сугыш вакытында төрек кызларын килен итеп алып кайтканары да байтак булган. Һәрхәлдә авылыбызда шундый 7–8 нәсел билгеле.

Ир-атлар кайтса да, атлар кире әйләнеп кайтмаган. Соңгы Карабаш атларын авылыбыздан 1943 елны алып китүләре билгеле. Сугыш беткәч, безгә Орлов токымлы юртакларны, авыр йөк атларын, башка төрле атларны китерә башлаганнар. Эзләнә торгач, мин Самара губернасында нәшер ителә торган «Самарский вестник» газетасының 1867 елгы санында Бөгелмәдә базар булуы, анда атларның күпләп сатылуы турында укыдым. Әйтик, бабайның атасы Гариф бабайда өч ат, ике сыер булган. Биш баласы үскән. Менә миндә дә биш бала. Энем Фәниснең әле дүртәү генә, насыйп булса, аның да бишәү булыр. Власть үзгәрә башлагач, кулаклар исемлегенә язачакларын чамалап ала бабам. Бер атын сатып җибәрә. Улын – Зиннәт бабайны күрше кызына өйләндереп, башка чыгара, аңа бер атын, бер сыерын бирә. Бер аты, бер сыеры гына булгач, аңа тимиләр. «Бу власть, система озакка килә. Аңа каршы көрәшеп, сугышып йөрүдән мәгънә юк», – дип әйтә ул балаларына. 1991 елны да яңа система килде. Менә хәзер дә система алышыныргa тора. Байлыгы, акчасы булганнар кабат милексез калырга мөмкин.

***– Нindiрәк үзгәрешләр булачагын тәгаенрәк әйтә алмыйсызмы?***

– Мин күрәзәче түгел, әмма тормышлар үзгәрәчәген тоям. Яшибез бит әле, күрербез. Бүгенге сәясәткә нindiдер үзгәртүләр кермичә калмаячаклар. Кечкенә вакытта Зиннәт бабай безне – энекәшем белән мине Бөгелмә базарына алып бара иде. Анда кыяр саталар. Кыярны татарлар – Карабаш һәм Мортаза авылы кешеләре үстерә иде. Бөгелмә тирәсендәге авылларда торучы урыслар ул вакытта кыяр үстермәде. Шушы ике авыл халкы тәэмин итте. Кыярны сатарга кирәк. Шунда бабабыз юриме, малайлар сату эшенә өйрәнә башласыннар дип махсусмы, нindiдер йомыш табып, каядыр китә. Карабашта кыяр үстерү, сату – гадәти эш иде. 80 еллар җиткәч, авыллар таркала, шәһәрләр үсәчәк дигән шаукым чыкты. Шул рәвешле авылда яшьләр калмый башлады, калганы да нефть тармагына эшкә керде. Шулай итеп кыяр үстерү дә онытылды. Хәер, базарда сату да тыела иде. Хәтерлисездер: көнбагыш сатучылар да – Пенза татарлары! Менә хәзер алар – иң актив эшкуарлар. Хәзер көнбагышны Европа илләренә дә саталар. Менә безнең янәшәдә генә Башкортстанның Туймазы районы бар. Кыяр, помидор үстерү анда сакланды. Безнекеләр «озын берлек» артыннан Себер нефтен үзләштерергә китте. Шушылай гореф-гадәт, яшәү рәвеше бозыла башлады. Дәүләткә дә, халыкка да бәйле бу. Югыйсә, халык ялланып эшләүчегә әйләнә бит. Моны аңлаучылар аз булды. Ходай Тәгаләнең ымы, җир тартуы булгандырмы: шушы хәлгә

төшенә башлагач, атчылык белән шөгыльләнә башларга вакыт дигән фикергә килдем. Рафаэль Бәзертинов белән аралашуның да нәтиҗәсе булгандыр, билгеле. Бөгелмә базарында атларның күпләп сатылганын гына түгел, төбәгебездә шанлы ат бәйгеләре оештырылганын да бу эшчәнлеккә ныклап керешкәч, атларга, атчылыкка кагылышлы мәгълүматларны бөртекләп җыя башлагач кына белдем мин.

### Ир канаты ат булыр

***– Беренче атыңны кайдан алып кайттың?***

– Башкортстаннан. Хет Чиләбе, Курган, Башкортстан ягы булсын, гел татар авылларыннан таптым мин үз атларыбызны. Шагыйрь Сириннең «Чаптар атың, атлан атың» дигән язмасын укырга туры килде. Чаптар дигән сүз безнең халыкта төсне дә аңлата икән. Башкорт авылларында йөргәндә шундый хәлгә юлыктым: татарлар суяр өчен елкы сатып алырга дип килсә, ни өчендер чаптар төслене алырга теләми, дип сөйлиләр миңа. Үз атыбызны суярга кул бармый, дип аңлыйм мин бу хәлне. Күрәсең, кан хәтере бу. Ничек табигатьтә бөтенесе көйләнгән! Менә шулай әкренләп җыела башлады татар атлары. Татар атлы булсын – бу бит инде хыял! Акча китерерме бу эш, дип башта уйланмадым да. Менә быелгы җәйне алыйк әле. Хәзер күп кенә зур агрофирмалар хәлсез, акчасыз утыра. Республикабызда яхшы гына уңыш җыеп алсак та, бөртеклеләрнең бәясе түбән. Сатып алучы юк. Бодайның бер килосын биш сумга да сатып булмый. Солыны 3-3,5әр сумнан саталар. Аны черетеп яткызыргамы, малга ашатыргамы? Ашатыйм дисә, малы азрак. Ел карлы буламы-юкмы безнең якта кар аз яуды менә. Безгә киләләр, атларыбызны сатып алалар. Малкайларларыбыз тау битләрендә, ерганакларда тибенеп ашый. Бу вәзгыятьтән әле без җиңелрәк чыгып барабыз. Без сату өчен түгел, үзебезгә җитәрлек кенә чәчәбез, күпьеллык үлән дә үстерәбез. Гомумән, безнең көньяк-көнчыгыш – ат үрчетә торган як. Әле йөз ел кенә бу якларда атларны йөзәрләп, меңәрләп тотканнар. Әйтик, Зәй-Каратай авылында ике мең ат асраучы кеше булган. Ул Оренбур, Казакъстан тарафларында да атчылык белән шөгыльләнгән, ат өерләре тоткан.

***– Бер очрашкан вакытта, инкыйлабка хәтле Бөгелмәдә чәйханәләр күп булган, аларның барысын да татарлар тоткан, дип сөйләгән идең. Хәзер шәһәрләребездә татар гаиләләре тотучы кафе-ашханәләр юк диярлек аз. Кечкенә кафеларны ачучылар нигездә үзбәкләр, таҗиклар. Сәбәбе нәрсәдә икән?***

– Татар шәһәрләре, шул исәптән шәһәр культурасы бетерелгәч, мондый эшне халкыбыз оныта башлаган. Ни дисәң дә, үзбәк, таҗиклар үз туган җирләрендә күпчелек булганга һәм шәһәрләрдә күпләп яшәгәнгә бу эш аларга чит-ят түгел. Икенчедән, Бөгелмәдә ул вакытта татар мо-

хите булган, димәк. Хәер, Казанда да татар ашханәләре булган һәм, билгеле, татарлар аны үз күргән, якын иткән. Үз мәхәлләсендәге чәйханәгә өстенлек биргән. Хәзер, мәхәллә системасы, гомумән, шәһәрләрдәге татар бистәләре калмады диярлек. Өченчедән, читтән килгән кешеләргә тиз арада, көнендә акча китерүче тармак-юнәлеш ул – кафе-ашханәләр ачу. Шушы яңа мохиттә үз урыныңны табу, тамыр җибәрү өчен моннан да яхшырак, җайлырак, төшемлерәк урын табып та булмыйдыр, мөгаен. Бүген пешердең, саттың – шундук акча керде! Ат үстерергә теләсәң – кимендә өч ел, сөт өчен сыер үрчетергә ниятләсән, кимендә ике ел кирәк. Яшелчә үстерергә уйласаң язын, җәен, көзен теплицада мәш киләсең. Ә менә әзәриләр хәзер башка юнәлешләрне дә үзләштерә башлады. Хәер, базарларда да (ул да көнендә акча бирә торган урын) сату итүчеләрнең күбесе – Урта Азия халкы, әзәриләр. Хәл алгач, баегач, башка юнәлешләрдә дә эш йөртә башлый алар.

Шул ук вакытта акчалы татарларыбыз, эшкуарларыбыз шактый күп хәзер. Әмма акча бүген бар, иртәгә булмаска мөмкин. Шуның өчен озакка исәпләнгән эшләргә, традицион, үз халкыбызга хас булган җитештерү тармакларына акча кертергә кирәк. Һич кенә дә кемнең аты бар, шул исән калачак дип әйтүем түгел. Татар табынында борын-борыннан табигый, гадәти булган ризыкларны куллануга кайтырга вакыт. Елкы ите, казылыктан тыш, каз ите, катык, бавырсак та булырга тиеш өстәлебездә. Туклану системасы дигәннән. Кымызга әле һаман үгисетеп карыйбыз. Ни өчен елкы ите, кымыз дим. Болыннарда иркенләп йөргәнгәме, аның мае тиз үзләштерелә. Елкы мае утыз сигез градуста эри. Сарык мае җитмеш градуста гына эри. Аны эшкәртү өчен ашказанына күпме көч түгәргә кирәк?! Бия, ишәк һәм хатын-кыз сөтенең структурасы бер төсле икән. Анда албумин дигән матдә өстенлек итә. Ә сыер, кәҗә, сарык сөтендә козеин күп. Җилем кебек матдә бу. Кеше олыгая-олыгая сөтне ни өчен азрак куллана? Чөнки сыер сөтендәге әлеге бактерияләр җыела-җыела тромбоз китереп чыгара икән. Сыер сөте әлеге бактерияләрнең колония булып берләшүенә ярдәм итә. Менә ни өчен хәзер халыкта инсульт, инфаркт очраклары артты. Кеше даими кымыз эчә икән, ул кан тамырларындагы бактерияләрне ышкып-ышкып дигәндәй юкка чыгарып тора. Мәсүфә әбиебез: «Сугышка тикле Карабашта да сөт бияләре бар иде», – дип сөйли иде. Хатын-кыз бала тапкач, сөте югалса, шул балаларга бия сөтен бирә торган булганнар. Андый балалар исән калган. Беренче, икенче айда сыер, кәҗә сөте имсә, сабый үлә. Моны белүчеләр хәзер сирәк. Безнең бу эшебезне – татар токымлы атларны үрчетә башлавыбызны беренче булып күреп алучы, хуплаучы Ринат әфәнде Закиров булды. Татар конгрессы оештырган эшкуарлар җыеннарында атчылыкны пропаган-

даларга шушылай юл ачылды. Хәзер Россиядә, Казакъстанда елкы асраучы татарларыбыз бик күп. Бөтендөнья Татар конгрессы Милли Шурасы башлыгы Васил әфәнде Шәйхразиев ике тапкыр ат бәйгесендә катнашып, үзе җайдак булып узышты. Авыл хуҗалыгы министры Марат әфәнде Әхмәтов тә татарга атның кирәген яхшы аңлый. Кырлайда ат көнен ачуда үзе катнашты. Сентябрь ахыры, октябрь башында менә берничә ел үткәрелә инде ул. Без үзебез ат бәйгесен яз көне уздырабыз. Бу ярыш җиргә орлык кергән вакытта, Сабантуй вакытында оештырылырга тиеш дип уйлыйм мин үзем. Без аны өч мәртәбә уздырдырдык инде. Алла боерса, быел дүртенче мәртәбә үткәреләчәк. Без башта биш, ун, унбиш чакрымга узыштыра идек. Быел татар токымлы атларны егерме чакырымга чаптырачакбыз. Заманында Бөгелмәдә илле чакырымга чаптырганнар. Бер якка – егерме биш, икенче якка егерме биш чакырым.

**Чаба атлар, оча-чәчри күбекләр...**

***– Бу бәйге ничегрәк уздырыла?***

– Безгә төрле районнардан киләләр. Татар токымын аерым чаптырабыз. Аның бүләкләре дә аерым. Калган токымнар да аерым узыштырыла. Сабантуйларда да татар атлары катнашырга, аерым чаптырылырга тиеш. Шушындый дистәдән артык ярыш булды инде.

***– Хәзер сездә күпме татар аты бар? Татар атын үрчетәсебез килә дип, төрле төбәкләрдән сатып алырга киләләрме?***

– Хәзерге вакытта өч йөз атым бар. Киләләр, алалар. Кем – ике, кем өч ат ала. Айгырын булса да сат әле, диләр. Бияләрне без әллә ни сатмыйбыз. Әле күптән түгел генә нугайлар минем белән элемтәгә керде. Рафаэль Бәзертиновтан алганнар икән минем телефон номерын. «Без дә хәзер нугай токымын тергезергә уйлыйбыз. Без бит – бер халык», – ди алар. Чынлап та, шулай. Заманында безнең яклар Нугай урдасына кергән ич. Алар юрга атларны үрчетмәкче. Бу эш – әле безнең планда гына. Юртак урысча әйткәндә рысак була. Юрга исә иноходец, ягъни чапканда алгы, арты тояклары бергә ташлана. Алай ат та, җайдак та армый, тирбәлеп кенә бара, йөз чакырымны да җиңелчә генә уза ул. Нугайлар менә шундый атларны үсерүгә алынган. Башкортлар, әй, кара юрга, дип җыр сузганда, шул атларны күздә тота инде. Үз вакытында алар да аерым чаптырылган. Бездә дә юрга атлар булырга тиеш. Планнар зур. Ярый әле җитәкчеләр аңлый. Генетика буенча безнең ветеринария академиясе зур эш алып барды. Бу эшкә Равил ага Хәеретдинов күзәтчелек итте, рәхмәт яусын аңа!

Әле тагын шундый ният бар. Үз төбәкләреннән Болгарда Ислам дине кабул итү көнен бәйрәм иткән вакытка, Изге Болгар җыенына килеп җитәрлек итеп ат бәйрәме оештырырга исәп. Егерме ат буламы, ике йөз атмы – районнарыннан чыгалар да, ике-өч, дүрт көннәнме Болгарга ки-

леп җитәләр! Мондый атларны гади кешеләр, үз өендә мал тотучылар да асрый ала бит. Әлеге атларны тоту өчен күп чыгым таләп ителми. Шуңа күрә тора-бара татар токымлы атлар шактый күбәер дип ышанам мин. Билгеле, моның өчен ат асрау культурасы да булырга тиеш. Кара бу атның хуҗасы юк икән, кырда берүзе тибенеп ашап йөри дип, атып алып китүләре дә бар, Алла сакласын! Менә безнең Карабашта кашлак дигән урын бар. Элек маллар шунда кыш чыга торган булган.

Ат үрчетү, ат тоту – гореф-гадәтләребезне, дәрт-көчебезне кире кайтару да ул. Атка атланып чапкан кеше нәкъ бабаларыбыз кебек рухлана, дәртләнә. Милләтне яшәтү өчен милли мохит кирәк. Милли мохит – туган телең, бәйрәмнәрең генә түгел, халкыбыз элек-электән асраган хайваннар, күнеккән киемнәр, ашамлык-эчемлекләр дә ул. Шул эчтәлеге булса, тышта да милли яшәешең гәүдәләнәчәк. Милли мохитне эзләргә түгел, үзебезгә булдырырга, онытылганнарны тергезергә кирәк. Инглизләрнең бу гадәте ошый, урысларның теге гадәте дип, башкаларга ияргә башласаң, интернетка кереп «чумсаң», виртуаль дөньяда яши башлаячаксың.

***– Халкыбыз нигә һаман җиргә кайтып җитә алмый? Ни сәбәпле авыл җирендә эшкуарлык белән шөгыльләнүчеләребез аз?***

– Мондый эшләрне башлаганда керем булмаска да мөмкин. Кеше башта тәҗрибә туплый. Үзен шәхес дип хис иткән адәм баласы бу җирдә яшәвемнең максаты нидә икән дип тирән фикер йөртә. Шул рәвешле олы эшләргә алынырга кирәк дигән нәтиҗәгә килә. Әгәр акчага гына ябышып ятса, бу эш файда китерерме икән дип озак баш ватса, кеше ваклана, тирәнлеген югалта башлый. Элекке данызбызны кайтарыйк дисәк, югала башлаган, безне милләт итеп тоткан, борынгыдан килгән хасиятләребезне берәм-берәм тергезергә тиешбез. Әйтик, туган телебезне балаларга сабый чагында ук бишек көй-җырлары итеп сеңдерергә кирәк. Ниндидер сәбәпләр аркасында милли мохиттән аерыла башласа да, мәсәлән, урыс балалар бакчасына йөрсә, урыс мәктәбендә укыса да, ул көйләр ана сөте белән бергә аның җанына сеңеп кала. Шул бишекнең үзен дә тормышыбызга, яшәешебезгә кайтарырга, бишек җырларын күпмедер яңартырга, яңаларын да иҗат итәргә кирәк.

Шулай кеше Сабантуйларга, ат чабышларына йөри башлый. Менә минем гаиләдә малайның башта атка исе китмәде. Институтны тәмамлагач, ярдәм итәргә ешрак чакыра башладым. Хәзер менә үзе мавыгып китте, бик кирәкле эш икәнлеген аңлады. Инде аннан күреп атлар янына башка яшьләр дә тартыла. Лениногорскидан, Карабаштан, күрше авыллардан киләләр. Бүген унбишләп яшь кеше, даими килеп, ат янында кайнаша. Шунысы кызык: аларның күбесе – кызлар. Ярышта катнашучылар да – шулар. Аларның тренерлары да юк. Улым Самат алардан 4–5 яшькә олы-

рак булгач, бераз юнәлеш бирә инде. Болар нигездә унөч, ундүрт, унбиш яшьлек үсмерләр. Интернетта булган сайтларында да бу шөгыльләрен даими тәфсилләп язып торалар. Балаларын ата-аналары үзләре китерә. Атта йөрергә ризалыгын бирә. Үзләре белән ашарга алып киләләр. Бездә туклану урыны бар. Теләгәннәр кунып та кала ала. Билгеле, бу – зур җаваплылык. Югыйсә, без бәләкәй чакларда беркемнән дә сорап тормый идек. Ат абзарына – бу гыйбарәнең борынгы вакытта бездә тәләкә дигән матур сүзе дә булган – менә идек тә, атларны сайлап алып, атланып йөри, өйрәтә идек. Ник монда буталып йөрисез дип, орышучы да юк иде. Дөрес, тибеп җибәрүе бар, атның артыннан килмә, дип кисәтүчеләр булды.

***– Балаларның «Сәләт» лагерен бәлкем синең ат ширкәте янында эшләтергәдер?***

– Бөгелмәдә «Сәләт» бар. Әмма нишләптер аларның атчылыкка исе китми. «Сәләт» лагерьларының һәрберсенең үз программасы бар. Дөрес, Җәүдәт абыйлары ат белән кызыксындырасы иде, дип гел әйтеп килә. Әмма озак җыеналар. Югыйсә, аларның лагере турыга бездән җиде-сигез чакырым ераклыкта гына урнашкан.

***– Чуашстан ягында, әйтик, Шыгырдан, Урмай, Тукай авылларында ике кешенең берсе – эшкуар. Берәү дә, авылда эш юк дип, аягын күтәреп ятмый. Авыллар таркалмый. Киресенчә, үсә, ныгый бара. Безнең Татарстанда ни өчендер һаман эш урыннары булдырылмый дип, кемнәрнедер гаепләү ягын карыйлар.***

– Безнең якта моның беренче сәбәбе нефть тармагының нык үсеш алуы дип уйлыйм. Сәгать сигезгә генә эшкә бара. Дүрттә эше дә бетә. Акчасы керә, нужаланасы юк. Вахта машинасы илтә, китереп куя. Безнең халыкка ялланып эшләүче психологиясе нык үтеп керде. Моны кол психологиясе дип тә әйтергә була. 20–25 мең сум түлиләр бит әле, нигә баш ватарга? Шушы рәвешле ялкаулык та керә. Үз эшеңне ачып, ялкау булсаң ачка үләсең. Әбиләр, бабайлар заманында шулай булган. Ялкау булганнар гаиләләре белән ачка үлгән. Бер туганыбызның шундый хәлне сөйләгәне бар. «Бер елны бик коры җәй килде. Шунда әтиебез һәрберебезгә капчык бирде. Барыгыз алабута башлары җыеп кайтыгыз, дип көн дә җыярга җибәрә иде. Көн саен бер капчык алабута җыярга тиешбез. Инәкәй белән бергә шуларның орлыгын уып, капчык-капчык тутырып кышка әзерләп калдырдык. Ачы булса да шуны кыш буе ашадык. Әткәйнең бер энекәшенең дә шулай ук ишле гаиләсе, балалары бар иде. «Нишләп балаларыңны алабута орлыгы җыярга йөртмисең?»,– дип әткәй энекәшенә еш әйтә торган булган. Тегеләр Совет властена ышанганнар, ач калдырмаслар, ярдәм итәрләр әле, дигәннәр. «Абый, менә ач утырабыз. Бернинди ярдәм дә юк.

Бер капчык бир инде»,– дип сорап килгән энекәше. Биргән. Ярдәм сорап икенче тапкыр да килгән. Тагын биргән. Монысында, апаем, бүтән килмә, бирмим, дигән. Шуннан соң ярдәм сорап берничә мәртәбә килгән, инде бүтән бирмәгән. Хатыны, үзе, бөтен балалары ачлыктан үлеп беткән. Әгәр әткәй шунда биргән булса, без дә үләр идек»,– дип сөйләде ул. Менә нинди хәтәр еллар булган. Менә хәзер карагыз: сөтнең хакы төште, итнең бәясе күтәрелми. Халык эшләргә яратмый. Эшләп интеккәнче, очсыз тавык итен ашап ятам, ди. Ул тавыкның нинди уколлар белән үстерелгәнен белми ул. Менә бу – коллык психологиясе инде. Әгәр авылда мал асрамый башласалар, халыкның кырылып бетүе бар. Халык эштән бизенде. Менә 12 яшьлек кыз. «Әти, мин быел ярышта катнашам», – ди. Шимбә-якшәмбе, каникулларда гел атлар янында. Менә дәртләнә, менә дәртләнә! Баланы үсендерү өчен күп кирәкми. Балам, булдырасың бит! Шәп чабасың! Ат та сине тыңлый бит, дип әйтү дә җитә кайчагында. Инде аның өйдә оеп компьютер каршында утырасы килми. Менә ун яшьлек кызым унбиш яшьлек апасы белән бергә һич курыкмыйча бия сауды. Кызым, кымыз тәмлеме, дип сорыйм. «Тәмле!» – ди. Кайчагында авыррак та була. «Торасым килми, ардым», – ди. Кызым, түз инде, барырга кирәк, дим. Баралар. Эшли башлагач, буыннар язылып китә.

**Егет булса, ут булсын! Ут булмаса, юк булын!**

***– Хәзер хезмәт тәрбиясе дигән нәрсә мәктәпләрдә дә онытылып бара бит.***

– Ни кызганыч, шулай. Эшләп үскән, яшьли чыныккан кеше тормышта югалып калмый. Әз генә нужа-авырлык күргәннәр барыбер кыенлыкларга каршы көрәшергә көч таба, бирешми. Шөкер, авырлыклар күреп тә сынмаган-сыгылмаганнар бар әле. Андыйлар кризистан чыга. Алар калмаса, халык нишләп бетәр – әйтүе кыен. Без үзебезне күп санлы халыклар белән түгел, аз санлы халыклар белән дә чагыштырыйк. Әйтик, балкар, карачай, нугайларга нишләргә? Кавказда эш юк. Йә Себергә акча эшләргә китәләр, йә үзләрендә элек булган традицион яшәешләренә кайталар, мал асрый башлыйлар. Әнә үзбәкләр монда эшли, гаиләсенә ай саен акчасын җибәреп тора. Моңарчы белми идем: Әфганстанда ярты миллионнан артык татар яши икән. Аларда ат өстендә килеш тартышу, ягъни күкпар дигән ярыш һаман югалмаган. Бу ярыш-уенның «улак» дигән атамасы да бар. Бу бәйге атка атланган ике төркемнең сарыкны тотып алып улакка беренче булып ташлавы өчен ярышуын аңлата. Күчмәннәр уены дип моны казакълар күтәреп алды, бу бәйге башкортларда, нугайларда да бар. Татарстанда түгел, Әфганстан татарларында сакланган. Безгә дә бу ярышны тергезергә иде. Егетләребез әзерме моңа? Юк! Әле моның өчен атларыбыз да җитеп бетми. Үзбәкстанда, Казакъстанда, Кы-

ргызстанда, Әфганстанда оештырылды инде бу бәйгеләр. Ел саен аның урыны алышынып тора. Менә башкортлар әлеге бәйгедә 2016 елдан катнаша башлады. Без кайчан башларбыз...

Ат янына күбрәк кызлар тартыла дидем. Ни гаҗәп: егетләр аз. Бу ни дигән сүз? Дәртле кызлар бар. Дәртле егетләр юк диярлек. Менә нәрсәдә хикмәт! Бу бит кызлар уены түгел, ир-егетләр уены. Атта йөрисе килә дип, безгә өч ел инде киләләр. Аларның туксан проценты – кызлар бит. Нигә кызларыбыз ят милләтләргә кияүгә чыга дип зарланабыз. Урыска гына түгел, шул ук казакъка, нугайга, үзбәккә дә килен булып төшә. Ни өчен? Чөнки аларда дәртле егетләр бар. Менә Фәнис белән мин көрәшеп үстек. Без бик дәртле идек. Шул дәрт безне хәзер дә йөртә. Бу бит көч сынашу, үзеңне күрсәтү. Әгәр поп-корн ашап, кока-кола эчеп ятсаң, корсагың үсә, көчең булмый. Нинди атка атлану ди ул?! Инде курку бар малайларда. Ни өчен? Алты яшендә беренче тапкыр атка атланмагач, инде уналтыда курка ул. Беренчедән, курка. Икенчедән, кызлар көләр дип уйлый. Әйдә, ничек атланырга кирәклеген үзем күрсәтәм, дип хәзер кызлар егетләрдән көлә. Элек бит шундый җыру да булган: ат тугарып җигә белми, кызлар сайлаган була... Хәзер нәкъ шушындый вәзгыять. Атка атланып ике-өч көн буе Болгарга баручы егетләр килеп чыкса, хатының да, менә безнең кызга яхшы кияү булачак бу, дип әйтәчәк. Әниләр яхшы белә: ныклы нәсел калдыру өчен, кызыңны яхшы, дәртле, гайрәтле нәселгә кияүгә бирергә кирәк. Шуңа күрә ул төпле егет күзли. Табигый сайланыш бу. Булдыклы егетне туксан яшьлек бабай да, унике яшьлек кыз да күрә.

***– Бу санкцияләр сезне куркытмады дип беләм.***

– Хәзер зур агрофирмалар батып бара, ә без яшибез. Әле көлеп йөрибез. Казанга килергә дә вакыт табабыз. Дөрес, Казан дисәк тә, мондый зур шәһәрләрдә яшәп кеше терәк-таянычын, табигать белән бәйләнешен югалта. Акча артыннан куып, адәм баласы еш кына ни өчен яшәгәнен дә онытa башлый. Шәҗәрәсе ике ятып бер төшенә дә керми. Агач үзенең тамырларын белмәсә, аннан су килми башлый. Әгәр шундый элемтә булмаса, агач чери. Нәсел дә шулай бетә. Ходай Тәгалә кешегә нәселен, милләтен, динен, телен биргән – көче шуңарда! Безнең табигать искиткеч бит. Үзәнлекләр, тугайлар, таулар да бар. Тауга менәсең: бөркетләр очканы күренә. Син дә бөркет бит. Син дә тауга мендең. Килеп күрүчеләр: «Сездә рәхәт, иркенлек, хозурлык!» – диләр. Хәрәкәтләнергә, гамәл кылырга кирәк.

## Нигез ташың исәнме?

***– Әле бервакыт, нигез ташларын, нигезне сакларга кирәк, шул безне саклап тора, дип әйткән идең.***

– Әлеге ташларны Зиннәт бабай әтисе Гариф белән икәүләп таудан куптарып, арбага салып алып кайткан. Нигез ташы дигән гыйбарәнең без татарда, оя дигән мәгънәсе дә бар. Ул ташларны һичшиксез сакларга кирәк. Кем үзенең нигезен ташлый-оныта, ул бабаларының көчен югалта. Аннары гомер буе шуны эзләп йөри ул. Елап йөри, үзенә урын таба алмый. Нигә шулай йөри, чөнки көчен югалткан. Кемдер, цивилизация килде, нәрсәгә бу миңа, җимереп ташлыйсы гына, нишлим бу ун-унбиш сутый җирдә, ди. Әмма пенсиягә чыккач кайтмакчы була, тик инде анда башкалар яши. Ярый әле үзебезнең татар булса, хәзер авылларыбызга башка милләт вәкилләре дә килеп урнаша, тамыр җәя башлады. Шәһәргә киткән кешенең нигездә калган гайрәте хәзер шуларга күчә. Хәзер алдану күп. Нигә миңа базар кирәк – кибет бар. Нигә миңа каядыр барып эшләргә? Хәзер интернетта утырып та акча эшләп була, бер кая чыгып йөрсе юк, интернет-кибет бар. Хәзер бөтен кеше интернетта гына утыра башласа, кем иген игәр? Халык шулай алдана. Үзе дә битарафка әйләнә, балалары сүлпән үсә. Шушылай яшәүнең кызыгы да югала. Әнә Европада бер җенесleләр гаилә кора башлады. Инде яшьләр бер-берсенә әшәке, тупас сүзләр әйтешүдә узыша башлады. Ялгышмасам, моны «батл» диләр. Кем-кемне ныграк батыра, чеметеп ала, пычрак түгә дип аңлыйм мин моны. Телевидение, интернет та моны тарату, ишәйтүгә үзеннән зур өлеш кертә.

***– Без моңа нәрсәне каршы куя алабыз соң?***

– Үзебезнең, төркиләрнең борынгы яшәешенә кайтып карасак, акыннарыбыз, чичәннәребез булган. Алар җыру чыгаруда, тапкырлыкта ярышкан. Әбиләребезнең мөнәҗәтләрен, бәетләрен искә төшерик. Болар – гади тормыштан алынган вакыйга-хәлләргә мөнәсәбәт белдерү, бәя бирү. Бу – бер-береңне батыру түгел, үстерү, башкалар хәленә керү, кайгы-хәсрәтләрне уртаклашу. Менә шулай хис уяна, көч барлыкка килә. Без татарлар да шушы батлга иярсәк, надан-ахмак булачакбыз. Безнең халык күп авырлыклар күрсә дә, мондый шикле гамәлләргә керешмәгән. Менә Рим империясе булган. Анда гладиаторларны сугыштырганнар. Шулай кеше сугыштырудан тәм тапканнар. Боксның да асылы шул ук. Ике кешене дөмбәсләштереп, цирк ясап, шуннан тәм-ләззәт табалар. Үз вакытында Әтилле бабабыз, менә шушылай язукка батып ятканнары өчен, римлеләрне буйсындырган, тез чүктергән. Чыңгыз хан да заманында үзара сугышып яткан урыс кенәзләрен буйсындырып, тәртипкә кертеп, Алтын Урданы корып куйган. Кагыйдәсе булмаган йодрык сугышлары да шулай ук бозыклык дип бәяләнергә тиеш. Әлеге уенны оештыручылар, катнашучылар – хәзерге заман гладиаторлары. Бу дөньяда бөтен җирдә кагыйдә-тәртип бар. Кеше тәртип юк дип әйтә икән, бернәрсә өчен дә җа-

вап бирми башлый. Болай дәвам итсә, кешелекнең юкка чыгуы бар. Менә безгә, татар халкына юкка чыкмас өчен мондый нәрсәләрне кабул итмәскә кирәк. Батлда да, кагыйдәсез йодрык сугышларында да татар егетләре катнашмасын. Катнашу гына түгел, андый чара-тамашаларга бармаска, аларны карамаска кирәк. Карамасак, аның үз арабызда таралуына юл куймаячакбыз дигән сүз. Моны яшьләргә генә түгел, өлкәннәргә дә аңлатырга иде. Шушы әшәкелекләр аша тормышыбызга шайтан керә.

***Әңгәмәдәшебез – Рәшит Минһаҗ***

## Төбәк тарихы буенча конференцияләр һәм очрашулар. Хатлар һәм кайтавазлар/ Краеведческие конференции и встречи. Письма и отклики.

*На последней встрече краеведов обсуждалась проблема доступности архивных материалов. Так как выяснились ряд трудностей в этой сфере, одним из участников обсуждений – Тахиром Абдурахмановым были сформулированы вопросы, имеющие общее значение. Имея ввиду важность этого вопроса, редакция приводит предложения данного краеведа.*

## ПРОБЛЕМЫ, С КОТОРЫМИ СТАЛКИВАЮТСЯ КРАЕВЕДЫ, РАБОТАЮЩИЕ В АРХИВАХ ТАТАРСТАНА:

1. Проблемы при выдаче метрических книг и ревизий. Данная проблема началась больше года назад, когда под предлогом оцифровывания ограничили доступ. За обещанный год оцифровано было очень мало, можно сказать почти ничего. И по окончанию года придумали новый способ – берут на заказ по два дела на сканирование и через только 15 рабочих дней выдают.

2. Фотографирование и копирование архивных документов очень дорогое.

Так как историей сел занимаются пенсионеры, учителя, историки которые ограничены в финансовых возможностях и порой делают все на свои средства отрывая это от семейного бюджета, тут надо что-то делать.

3. Архивисты часто не могут помочь в поиске материалов, плохо знают свои базы. Нет тематических справочников по поиску материала по истории деревень, отсутствуют рекомендации по поиску родословных.

Кроме того, ЕАИС создан на слабой платформе. Листать уже оцифрованые документы долго и тяжело.

4. Часто выдача дел зависит от личного отношения работников архива к краеведу.

5. Выдача дел производится через два дня, тогда как большинство тех, кто занимается историей деревень, не живут в Казани. И им приходится ездить туда-сюда. Надо пересмотреть сроки выдачи дел для иногородних. Что касается других региональных архивов, то иногородним, там выдают дела в этот же день или на следующий.

6. В соседнем Башкортостане оцифрованы ревизии и метрические книги, и они разосланы по районам и исследователям не приходится ездить в Уфу. Также исследователям занимающимся историей сел, созданы там благоприятные условия и выдают дела в тот же день.

## Төбәк тарихына караган хезмәтләр турында мәгълүмат. Рецензияләр/ Информация о краеведческих трудах. Рецензии.

# «РЕГИОНЫ КОМПАКТНОГО ПРОЖИВАНИЯ ТАТАР В РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ»: НАУЧНО-СПРАВОЧНОЕ ИЗДАНИЕ ИТЭР АН РТ

***Б.Л. Хамидуллин, Л.М. Айнутдинова***

***Аннотация:*** *В статье рассматриваются концептуальные основы первого тома научно справочного издания «Регионы компактного проживания татар в Российской Федерации», подготовленного в рамках государственной программы Республики Татарстан «Сохранение национальной идентичности татарского народа», и анализируется его содержание.*

***Ключевые слова:*** *татары, регионы Российской Федерации, районы компактного проживания, диаспора, научно-справочное издание.*

В 2016 г. в рамках выполнения государственной программы «Сохранение национальной идентичности татарского народа» коллективом Института татарской энциклопедии и регионоведения был подготовлен справочник «Регионы компактного проживания татар в Российской Федерации» [Регионы: 2016]. Основной целью проекта являлось написание комплексного научно справочного издания, отражающего общую картину расселения и современное состояния татарского народа в Российской Федерации. В рамках поставленной цели решался ряд задач: выявление мест компактного проживания татар в Российской Федерации; установление связей с представителями администраций и общественных организаций в местах компактного проживания татар в Российской Федерации с целью сбора информации; создание комплекса сведений о татарском народе за пределами Татарстана, его систематизация и аналитическая обработка; определение основных факторов сохранения национально культурной идентичности татар в иноэтничной среде, выявление общих тенденций, требующих внимания властных структур и изучения со стороны научного сообщества.

Татары – государствообразующий и второй по численности этнос в составе Российской Федерации [Татарстан: 2015. С. 688]. Они проживают на своей исторической родине в Поволжье и Приуралье, в Крыму и

Сибири, дисперсно – на всей территории России от Камчатки до Калининграда, а также в странах ближнего и дальнего зарубежья.

Татарская этническая общность, безусловно не являющаяся однородной генетически, монолитна в осознании своего единства, имеет очень сложную внутреннюю структуру. В академическом издании «Татары», подготовленном Институтом этнологии и антропологии Российской АН и Институтом истории АН Республики Татарстан, представлен один из возможных вариантов общетеоретического подхода к данному вопросу. В рамках единой татарской этнической общности ученые этнологи выделяют 2 нации (крымско татарскую и татарскую) и 2 этнические группы (буджакских и литовских татар), что напрямую связано с этнополитической историей татар золотоордынского и постордынского периодов, являвшихся ключевым этапом этногенеза всех современных татар [Татары: 2001. С. 14].

Общая численность татар в России по переписи 2010 г. – 5413 тыс. чел. (без учета крымских татар, которых, по разным оценкам, на сегодняшний день в России насчитывается около 300 тыс. чел.), в том числе 5310 тыс. поволжско приуральских татар [Татарстан: 2015. С. 688].

Татарская нация делится на этнотерриториальные группы астраханских, волго уральских (поволжско приуральских) и сибирских татар. У них единый литературный язык. Подавляющее большинство верующих татар – мусульмане сунниты.

Основное ядро татарского народа – поволжско приуральские татары – сформировалось на территории Среднего Поволжья и Южного Приуралья. В их состав входят субэтносы казанских татар, касимовских татар и татар мишарей, субконфессиональная общность крещеных татар (кряшен). Все они подразделяются на многочисленные этнографические группы, обычно имеющие минимальные этнографические особенности. В формировании этнокультурного облика волго уральских татар сыграли роль многие тюркские и финно угорские племена и народы – булгары, хазары, буртасы, мадьяры, огузы, кипчаки, ногайские татары и др. Заключительный этап консолидации волго уральских татар происходил в Золотой Орде и в образовавшихся после ее распада Казанском и Касимовском ханствах и Ногайской Орде. В конце XIX – начале XX в. на основе наиболее многочисленных поволжско приуральских татар сформировалась единая татарская нация.

Астраханские татары – коренное население Астраханской области Российской Федерации и сопредельных территорий. Они делятся на карагашей, кундровских и юртовских татар. В этническом формировании астраханских татар приняли участие приазовские болгары, хазары, пече-

неги, кипчаки, ногайские татары, кавказские и среднеазиатские тюрки и др. [Татарстан: 2015. С. 102]. В процессе консолидации астраханских татар определяющую роль сыграли Золотая Орда и образовавшиеся после ее распада Большая Орда, Астраханское ханство и Ногайская Орда. Большое влияние на этнокультурное развитие астраханских татар оказали поволжско приуральские татары, переселившиеся в XVII – начале XX в. в Астраханскую губернию. Во 2-й половине XIX – начале XX в. астраханские татары вместе с поволжско приуральскими и сибирскими татарами образовали единую татарскую нацию.

Сибирские татары – коренное население современных Новосибирской, Омской, Томской и Тюменской областей РФ. Они в свою очередь делятся на 3 этнографические группы – барабинскую, тоболо иртышскую и томскую. В формировании этнокультурного облика сибирских татар сыграли роль многие тюркские, финно угорские, самодийские, отчасти индоевропейские и монгольские племена и народы [Татарская: 2010. С. 313]. Процесс объединения сибирских татар происходил в Золотой Орде и в образовавшемся после ее распада Тюменском/Сибирском ханстве. Сильное влияние на их этническое развитие позднее оказали сибирские бухарцы и поволжско приуральские татары, мигрировавшие в конце XVI – начале XX в. в Сибирь. В XVII–XIX вв., в связи с освоением Сибири русскими, в расселении всех групп сибирских татар произошли существенные изменения. Во 2-й половине XIX – начале XX в. сибирские татары вместе с поволжско приуральскими и астраханскими татарами образовали единую татарскую нацию.

Крымско татарская нация – коренное население Крымского полуострова, исторически сформировавшееся в Северном Причерноморье. По оценочным данным, в настоящее время в РФ проживает около 300 тыс. крымских татар – большей частью в Республике Крым, а также в Краснодарском и Ставропольском краях. Компактные поселения крымских татар расположены в Болгарии, Румынии, Таджикистане, Турции.

Буджакские (добруджские, дунайские, румынские) татары – коренное население Молдавии, Румынии и Украины. Их численность не менее 25 тыс. чел. (в 2002 г. в Румынии проживали 24 тыс. чел.). Язык – близский к крымско-татарскому. По вероисповеданию в большинстве своем мусульмане сунниты.

Литовские (польско литовские, белорусские) татары – коренное население Белоруссии, Литвы и Польши. По данным за 1993 г. их общая численность составляла свыше 26 тыс. чел. Язык, в зависимости от территории проживания, белорусский, литовский либо польский. Верующие в основном мусульмане сунниты.

* * *

В силу ряда объективных обстоятельств в 1-м издании справочника мы ограничились информацией о районах компактного проживания только поволжско приуральских татар (без учета собственно Республики Татарстан, где по данным за 2010 г. проживали 2012 тыс. татар) [Татарстан: 2015. С. 7].

Статьи для справочника подготовлены в разрезе республик, краев, областей, автономных округов, районов, городских округов и городов. Всего в нем 380 статей: 45 обобщающих статей о регионах (29 областях, 9 республиках, 5 краях, а также о Москве и Санкт Петербурге), 2 – об автономных округах, 273 – о районах, 4 – о городских округах, 56 – о городах. В 45 охваченных справочником регионах по данным за 2010 г. проживали 3185920 татар.

Основной принцип построения справочника – региональный, статьи о 45 основных регионах компактного проживания татар в Российской Федерации расположены в справочнике в алфавитном порядке [Регионы: 2016. С. 332–333]. Регионы, где поволжско приуральские татары малочисленны и проживают максимально дисперсно, в данном справочнике не рассмотрены. Ввиду отсутствия официальных статистических сведений, не представлена в данном издании и Республика Крым.

Статьи в книге строятся по условной схеме, включающей следующие составляющие: название и статус административно территориального образования; географическое положение; площадь; общая численность населения и численность татар (по возможности в динамике – по годам переписи населения); места основного расселения татар с указанием численности; исторические сведения о времени и характере заселения татарами данной территории; информация о жизни татарской общины до 1917 г. (школы, мечети, медресе, культурно просветительские учреждения, печатные издания, промышленные и торговые предприятия, промыслы и т.д.) и в советский период; сведения о национально культурной жизни татар на современном этапе (количество татарских школ или школ, где татарский язык изучается как предмет; наличие национально культурных центров, других учреждений и организаций, ведущих работу с татарским населением; периодические издания, татарские самодеятельные коллективы, творческие союзы и т.д., по возможности с указанием местонахождения и года образования организаций и творческих коллективов); связи с Татарстаном; историко культурные памятники, связанные с татарами; знаменитые представители татарского народа, чья жизнь и деятельность связаны с территорией данного региона.

В рамках создания справочника была проведена большая исследовательская работа: фронтальный просмотр, систематизация и анализ источников, научной литературы и периодических изданий, в которых отражены сведения о татарской диаспоре (справочник снабжен списком литературы, насчитывающим около 600 наименований); анализ материалов интернет ресурсов; анализ статистических данных (помимо данных, полученных из регионов, каждая статья снабжена сведениями о количестве татар по данным переписей, что позволяет выявить динамику количественных изменений); посредством контактов с управлениями образования и культуры администраций регионов были получены данные о количестве школ в разрезе районов и городов за пределами РТ, где обучение ведется на татарском языке или он изучается как предмет, о работе самодеятельных организаций, а также ряд других сведений, отражающих национально культурную жизнь татар. В общей сложности в регионы было направлено более 500 запросов.

Хотелось бы отметить, что статьи справочника не всегда равнозначные, что во многом определяется отсутствием необходимых сведений из регионов. Многие статьи справочника и далее будут заполняться материалом по мере исследовательских возможностей.

Собранные в справочнике сведения позволили нам выявить некоторые тенденции. Так, для большинства изученных регионов характерно уменьшение численности татар в динамике по переписям населения 2002 и 2010 гг. Во многом это объясняется сокращением в целом численности населения в муниципальных образованиях. Характерной чертой большинства районов компактного проживания татар является заметное развитие национально культурной жизни. Полученные материалы свидетельствуют о том, что, как правило, она концентрируется вокруг национальных творческих коллективов, которые функционируют почти во всех изученных объектах. В большинстве случаев их наличие или отсутствие не зависит от численности татарского населения. Например, в Аларском районе Республики Саха (Якутия) при относительно небольшой численности татар (на 2010 г. – 509 чел.) действует Татарский культурный центр; в Атюрьевском районе Республики Мордовия (на 2010 г. – 589 чел.) функционирует татарский ансамбль «Умырзая». Большая часть татарских самодеятельных творческих коллективов была образована в конце 1980-х – 1990-е гг. – в период всплеска в стране интереса к национальной истории и культуре, в последние пять лет также наблюдается рост интереса населения к культуре своего народа, что отражается в увеличении количества самодеятельных организаций. В то же время функционирует большое число коллективов, возникших значительно раньше и работающих

в настоящее время, что является показателем устойчивого характера их деятельности. К примеру, в Артинском городском округе Свердловской области работают вокальный ансамбль «Нур» и народный театр, основанные в 1976 и 1977 гг. соответственно. Структурами, организующими национально культурную жизнь татарской диаспоры, являются также и татарские общественные центры, имеющиеся почти в каждом регионе. Однако в разрезе районов и небольших городов они есть далеко не в каждом из них.

Одним из главных компонентов национально культурной идентичности народа является родной язык. Помимо семьи, место его изучения и активного использования – учебные заведения. Анализ этого аспекта в жизни татар за пределами республики выявил определенную тенденцию, в рамках которой в настоящее время наблюдается сокращение количества школ, где татарский язык изучается в качестве предмета. Так, если в Артинском городском округе Свердловской области в 1999/2000 учебном году работали 4 школы, где татарский язык изучался как предмет, то по состоянию на 2015/2016 учебный год таковых осталось 2; перестали действовать 2 татарские школы в Алнашском районе Удмуртской Республики и т.д. В качестве официальной причины их закрытия, как правило, указывается малое число учащихся.

Важным фактором этнокультурного единения татар за пределами Татарстана стал Сабантуй, празднуемый в разных форматах – от сельского до федерального уровня.

Формированию этнической толерантности способствуют также организуемые местными и татарстанскими властями в местах компактного проживания татар Дни татарской культуры. Они проходят с разной периодичностью и масштабом (например, в Астраханской области в 1992 г., в Калтасинском районе Республики Башкортостан в 1997 г., ежегодно – в Балаковском районе Саратовской области и в Городищенском районе Пензенской области и др.). В ходе подобных мероприятий представители других национальностей имеют возможность познакомиться с традициями и обычаями татарского народа.

В 2018–2019 гг. Институтом татарской энциклопедии и регионоведения Академии наук РТ предполагается продолжить работу над проектом «Регионы компактного проживания татар на территории Российской Федерации» и посвятить следующее научно справочное издание известным представителям татарского народа, чья жизнь и деятельность связаны с конкретными местами проживания татар России. Отметим, что до сегодняшнего времени подобные комплексные исследования не проводились. При этом заинтересованность Татарстана и регионов в таком изда-

нии давно назрела, так как представители татарского народа в регионах компактного проживания активно проявляют себя в различных областях жизнедеятельности – в сфере науки, образования, культуры, спорта и т.д. Предполагаемое издание позволит дополнить общее представление о регионах компактного проживания татар в Российской Федерации, показать реальную историю нашего народа, сотканную из индивидуальных судеб конкретных людей. Подготовка и издание такой работы, безусловно, будут способствовать укреплению связей республики с татарами в многочисленных регионах их компактного проживания, а также духовному и культурному единению татарского народа. В дальнейшем на базе собранных материалов мы планируем подготовить энциклопедическое издание о местах компактного проживания татар в Российской Федерации.

**Литература:**

1. Регионы компактного проживания татар в Российской Федерации. Казань: Институт татарской энциклопедии и регионоведения АН РТ, 2016. – 336 с.

2. Татарская энциклопедия. Казань: Институт татарской энциклопедии, 2010. Т. 5: Р–Т. – 736 с.

3. Татарстан: Краткая иллюстрированная энциклопедия. Казань: Институт татарской энциклопедии и регионоведения АН РТ, 2015. – 828 с.

4. Татары. М.: Наука, 2001. – 583 с.

# РЕЦЕНЗИЯ<br>НА КНИГУ Р.Ф. КУШМУХАМЕТОВА<br>«ОПАЛЕННЫЕ ВОЙНОЙ СТАНИЦЫ ПРИУРАЛЬЯ». – ОРЕНБУРГ: ИПК «ГАЗПРЕСС» ООО «СЕРВИСЭНЕРГО-ГАЗ», 2017. – 130 С.

***Р. Р. Аминов***

В последние годы история Оренбургского казачьего войска и в том числе татар-казаков,становится объектом исследования не только ученых, но и местных краеведов. Автор рецензируемой книги Рашит Кушмухаметов, выпустил в свет несколько работ по истории татар-казаков Оренбуржья, а именно, пос. Чесноковка Переволоцкого района Оренбургской области. Выход в свет научно-популярной литературы, посвященной истории населенных пунктов со смешанным этническим составом населения, способствует укреплению мирного сосуществования и взаимодействия народов и конфессий и представляется важным подспорьем в обеспечении социальной стабильности России.

Несмотря на небольшой объем (130 стр.), данная книга включает в себя богатый фактический материал. Работа состоит из восьми разделов.

В первом разделе «Введение» (стр. 3–6), автор затрагивает вкратце основные события, связанные с историей казачества Оренбуржья. Безусловно, было бы не лишним, если автор привел в вводной части работы историографию вопроса.

Несомненно, положительным моментом в структуре работы является взятый за основу хронологический метод подачи материала. Основное повествование начинается с участия казаков ОКВ в Отечественной войне 1812 г. и завершается Чеченской войной. На наш взгляд, было бы целесообразным привести в конце работы перечень основных дат.

Во втором разделе («Казаки из Оренбуржья в Отечественной войне 1812 года и других военных действиях России». стр. 7–12.), Рашит Кушмухаметов обращает внимание читателя на сюжеты участия оренбуржцев в Отечественной войне 1812 года, а также в Русско-турецких войнах (1828–1829 гг. и 1877–1878 гг.), Среднеазиатских походах, Русско-японской войне 1904–1905 гг. К сожалению, за исключением Отечественной войны 1812 г., которой посвящена основная часть раздела, автор рассматривает историю участия оренбургских казаков в других военных кампаниях вскользь.

Самым ценным разделом рецензируемой книги, по нашему мнению, является III раздел «Возвращение казаков в станицу» (стр. 13–57). Здесь

мы обнаруживаем разнообразный фактографический материал: планировка пос. Чесноковка, сведения о численности поселка на рубеже XIX – XX вв., описание жилища. Дополняется общая картина иллюстрациями типов казачьих изб Чесноковской станицы.

Проведенный автором анализ социально-экономического положения Чесноковской станицы на рубеже XIX–XX вв. позволяет читателю окунуться в реалии казачьей жизни и получить представление о взаимоотношениях и буднях казачьей жизни. Положительным моментом является разделение автором население поселка вне зависимости от этнической принадлежности по социально-имущественному положению. В поселении наблюдалось социальное расслоение. К примеру, выясняется, что к зажиточной прослойке «чесноковцев», относились представители семьи Кушмухаметовых: Бакый-бай, Фатых-бай, Муким-бай. Войсковым хлебным магазином руководил также татарин – Наби-бай Биткулов.

В четвертом разделе («Первая мировая война. 1914 год». стр. 58–70), при изложении материала Р. Ф. Кушмухаметов приводит данные из записок казака Чесноковского поселка – Д. А. Муканаева, из которых видно, что чесноковцы встретили весть о совершении Великой Октябрьской социалистической революции находясь в лагере для военнопленных от немецких социалистов, требовавших от командования лагеря смягчения условий содержания русских пленных. На основании имеющейся литературы и воспоминаний вышеупомянутого Д. А. Муканаева, краевед воссоздает картину боевого пути чесноковцев и приводит данные о награждении казаков. К примеру, выясняется, что в ходе боев у села Трыстень (июль 1916 г.) были награждены казаки-чесноковцы шестой сотни 3-го Оренбургского полка Набий Аблязов, Хузиахмет Биктеев, Василий Болодурин. В этом же разделе автор информирует читателя о ситуации в крае во время Февральской революции 1917 г.

В V разделе освещаются сюжеты из Гражданской войны (стр. 71–94). Выясняется, что в ходе событий Гражданской войны представители одной семьи оказались по разные стороны баррикады. Так, если Габдрахим Хусаинович Кушмухаметов остался верен атаману Дутову, то его отец, Хусаин Зарыевич Кушмухаметов, напротив, принял сторону красных. Нельзя, не согласиться выводом с Р. Ф. Кушмухаметова о кровавом и жестоком характере действий в ходе Гражданской войны. В целом, краевед довольно подробно и живописно описывает сложные события, происходившие в регионе в исследуемый период, что позволяет читателю достоверно воссоздать картину участия оренбуржцев в том числе и казаков-чесноковцев в военных действиях.

Заслуживает внимания факт описание подвигов, совершенных жителями Чесноковки, в ходе Великой Отечественной войны (VI раздел. Великая Отечественная война 22.06.1941–09.05.1945. стр. 98–110). В книге представлены 19 человек, из которых 17 являлись татарами. Вне всякого сомнения, данная информация представляется уникальной и важной при составлении справочников, энциклопедий по истории участия оренбуржцев, а также татар, в Великой Отечественной войне.

VII раздел посвящен локальным войнам (Афганская и Чеченская войны – стр. 111–120). В данном разделе, автор продолжает выбранный им вектор изложения материала и вкупе с биографией участников военных действий публикует их воспоминания.

В качестве пожеланий можно рекомендовать автору в дальнейшем чаще использовать архивные данные и приводить в своих работах как можно больше иллюстративного материала. Незначительным упущением книги можно назвать отсутствие в ней родословных казаков-чесноковцев, их наличие обогатило бы и разнообразило рецензируемую работу. К сильным сторонам настоящей книги можно отнести использование в ней воспоминаний современников событий, описываемых в работе. Особенно, это касается периода конца XIX–начала XX вв.

Стоит сказать, что обращение к мемурам, дневниковым записям является важным дополнением к другим видам источников таким как архивные данные, законодательные акты, статистические материалы, справочные издания. Информация, которая содержится в воспоминаниях и дневниковых записях, является уникальной, так как в архивах обнаружить зафиксированные в них факты представляется практически невозможным. К преимуществам работы можно отнести также использование Р. Ф. Кушмухаметовым научных трудов таких авторов, как Р. Р. Аминов, А. В. Ганин, В. С. Кобзов, Т. К. ахрова, что несомненно, делает работу более качесвенной и целостной.

В заключении хотелось бы отметить, что предложенная структура книги, при небольшой доработке, может быть рекомендована в качестве модельной при дальнейших краеведческих публикациях подобного рода по истории народов Южного Урала.

# ТАТАРДА КӨЧ БАРМЫ?

***Ф. М. Нәбиуллин***

Татар теленә генә түгел, татарларның үзләренә дә үтә кыен вакыт килде.

Татар өчен үз телен югалту ни дәрәҗәдә хәвефле соң? Бәлкем, кайберәүләр уйлаганча, татар каны һәм татар рухы булу да җитәдер? Билгеле, теләсә кайсы мәсьәләне һәрьяклап һәм тирәнтен өйрәнгәндә, җиде кат үлчә – бер кат кис, дигән мәкальне онытмаска тиешбез. Шул ук вакытта инсани, матди көчләребез, вакытыбыз һәм башка мөмкинлекләребез чиксез булмавын да истә тоту зарур. Эволюция кичерүче Табигать әллә ни күп мөмкинлек бирми.

Татар һәм башка халыкларның телләрен өйрәнү мәсьәләсен кабыргасы белән куеп, Табигать тарафыннан үз мәдәниятләре кочагында барлыкка килгән; тәгәрәп-аунап буй үстергән туган җиргә, Ватан дигән тәгаен биләмәләргә тарихи бәйле булган; гомуми түгел, тормышчан күзаллаулар уята торган милли мохитне саклап калу максатында игътибарыгызга милләтебезнең һәр акыллы вәкилендә халкыбызның чишмә башы булган туган теле белән кызыксыну уятуның төп механизмнары нигезләмәсен тәкъдим итәм.

Әлеге мәсьәләнең сәяси ягын кузгатырга теләмәсәм дә, моны әйләнеп узу мөмкин булмавын аңлап, системага салучы белгеч буларак, хәзерге тарихи чорда тормышка ашырылучы, милли һәм тел сәясәтендәге ап-ачык хаталарны һәм ялган күзаллауларны, Россия дәүләтчелегенең үзенә дә янаучы яшерен хәвефләрне ни рәвешле күрүемне кыска гына бәян итеп китәргә телим. Мәгълүм бер идеологик даирәләрнең дәүләтчелекне саклау, җәмгыятьне берләштерү өчен төрле халыкларны, милләтләрне бер телле, бер мәдәниятле казанда кушып «кайнатып», үзенчәлекләрен юкка чыгару мөмкин һәм зарур дип исәпләүләре Мотлак Канун идарә итә торган теләсә кайсы галәми системалар төзелешенең барча нигезләмәләрен җимерә. Ап-ачык күренеп торган галәмнең системалы законнарына таянганда, аерым шәхесләрдән өстен торган физик һәм метафизик процессларга таянганда гына ялгышмыйча, дөрес үлчәнгән карарлар кабул итәргә мөмкин. Системага салучы белгечләргә система законнары яхшы мәгълүм, бер чылбыры өзелә яки югала икән (дәүләти һәм иҗтимагый өлкәләргә дә карый бу), система котылгысыз рәвештә көчен, идарә итү

мөмкинлеген җуя. **Россиядә яшәгән халыклар үз хасиятләрен югалта икән (тел – шуның иң әһәмиятле сыйфатларыннан берсе), дәүләт үзе дә, нигез ташларын, таяныр көчләрен җуеп, әкрен һәм ышанычлы рәвештә үз-үзен бетерүгә, һәлакәткә дучар була.**

Теләсә кайсы зур система (шулай ук кечкенәсе дә) тормыш-көнкүрмешендә яшәүчәнлеген һәм тотрыклылыгын саклау өчен вакыт-вакыт кына түгел, даими рәвештә билгеле бер законнарга таянырга, бериш таләпләрне үтәргә тиеш.

Мин биредә система кагыйдәләрен һәм тулы составлылык, ике башлангыч нигезләмәсе, көчләрнең эволюцион иерархиясе кебек таләпләрне тәфсилләп тормыйм. Бу күп вакытны алачак, мин моны теләсә кайсы фәнни яки стратегик форумда бәян итә алам. Бары тик галәм законнарын әйләнеп узу, алдау яки кичектереп тору мөмкин түгеллеген генә искәртәм. Эволюция барышын тормышка ашыру өчен тигезләп торучы көч каршы торучы көчләр үсешен дә барлыкка китерә. Табигать көчләренә каршы көрәшүне җил тегермәннәре белән көрәшүгә тиңлиләр. Эволюция, алга таба ныклы биш адым ясау өчен, төрле вакыт аралыгында ике адым артка чигенү мөмкинлеген дә калдыра.

Мондый чорларда – төшенкелек вакытында һәм тәгаен бүгенге этапта да, материализм, мал җыю, чиктән тыш исраф итү һәм һәртөрле уңайлыклар гына эзләп замандашларыбызның акылы томаланган, өстән-өстән генә фикерләү тантана иткән чорда кеше яшәеш серләрен эзләүдән шактый ераклаша башлый, күршесенең эчке дөньясына битараф булып кала, хәтта аны күрергә теләмәүчегә әйләнә. Билгеле, андыйларны күршесенең эчке дөньясы, үсеш үзенчәлекләре кызыксындырмый, аңа өстән-өстән генә аралашу да җитә, хәл белешү дә һава торышыннан зарланудан узмый. Мондый вәзгыятьтә күршеләр, шул исәптән милләтләр арасында да, тәҗрибә алмашу шактый кыенлаша, хәтта моңа җирлек тә калмый. Кешелеккә зур колачлы сынаулар, һәлакәт, бәла-каза, эпидемияләр, рак, ВИЧ, йөрәк сырхавы кебек дәвалавы катлаулы булган авырулар килгәндә (бу сынау-имтиханнар, тетрәнүләр милләтләрне, халыкларны аралап тормый, яман шеш кешеләрдә генә түгел, теләсә кайсы системада да килеп чыга) уртак тәҗрибәнең җитәрлек дәрәҗәдә булмавын һәм белемне гомум туплый алуга сәләтсезлегебезне, алдыбызга килеп баскан сынауларны җиңәргә, бусага аша чыгарга көчебез җитмәүне күрсәтә.

Хәтта татарлар үзләре үк туган телебезне искелек калдыгы, файдасыз бер нәрсә итеп күзаллый башлаган икән, бу хәл элгәреләребезнең, әби-бабаларыбызның үзенчәлекле тәҗрибәсе белән бәйләнешне югалта баруыбызны аңлата. Мондый караш киләчәктә бу тәҗрибәне, бу бәйләнеш аша бирелә торган көчне бөтенләй югалтуга китерәчәк. Әлеге тәҗрибәнең

кыйммәте IQ, интеллектуаль гыйлем туплауда түгел, ә Абсолют (Мотлак) Гыйлем белән багланышны сиземләү аша үстереп, рухны ныгытуда, бәла-каза, кайгы-хәсрәт, авырлыкларны, сынауларны кичеп чыгардай көч булдыруда. Биредә гыйлем академик белем туплауны түгел, асылында, табигатеңдә булган түбән омтылышларны җиңеп, югары омтылышларга җавап бирә алу сәләтен уятуны аңлата.

Мин озак еллар буе берничә йөздән артык нәсел системаларын күзәтеп, аларның язмышын анализладым. Шушы күзәтүләрем нигезендә тупланган дәлилләргә таянып, катгый бер фикергә килдем: әгәр милләт үзенең мәдәни үзенчәлекләрен, этник менталитетын югалта һәм кешенең ата-анасы, тамыры белән эмоциональ бәйләнеше өзелә икән, бу киләчәк буынның эчке принципларын какшата, таяну ноктасын югалта, буыннар арасында конфликт тудыра. Шулай итеп, иң аянычы килә: нәсел көче котылгысыз рәвештә сүнә бара.

Шуның нәтиҗәсе буларак, тормыш шартлары, аерылып киткән яшь буынны, космополитик лозунгларга бәйләп, чит уенга тартып ала, чит стратегиягә кертеп җибәрә. Моның ачык үрнәге булып, яшертен, әмма кырыс, чик дәрәҗәдә куркыныч булган кытай стратегиясенең кертелүе тора.

Бары тик төпле аек акылга ия булган көчләрне уятып, аларны җитәрлек күләмдә формалаштырып, туплап кына гаиләне, милләтне, җәмгыятьне, дәүләтне саклап кала алабыз һәм планетабызны упкынга, билгесезлеккә этәрүче планетакүләм җимергеч процессларны туктата алачакбыз. Тулы түгәрәк көчен аңлаучы акыллы кешеләр ир-атның хатын-кыз ярдәменнән башка фәлсәфә ташын – җуелган ижат итү көчен, таба алмаячагын яхшы беләләр. Шул рәвешле, охшашлыклар законы буенча, ишле булуына карамастан теләсә кайсы төркем, милләт, күршесендәге төп этник төркемнәрне күрмәмешкә салыша икән, үсеш баскычында үз алдында куелган бурычларны ерып чыга алмаячак. Кешелек алдында әзерләп куелган бихисап сынауларның берсе: чираттагы бусаганы узу өчен кирәкле булган берләштерү көчен, куәтен туплый, җыя алмаячак. Билгеле булганча, шымчылык итү, алдау, хәйләләү кебек алымнардан чирканмаучы эгостик катламнарда да әлеге Бусагаларны үтеп чыга алырдай көч туплана алмый.

Өстән генә караучы прагматиклар һәм рационалистлар тышкы якка, тышкы багланышларга өстенлек бирә торган хәрәкәтләрне генә үтә файдалы дип саныйлар һәм моның өчен инглиз телен аеруча кулай дип исәплиләр. Гәрчә бу хәл өзелгән, җил әллә кайларга илтеп ташлаган һәм шуңа күрә саргаеп кибәргә туры киләчәк яфракны хәтерләтә. Телне тышкы багланышлар чарасы гына дип күзаллау кешенең асыл табигатен үтә

гадиләштерә. Теләсә кайсы агачның тернәкләнүе, уңышлы үсеше өчен, туфракта булган иң яхшы, туклыклы матдәләрне таный, суыра, сеңдерә ала торган, җир белән бәйләп торучы тамырларның нык булуы мөһим. «Җир-тамыр» бәйләнеше булмаса «тамыр-кәүсә-яфрак-җимеш» буыннарының эзлеклелеге, дәвамлылыгы булмас иде. Охшашлык законы буенча, бабаларына, аларның меңъеллык тәҗрибәсенә, тарихына, аралашу ысулларына бармак аша гына караган кеше күптәннән тупланган иң яхшы тәҗрибәне кабул итәргә һәм аны киләчәк буынга тапшырырга сәләтле түгел. Димәк, ул нәсел тамырларының көчен дә тапшыра алмаячак, чөнки аңа узмышыннан, ата-бабадан фатиха бирелмәгән.

Гасырыбыз өчен иң авыр саналган чирләрнең калкып чыгуы – нәселдән нәселгә күчеп килгән психогенетик кичерешләр, тетрәнүләр нәтиҗәсе ул. Моңа шәхеснең яшәеш барышында башыннан кичергән дулкынланулары да өстәлә (ул мохитне морфогенетик кыр дип атыйк). Стресс – кичерешләр, хисләр системасын томалый, организмдагы көч кырларының тулы канлы әйләнешен боза. Шул рәвешле бурят, татар, ингушлар өчен үткәннәр белән тоташтыручы күпер – инглиз, немец яки урыс теле түгел, ә аның үз туган теле. Туган тел – үз-үзең, күңел түреңдәгеләр белән багланышлар ул. Нәселдән килгән чирләр – генетиклар тарафыннан өйрәнелә торган бозык хромосомалар чылбырын сукыр рәвештә, үтә гади тапшыру түгел, нәсел яшәешендәге алынмаган сабакларның теркәлеп баруы нәтиҗәсе. Бу дөньяда берни үлми, бернәрсә дә юкка чыкмый, узганнар бездә яши бирә. Аерма фәкать шунда: кемдәдер алар үле йөк булып тора; икенче берәүләрдә кайчакта аңлый алырдай өслеккә чыгып әрнү, сызлануларның сәбәпләрен белдерә.

Аерым алганда, татар телендә мәгънәләр дөньясына ачкыч булып торучы бик үзенчәлекле сүзләр бар. Әйтик, үпкә-үпкәләү, чир-чират һәм башка шундый кәлимәләр. Бу сүзләр үпкә авыруларының үпкәләүгә бәйле булуын, һәр чирнең билгеле бер эчке сәбәпләр аркасында, үз вакытында килүе турында сөйли. Барча дөнья – эзлекле рәвештә үзара бәйле, үзара шарт итеп куелган чылбырлардан торган тоташ тукыма ул. Чуаш, удмурт, бурят һәм башка халыкларда да мондый бәйләнешне күрсәтә торган сүзләр бар. Бу бик үзенчәлекле, әмма югалып бара торган хәзинә.

Мөнәсәбәтләр онкологиясе – күршеләрең, нәселең, ата-бабаларың, узмышың белән багланышларны югалтмый сакларга, ныгытырга теләмәүдән, үзара сакчыл мөнәсәбәтләр корырга сәләтсез булудан килеп чыга. Әмма яхшы киләчәккә узмышыбызның иң кыйммәтле тәҗрибәсен алганда гына, аны фидакарьләргә лаеклы рәвештә бүгенге көн аша уздырып кына ирешергә мөмкин. Бер-береңнең табигатеңдә булган тулы куәтен чагылдырырга омтылу хокукын; бөтенлекне югалтмыйча, аерым

бер милли үзәнчәлекләрне саклап калырга омтылу хокукын танымыйча торып, кешелек алдына килеп баскан глобаль проблемаларны хәл итү мөмкин түгел.

Татарлар алдында күп төрле бурычлар тора. Теләсә кайсы системада: беренчел, икенчел булу; бер-бер артлы урнашу; әһәмиятлелек дәрәҗәсе буенча; вакыт һәм кичектергесезлек ягыннан структура үз тәртибен булдыра. »Татарда көч-куәт бармы?», дигән сорауга мин бер дә икеләнмичә нык итеп: «Бар!» дип җавап бирәм. Ләкин ул көч төрле якка таралган, аны җыеп алырга кирәк. Без һәммәбез дә гомуми кагыйдәләргә таянып, билгеле бер критерийларны истә тотып, шул көчне торгызучылар, туплаучылар булып китәргә тиешбез. Ләкин, бу очракта түбәндәге кагыйдәне истән чыгармаска кирәк: үзебезне кимсетелгән итеп тоюдан, корбан итеп санаудан арынырга кирәк. Һәлакәткә, бетүгә дучар булганнар хәленнән чыгып, эчке бер үпкә белән гаеплене эзләүдән туктарга кирәк. Һәркем үзгәрешне үзеннән башларга тиеш. Иң яхшы, иң кулай үзгәреш урыны – ул мин үзем, минем гаиләм, нәселем, халкым. Теләсә нинди авырудан дәвалануның беренче адымы – мөмкин кадәр төгәл, гадел, объектив диагноз кую. Шуны да танырга һәм исәпкә алырга кирәк: безнең халык яшәеш тарафыннан үзенә бирелгән вакыт аралыгында күп кенә хаталар ясады, күп мөмкинлекләрне кулдан очкындырды, рухи көчен югалтты. Хәзер инде башкаларны тикшермичә, аларны үзебезнең орбитага тартып китермичә, оператив (җитез) рәвештә хаталарны төзәтү өстендә эш алып барырга кирәк.

Белгәнебезчә, диңгез корабының озак вакытка сузыла торган сәфәре алдыннын аеруча ныклы әзерлек кирәк. Татар халкына да үзенең тормышчан, оптимизм белән сугарылган үсеш юлын, киләчәген кору өчен, тирән фәлсәфәгә нигезләнгән стратегия кирәк. Россия татарларына һәм җирдә яшәүче барлык татарларга да стратегик үзәк – көч үзәге, зирәклек үзәге, фәлсәфи үзәк, планлаштыру үзәге, рух һәм фикер үзәге кирәк. Анда аксакаллар, философлар, тарихчылар, тел белгечләре, психолингвистлар, психогенетиклар, филологлар, системалаштыручылар, мәгариф өлкәсендәге новаторлар, яшь лидерлар һәм югары идея йөртүче, генератор булырдай кешеләр булырга тиеш. Стратегия кирәкле югарылыкта һәм күпкырлы булырга тиеш. Милләтенә, теленә, мәдәниятенә битараф булмаган һәрбер татар кешесенең бу стратегиядә катнашуы сорала.

Стратегик үзәк үсешкә китерә торган иҗади принципларга таянырга һәм һәртөрле таркатуга, бүлгәләүләргә чакырулардан азат булсын. Үзәк куйган максат һәм бурычларның һәркемгә дә ачык аңлаешлы булуы да шарт. Ул мөмкин булган кадәр халыкыбызның һәм башка халыкларның үткән тәҗрибәсенә таянырга, шулай ук хәзерге заманның алдынгы тех-

нологияләрен, методларын, команда – оештыру алымнарын куллану аркылы барсын. Татар халкының бердәм команда, бер гаилә булып берләшүе мөһим. Шул очракта гына бу гаилә сыйфат күрсәткечләрен югалтмыйча ишәя барыр, яңа көчләр белән ныгытылыр.

Бүгенге этапта Стратегик үзәк һәрберебезгә юнәлеш итеп яңа ныклы күрсәтмәләрне алга куйса дөрес булыр. Менә алар:

1. Аерымлыкларны түгел, барыбыз өчен дә уртак якларны эзләргә кирәк.

Россиядәге барлык татарларны берләштерергә (Казан, Мәскәү, Себер, Әстерхан, Пенза, Пермь, Саратов, Оренбург һ.б.). Татар, башкорт, типтәр, мишәр, кряшеннәрне бер-берсе белән тагын да якынайту өчен мөмкин булганның барсын да эшләргә. Бер-береңне кимсетүне, каршы куюны һәм башкалардан өстен булырга тырышуны туктатырга, һәр төрле эрелек, тәкәберлек күренешләреннән арынырга. Үзеңнең үзенчәлекле, уңай якларыңны масаюга түгел, ә уртак үсешкә, уртак бәхеткә, теләктәшлек күрсәтүгә юнәлдерергә кирәк. Чөнки чамадан тыш горурлык тәкәберлеккә, үзеңне башкалардан өстен куюга китерә.

Шул ук вакытта билгеле бер милләт вәкилле булуың белән кәперәю, масаюлардан да искелек калдыгыннан арынган кебек котылырга кирәк. Һәрбер милләт – билгеле бер халыкның, этносның күп гасырлар буе җыелган шәхси тәҗрибәсеннән тупланган, аңа гына хас булган үсеш калыбы ул. Гасырлар буена тупланган аеруча файдалы бу элементлар Дөнья халыкларының гомуми хәзинәсенә салынып бара. Һәрбер халыкның бик күптәннән җыелып килгән шушы үзенчәлекле тәҗрибәсен игътибарга алырга, бүгенге тормышта кулланырга кирәк. Чөнки һәрбер милләт, халык алдында торган төп максат елдан-ел көчәя барган хаосны җиңеп, кешелек дөньясын саклап калу. Үзеңдәге эчке таркаулыкны җиңми торып, гомумкешелек таркаулыгын җиңәргә мөмкин түгел.

Кеше организмы барлык органнар үзара балансы булганда гына яхшы эшли ала. Сәгать һәрбер механизмы үз урынында булып, үз вазифасын төгәл башкарганда гына сыйфатлы һәм озак хезмәт итә ала. Әгәр дә зуррак шестеренка тешле тәгәрмәч үз вазифасын башкаларга көчләп тага башласа сәгать эштән чыгачак, ватылачак.

Россия Федерациясе Конституциясендә һәм дәүләт идарә аппаратының декларациясенендә язылган, «халыкларның федерация составына ирекле рәвештә керүе» турындагы нигезләмәне исәпкә алсак, бер милләт тә, тел, дин һәм мәдәният тә икенче сортлы була алмый. Халыкларны төрле сортларга бүлү турында сүз дә булырга мөмкин түгел. Бу нигезләмә бары тик декларация булып кына кала алмый. Аны тормышка ашырырга, тормышчан итәргә кирәк. Бер милләтнең, бер халыкның да

бәясен, дәрәҗәсен түбәнсетергә юл куймый торган, ныклы санкцияләр белән катгый рәвештә ныгытылган беркетелгән канун кабул итү һәм аны тулысынча үтәү зарур. Шулай булмаганда бу федерацияне иректе дип санап булмый. Бу очракта механизм бозыла, сәгать ватыла, организм үлемгә дучар була.

Безнең федерация составында булуыбыз кагылгысыз һәм бәхәссез, тулы хокуклы, тулы вәкаләтле. Кайбер электрон чыганакларда күренеп китә торган: «Үзегезнең мәдәниятыгызны, телегезне федераль чыгымнар хисабына түгел, үзегез күтәрегез», дигән аноним язмаларны җинаятьчел, Конституциягә каршы килә торган провокация дип санарга кирәк.

Теләсә нинди эре автономиянең тормышы кече автономияләрнең балансы нигезендә оеша. Сәламәт бавыр, талак, ашказаны организмга озак һәм продуктив яшәргә мөмкинлек бирә. Татар халкына да яшәешнең гомуми агымында, тарихта үз урынын, үз балансын, үз көчәрен табарга кирәк.

Гаиләдә озакка сузылган авыр аңлашылмаучылыклар вакытында, иң кулае – аек акыллы берәүнең ялгыз гына калып эчке дөньясында чишелеш табуы. Бу очракта аның бурычы – үзенең уй-фикерләрен туплап, таяныч ноктасын табу, капма-каршы куючы этәргеч көчне түгел, ә үзенең тарту көчен, җәлеп итә торган сыйфатларын ныгыту. Безнең халыкка да бер селкенеп алырга һәм нык итеп аякка басарга кирәк.

2. Татар халкының тарихына караган сорауларны, мәсьәләләрне тикшергәндә, бигрәк тә татарларның килеп чыгышын, теге яки бу токымның тарихи урынын билгеләгәндә, көчләп чукындыру кебек катлаулы сорауларны ачыклаганда аеруча сак һәм чамалап эш итәргә кирәк. Тарихи вакыйгаларны төрлечә ачыклау һәм аңлату да каршылыклар тудырырга, бер-береңне гаепләүгә, үзеңнекен күтәреп башкаларны түбәнсетүгә китерергә мөмкин.

3. Инануларның төрлелеге, төрле дини конфессияләргә карау татар халкын бер-берсенә каршы кую һәм бүлгәләү өчен чыганак булып торырга тиеш түгел. Кызыллардан – аклар, аклардан кызыллар ягына күчкән бала барыбер синең балаң булып кала.

4. Нык рухлы, әхлаклы шәхесләр тәрбияләү максатыннан чыгып, татар менталитетен тарката торган, татар мәдәниятын кимсетеп, татар халкының тарихын бозып күрсәтә торган кайбер телевизион тапшыруларга (мультфильм, фильм, һәр төрле масса күләм информация чаралары: газета, электрон газета һәм сайтларга) карата катгый эчке цензура булдырырга кирәк. Татарларга җавапсыз рәвештә бөтен милләтне, телне кимсетеп, мәсхәрәләп язган комментарийларны, аноним хатларны укуны, таратуны

бөтенләй туктатырга тәкъдим ителә. Явызлык һәм усаллык кемнең авызыннын чыккан шунда кала бирсен.

5. Татар әдбиятын, газета, журналларны, балалар әдәбиятын, сайт һәм методик материалларны сайлап алып тәкъдим итә торган база булдырырга кирәк. Күпчелек районнарда һәм татарлар тупланып яши торган биләмәләрдә уртак хәбәрләр мәйданын булдыру зарур. Төрле диспут-клублар уздыру өчен урыннар булдыру, мәктәпне тәмамлаганнар, урта һәм өлкән яшьтәгеләр өчен тиз арада татар телен өйрәтә торган махсус курслар оештыру таләп ителә. Гаилә институтын булдыру турында да тәгаен тәкъдимнәр эшлисе бар.

6. Соңгы елларда кулланылышка кереп киткән, ләкин безнең менталитетка каршы килә торган кайбер сүзләргә карата катгый фильтр куярга кирәк. Мәсәлән, *«абориген халыклар»* сүзтезмәсе урынына *«төп яки җирле халыклар»* дип куллану дөресрәк булыр. Гади халыкның күзаллавынча абориген сүзендә артта калган, примитив кешеләр дигән төсмер дә чагылып китә.

7. Үз телен начар белгән яки бөтенләй белмәгән милләттәшләребезгә карата да аларны санга сукмыйча, илтифатсыз булырга ярамый. Алар үскән, яшәгән тирәлек, уку-укыту шартлары, аралашу сферасы туган телне үзләштерү өчен уңайсызбулган булырга мөмкин. Бары тик яхшылык, игелекле мөнәсәбәт белән генә әзер затларны туган телен өйрәнүгә этәрергә мөмкин.

8. Сәяси вәзгыятькә бәйле булмаган җәмәгатьчелек фикере, иҗтимагый көч булдырырга, формалаштырырга кирәк. Шул ук вакытта барча җәмгыятьнең тулы канлы, имин яшәве өчен зарур булган дәүләтчелекне сакларга кирәклеген онытмыйк, истән чыгармыйк. Идарәчеләр дә, мәгариф министрлыгы да түгел, бары тик халык үзе – телен кулланучы, саклаучы һәм яклаучы булып тора. Баласын кайгырткан кебек халык үзе аны кайгыртырга, сакларга бурычлы. Бала белән тыгыз элемтә булганда – бала сәламәт була, аягында нык басып тора. Безне киләчәккә ялгаучы бу бала – безнең телебез, шуны истән чыгармыйк.

Тагын бер мөһим мәсьәлә – татарлар туган телләрендә сөйләшергә оялмаска тиеш. Ата-аналарыбыз аша Яратучы тарафыннан бирелгән, мәдәниятебезне без лаеклы рәвештә сакларга, киләчәккә амәнәт итеп тапшырырга тиешбез.

Безгә бирелгән сабак: Табигать тарафыннан салынган телебез тулы канлы әйләнештә булсын. Французлар ниндидер зарурлык булмаса, инглиз килеп мөрәҗәгать итмәсә, инглиз теленә күчмәс; немец үзе килеп мөрәҗәгать итмәсә индус та немец телендә сөйләшмәячшк. **Үзеңне түбәнсетеп башкаларның күңелен күрү зыялылык билгесе түгел**.

Ике тарафның да бер-берсенә карата хуш күңелле булуы, санлап хөрмәт белән каравы мөһим.

**P.S.** *Әлеге мәкаләне янә бер кат күздән кичереп утырганда, күкрәк авыруыннан җәфаланучы бер ханым белән күрешергә туры килде. Мондый очракларда тәкъдим ителә торган бер генә традицион медицина ысулы да, дару да аңа ярдәм итмәгән. Аяклары тыңламый, организмы көннән-көн зәгыйфьләнә бара, үзенең яшисе килә. Хатын-кызның күкрәге – хисләргә бәйле иң сизгер урын ул. Күкрәктә йомылып калган хисләр, кичерешләр җимергеч үзгәрешләргә сәбәп була (гадәти психосоматика очрагы бу). Аның ачынып әйткән ихлас сүзләре күпләргә сабак булырлык: кичерешләремне сиздерергә гел кыенсындым, уйлаганымны әйтергә кыймадым, урамда, халык арасында татарча сөйләшергә оялдым...*

*Хис – кичерешләрегезне тоткарламагыз, аларның табигый агышына ирек бирегез. Туган телегезнең ирекле әйләнешенә юл куегыз. Үзегезгә – үзегез иркенләп сөйләшергә рөхсәт итегез, ялгышырмын, буталырмын, дип кыенсынмагыз. Тормышыгызны үз кулыгызга алыгыз!*

## Авторлар буенча белешмә

**Абдерахманов Таһир**, тикшерүче-туган якны өйрәнүче.

**Айнетдинова Лариса Мәхмүт кызы**, ТФАның Татар энциклопедиясе һәм төбәкләрне өйрәнү институтының Төбәкләрне өйрәнү һәм социомәдәни тикшеренүләр үзәге мөдире, тарих фәннәре кандидаты, доцент.

**Алексеев Игорь Евгеньевич**, кандидат исторических наук, главный советник Управления по взаимодействию с религиозными объединениями Департамента Президента Республики Татарстан по вопросам внутренней политики.

**Батулла Рабит Мөхлис улы**, татар халык язучысы

**Борһанов Алберт Әхмәтҗан улы**, тарих фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасының Туган якны өйрәнүчеләр җәмгыяте рәисе

**Бугарчёв Алексей Игоревич**, ТФА А. Х. Халиков исемендәге Археология институтының кече фәнни хезмәткәре

**Вәлиев Рәмзи Кәлим улы**, тарих фәннәре докторы, профессор, Россия Федерациясе югары мәктәбенең атказанган хезмәткәре, Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе

**Вәлиәхмәтов Фазыл Абдулла улы**, журналист, төбәк тарихын өйрәнүче

**Габдрахманов Илфар Габделхак улы**, Татарстан Республикасының Балык Бистәсе районының Югары Тимерлек урта гомуми белем бирүче мәктәпбенең тарих укытучысы.

**Гатауллин Ринат Фәйзлтдин улы**, икътисад фәннәре докторы, РФА ӨФҮ СЭТИ.

**Гыйматдинова Рима Фатый кызы**, Татарстан Республикасының Лениногорск муниципаль районының «Валерий Павлович Чкалов исемендәге Шөгер урта гомуми белем мәктәбенең» тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы.

**Дәминова Флүрә Каюм кызы**, Татарстан Республикасы милли музеенең өлкән фәнни хезмәткәре, ТР атказанган мәдәният хезмәткәре.

**Емельянов Виталий Павлович**, нумизмат-тикшеренүче.

**Заһиров Булат Әхәт улы**, төбәк тарихын өйрүнәче

**Закиров Рөстәм морза Марат улы**, Башкортстотан Республикасының ТДҖ әгъзасы.

**Имаметдинов Кадерле Имаметдин улы**, Башкортостан Республикасы Татар иҗтимагый үзәге рәисе.

**Ислаев Файзелхак Габделхак улы**, тарих фәннәре докторы, Россия ислам институты профессоры, Казан шәһәре, Татарстан Республикасы

**Исхаков Дамир Мәүләви улы**, тарих фәннәре докторы, БТК Милли Шура әгъзасы.

**Кутумова Равиля Сибгатулла кызы**, Тубыл шәһәренең урта гомум белем бирүче 15 номерлы мәктәбе каршындагы Төмән өлкәсенең милли мәктәпләре музее мөдире, Татарстан Республикасы журналистлар берлеге әгъзасы, хезмәт ветераны.

**Минһаҗев Рәшит Рәкыйп улы**, «Ватаным Татарстан» газетаныҗ бүлек мөдире.

**Нәбиуллин Фәнис Масабих улы**, табиб, психогенетик.

**Сафин Илдар Фәтхулла улы**, Татарстан Республикасының атказанган укытучысы, Татарстан Республикасының Туган якны өйрәнүчеләр җәмгыяте Идарә әгъзасы.

**Сафина Фирсинә Шәймулла кызы**, Г. Ибраһимов исемендәге ТӘТИ эшләгән, тарих фәннәре кандидаты.

**Сәгыйдуллина Мөнирә Хәлим кызы**, БТК Башкарма комитеты хезмәткәре, журналист.

**Степанов Олег Витальевич**, нумизмат-тикшерүче, краевед, Бөтендөнья татар конгрессы каршындагы Гомумтатар төбәк тарихын өйрәнүчеләр җәмгыяте идарәсе әгъзасы.

**Тычинских Зәйтүнә Әптрәшит кызы**, тарих фәннәре кандидаты, РФА УрБның Тубыл комплекслы фәнни станциясе өлкән фәнни хезмәткәре.

**Хамидуллин Булат Лирон улы**, ТФАның Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институтының Татар диаспорасын өйрәнү үзәге мөдире, тарих фәннәре кандидаты, доцент.

**Хәбипова Зәрия Габдулла кызы**, пенсионер

**Черепанов Михаил Валерьевич**, Хәрби-тарихи фәннәр академиясе әгъза-корреспонденты, 1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы музей-мемориалы мөдире.

**Шәйхетдинов Дамир Исмәгыйль улы**, журналист, тикшеренүче һәм татар шәҗәрәләрен төзүче.

**Шәрипова Әльфия Ленар кызы**, Татарстн Республикасы Милли музееның 1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы музей-мемориалының фәнни хезмәткәре.

**Ә. Ф. Ямаева**, Краевед, хезмәт ветераны, Әлмәт шәһәре.

**Яхин Фәрит Зәки улы**, филология фәннәре докторы, профессор.

**Әхәтов Марат Шамил улы**, Чиләбе шәһәренең «Советлар Союзы Герое Муса Җәлил» исемендәге урта гомуми белем бирүче 81 номерлы мәктәпнең укыту-тәрбия эшләре буенча директор урынбасары

**Әскарова Фәния Хәй кызы**, Татарстан Республикасы Лениногорск районы Сарабиккол урта гомуми белем бирү мәктәбенең башлангыч класслар укытучысы.

**Әминов Рөстәм Равил улы**, ТФА Ш. Мәрҗәни ис. Тарих институты өлкән фәнни хезмәткәре.

## Сведения об авторах

**Абдурахманов Тахир**, исследователь-краевед.

**Айнутдинова Лариса Махмутовна**, кандидат исторических наук, доцент, заведующая Центра регионоведения и социокультурных исследований Института татарской энциклопедии и регионоведения Академии наук РТ

**Алексеев Игорь Евгеньевич**, кандидат исторических наук, главный советник Управления по взаимодействию с религиозными объединениями Департамента Президента Республики Татарстан по вопросам внутренней политики.

**Аминов Рустам Равилович** – с.н.с. Института истории им.Ш. Марджани АН РТ.

**Аскарова Фания Хаевна**, учитель начальных классов МБОУ «Сарабикуловская ООШ» Лениногорского района Республики Татарстан.

**Ахатов Марат Шамильевич**, заместитель директора по УВР, МБОУ «СОШ № 81 г. Челябинска имени Героя Советского Союза Мусы Джалиля», учитель истории и обществознания.

**Батулла Рабит Мухлисович**, народный писатель.

**Бурханов Альберт Ахметзянович**, кандидат исторических наук, председатель Общества краеведов Республики Татарстан, Институт истории им. Ш. Марджани.

**Бугарчёв Алексей Игоревич**, младший научный сотрудник Института археологии им. А. Х. Халикова АН РТ.

**Валеев Рамзи Калимович**, доктор исторических наук, профессор, заслуженный работник высшей школы РФ, заслуженный деятель науки РТ.

**Валиахметов Фазыл Абдуллович**, журналист, краевед.

**Габдрахманов Ильфар Габделхаевич**, учитель истории, директор МБОУ «Верхне-Тимерлековская СОШ» Рыбно-Слободсого района Республики Татарстан.

**Гатауллин Ринат Файзлтдинович**, доктор экономических наук, профессор, ИСЭИ УФИЦ РАН.

**Гиматдинова Рима Фатыховна**, муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение «Шугуровская средняя общеобразовательная школа имени Валерия Павловича Чкалова» муниципального образования «Лениногорский муниципальный район» Республики Татарстан, учитель истории и обществознания.

**Даминова Флюра Каюмовна**, старший научный сотрудник Национального музея РТ, заслуженный работник культуры.

**Емельянов Виталий Павлович**, нумизмат-исследователь. Казань.

**Захиров Булат Ахатович**, краевед.

**Закиров Рустем мурза Маратович**, член ТДС РБ.

**Имамутдинов Кадерле Имамутдинович**, председатель ТОЦ Республики Башкортостан.

**Ислаев Файзулхак Габдулхакович**, доктор исторических наук, профессор Российского исламского университета.

**Исхаков Дамир Мавлявеевич**, доктор исторических наук, член Национального Совета Всемирного конгресса татар, редактор журнала.

**Кутумова Равиля Сибгатулловна**, заведующая музеем национальной школы Тюменской области при СОШ № 15 г. Тобольска, член Союза журналистов Республики Татарстан, ветеран труда.

**Мингазов Рашит Ракипович**, редактор отдела газеты «Ватаным Татарстан».

**Набиуллин Фанис Масабихович**, врач, психогенетик.

**Сагидуллина Мунира Халимовна**, сотрудник Всемирного конгресса татар, журналист.

**Сафин Ильдар Фатхуллович**, заслуженный учитель Республики Татарстан, член Совета общества краеведов Республики Татарстан.

**Сафина Фирзина Шаймуровна**, работала старшим научным сотрудником Института имени Г.Ибрагимова КНЦ РАН (КФАН СССР).

**Степанов Олег Витальевич**, исследователь-нумизмат, краевед, член Совета Всетатарского общества краеведов Всемирного конгресса татар.

**Тычинских Зайтуна Абтрашитовна**, кандидат исторических наук. старший научный сотрудник Тобольской комплексной научной станции УрО РАН.

**Хабипова Зария Габдулловна**, пенсионер.

**Хамидуллин Булат Лиронович**, кандидат исторических наук, доцент, заведующий Центра изучения татарской диаспоры Института татарской энциклопедии и регионоведения Академии наук РТ.

**Черепанов Михаил Валерьевич**, член-корреспондент Академии Военно-исторических наук, заведующий Музеем-мемориалом Великой Отечественной войны 1941–1945 гг. Национального музея Республики Татарстан.

**Шайхутдинов Дамир Исмагилович**, журналист, исследователь и составитель татарских родословий.

**Шарипова Альфия Ленаровна**, научный сотрудник Музея-мемориала Великой Отечественной войны 1941–1945 гг. Национального музея Республики Татарстан.

**Ямаева Альфия Ф.**, краевед, ветеран труда, Альметьевск

**Яхин Фарит Закиевич**, доктор филологических наук, профессор, заведующий отделом ИЯЛИ имени Г.Ибрагимова АН РТ.

## Технические требования к публикациям /Мәкаләләргә техник таләпләр

Редакционный совет журнала «Туган җир/Родной край» сообщает о начале публикации данного двуязычного издания в 2018 году как ежеквартальника. К публикации принимаются статьи и материалы как на татарском, так и на русском языках. В этой связи обращаемся ко всем заинтересованным в развитии указанного журнала авторам с предложением принимать участие в его издании. Для этого необходимо подготовить и направить соответствующие статьи в наш адрес.

***Рекомендуемая тематика публикаций:***

- методика и методология историко-краеведческих исследований;
- история краеведения и историко-краеведческое наследие;
- проблемы региональной истории;
- новые археологические, нумизматические, фольклорные и эпиграфические находки;
- публикация источников;
- история конкретных сел и деревень;
- история музеев и публикация музейных коллекций;
- жизнь и деятельность выдающихся краеведов и земляков;
- использование краеведческих материалов и музейных коллекций в школе;
- популярные статьи по краеведению;
- краеведческая хроника (конференции, встречи и т.д.);
- рецензии, обзоры книг на краеведческую тематику.

Статьи оформляются согласно указываемым ниже требованиям:

***I. Технические требования к оформлению статей***

1. Внутри публикаций ссылки оформляются следующим образом [Аминов: 2017. С. 82.]; [Денисов: 2012. С. 25; Черкас: 2005. С. 16.]; [ГАОО. Ф 476. Оп. 3. Ед. хр. 609. Л.6.]

2. Список использованной литературы оформляются согласно ГОСТу и приводятся в алфавитном порядке в конце статьи в виде нумерованного списка:

***Источники и литература***

1. Р. Р. Аминов. Татары-казаки в составе Оренбургского казачьего войска (1748–1917 гг.). Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2017. – 348 с.

2. Государственный архив Оренбургской области (ГАОО). Ф. 98. Оп. 2. Ед. 25.

3. ГАОО. Ф. 98. Оп. 2. Ед. 26.

4. Денисов Д.Н. Очерки по истории мусульманских общин Оренбургского края (XVIII – начало XX в.). М. – Н.Новгород: Издательский дом «Медина», 2012. – 410 с.

5. Черкас Т.Г. Хронограф города. Орск: [Б.и.], 2005. – 67 с.

***II. Редакционные требования к оформлению:***

- Инициалы и фамилия автора указываются справа, далее по центру публикации идет название статьи.
- Аннотация (4–5 предложений) и ключевые слова.
- Текст

1. Текстовый редактор – Microsoft Word, в формате doc или docx.

2. Размер А4.

3. Поля: слева – 3 см., справа –1,5 см.. сверху и снизу – 2 см. Нумерация страниц снизу справа.

4. Шрифт – TimesNewRoman

5. Размер шрифта – 14

6. Межстрочный интервал – 1,5

7. Абзацный отступ – 1,25

3. Требования к иллюстративным материалам:

Фотоматериалы и рисунки (сканкопии) принимаются только качественные (в формате JPEG, объемом не менее 3,50 МБ).

4. Объем публикаций в пределах от 0,5 до 1,0 п.л. (20 000–40 000 знаков с пробелами). К публикациям прилагаются аннотации из 5–6 предложений, а также выделяются ключевые слова (4–5).

5. Сведения об авторе:

1. Фамилия, имя, отчество ____________________________________

2. Ученая степень ____________________________________________

3. Ученое звание _____________________________________________

4. Занимаемая должность ______________________________________

6. Почтовый адрес с индексом _________________________________

7. Адрес электронной почты (e-mail) ____________________________

8. Контактный телефон ________________________________________

Редакция отмечает, что после получения статьи от автора и детального его изучения членами редколлегии она в случае соответствия всем требованиям передается в печать. Если материалы не соответствуют техническим и научным требованиям, статья возвращается автору с замечаниями для устранения недостатков. В связи с большим объемом поступающих материалов редколлегия может ограничиться пересылкой автору, в случае необходимости, соответствующих правил оформления для привидения ее в соответствие с требованиями.

Редколлегия оставляет за собой право размещения публикаций в журнале согласно рубрикаций и наличия мест в выпускаемых номерах. После выхода журнала авторы статей могут получить по одному экземпляру издания.

Электронная версия журнала будет размещаться на сайтах Всемирного конгресса татар и «Всетатарского общества краеведов».

Материалы следует присылать по эл.адресу: monitoring_vkt@mail.ru с указанием темы: «Для журнала «Туган җир/Родной край». Допускается и прямая передача публикаций в редакцию, но лишь в электронных версиях. Для этого указываем адрес нашего журнала: Казань, ул.А.Пушкина, дом 52, офис 203, редакция журнала «Туган җир/Родной край».

**Туган җир**

*Төбәк тарихы буенча журнал*

**Родной край**

*Краеведческий журнал*
1’2018

Компьютерная верстка –
Подписано в печать 00.03.2018 г. Формат 70×100 1/16
Усл. печ. л. 9,25 Тираж 500 экз.
Отпечатано с готового оригинал-макета.
в типографии ООО «Грумант»
В данном номере журнала использованы фотографии из личных архивов авторов.
Карты составлены к.г.н. Р.Ф.Темиргалеевым